№ 3
2026

# МӘГАРИФ
## ТАТАР ТЕЛЕ




**Рәдиф Җамалетдинов:**

# «Татар филологиясе – милләтнең рухи нигезе»

04 сентябрь, 2026 ел
№ 3

МӘГАРИФ
ТАТАР ТЕЛЕ

ЭЛЕКТРОН ВАКЫТЛЫ БАСМА

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** «ТАТМЕДИА» АЖ
**Адресы:** Россия Федерациясе,
Татарстан Республикасы,
Казан шәһәре, Академия урамы, 2 йорт

**НӘШЕР ИТҮЧЕ:** «ТАТМЕДИА» АЖ
**Адресы:** Россия Федерациясе,
Татарстан Республикасы, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 йорт

**РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:** Россия Федерациясе,
Татарстан Республикасы,
Казан шәһәре, Декабристлар урамы,
2 йорт
**Редакция телефоны:** (843) 222-06-02;
222-06-09
**E-mail:** magarif@bk.ru
**Сайт:** magarif-uku.ru

12+

Создано при поддержке Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям.

Зарегистрирован в Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций 04.09.2014 г.

**Эл № ФС 77 - 59204**

**Периодичность выхода** – 1 раз в квартал

Мнение редакции не всегда совпадает с мнением авторов. Редакция не располагает возможностью выступать ходатаем в официальных организациях. За достоверность рекламных объявлений ответственность несёт рекламодатель.

**РЕДАКЦИЯ:**

Баш мөхәррир:
**Закирова Гөлүсә Рәүф кызы**
Чыгаручы мөхәррир:
**Лотфуллина Ф.А.**
Мөхәррирләр: **Хисмәтова Л.К., Сабиров А.З.**
Корректор: **Фәйзуллина Р.Ә.**
Дизайн һәм верстка: **Шәйхеева Э.З.**

**ТЫШЛЫКТА:**

Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор

**Рәдиф ЖАМАЛЕТДИНОВ**

**Дарья АНФЕРОВА** фотосы.

Журнал распространяется бесплатно.

МИЛЛИ МӘГАРИФ

**Фәния ЛОТФУЛЛИНА**
Рәдиф Җамалетдинов: «Татар филологиясе – милләтнең рухи нигезе»......3

**Фираз ХАРИСОВ**
Рүзәл Юсупов – милләтебезнең горурлыгы......8

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**
Татар әдәбияты кафедрасы: үткәне, бүгенгесе......15

**Чулпан ХАРИСОВА**
Татар теле кафедрасы эшчәнлеге: диахроник аспект......22

МӘКТӘПКӘЧӘ ТӘРБИЯ

**Нурия ГАЛИМОВА**
Эш беткәч уйнарга ярый......28

**Надия ВӘЛИЕВА**
Тукай һәрчак безнең белән... ......33

**Алсу ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА**
Кыстыбый бәйрәме......38

**Рүзия ГЫЙМРАНОВА**
Бүләкне кем калдырган?......41

**Эльмира ШАКИРОВА**
Кульяулык – вәгъдә билгесе......45

ДӘРЕС

**АЛИЯ БОРҺАНЕТДИНОВА**
Фәнис Яруллинның «Зәңгәр күлдә Ай коена» әкияте......48

**Чулпан ИБРАҺИМОВА, Фәйрүзә ХӨСӘЕНОВА**
«Үзем турында үзем»
Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәре буенча......52

**Рузилә ВАГЫЙЗОВА**
Илсөяр Иксанова иҗатына сәяхәт......58

**Рамилә АБДУЛЛИНА**
Яра тулы күңел... ......63

**Зәһрә МИҢНЕБАЕВА**
Алда юллар, кайсын сайларга?
Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәрен укыганнан соң уйланулар......67

**Фирания ЕРЕМЕЕВА**
Зат алмашлыклары......72

**Эльмира ГЫЙБАСЕВА**
Җөмләнең баш кисәкләре......76

ТӘРБИЯ СӘГАТЕ

**Диләрә ГАЛИМҖАНОВА**
Көчле рухлы шагыйрь......81

**Райлә ЙОСЫПОВА**
Балачак бәйрәмнәре......84

1

МИЛЛИ МӘГАРИФ



# Рәдиф ҖАМАЛЕТДИНОВ:
# «ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ – МИЛЛӘТНЕҢ РУХИ НИГЕЗЕ»

Татар филологиясе – үткәнне бүген белән тоташтыручы, телне һәм милли мәдәниятне киләчәк буыннарга җиткерә торган мөһим юнәлеш. Аның тарихы дистә еллар белән генә түгел, гасырлар белән исәпләнә. Казан укытучылар институтыннан башланган юл бүген Казан федераль университетының Габдулла Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбендә дәвам итә. Заман үзгәрә, уку йортларының исемнәре, структуралары алышына, технологияләр яңара. Әмма телгә, мәдәнияткә, фәнгә мәхәббәт, остазлар традициясе һәм милли мәгарифкә хезмәт итү максаты саклана. Уку йортының бай тарихы, сакланып килгән традицияләре һәм бүгенге мөмкинлекләре, киләчәк белгечләрне әзерләү турында шушы тарихның төрле чорларын үз тормыш юлы белән бәйләгән шәхесләрнең берсе – Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор Рәдиф Җамалетдинов белән сөйләштек.

**– Рәдиф Рифкатович, Сезнең һөнәри юлыгыз татар филологиясе белән тыгыз бәйләнгән. Бүгенге биеклеккә алып килгән беренче адымнарыгызны искә төшерик әле. Бу факультет Сезнең тормышыгызда нинди урын алып тора? Бирердәге мохит, традицияләр, остазларыгыз Сезгә ничек тәэсир итте?**

– Татар филологиясе факультеты – минем бүгенге тормышымның нигезе ул. 1995 елда КДПУны тәмамладым. Студент елларым истәлекләреннән иң элек остазларым, аларның белемгә ихлас мөнәсәбәте, дусларым хәтеремә килә. Ул чорда факультетның үзенчәлеге татар теле, әдәбияты һәм тарихын комплекслы рәвештә бирү иде. Бу бездә милли үзаң формалашуга зур ярдәм итте. Укытучыларыбыз безгә тирән белем бирү генә түгел, аны тормышта кулланырга да өйрәттеләр. Шуңа да без аларга чиксез рәхмәтлебез!

**– Татар филологиясе факультетының тарихы ул – бер уку йорты тарихы гына түгел, Татарстанда татар теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләү мәктәбенең тарихы да. Сезнеңчә, бу мәктәпнең иң зур казанышлары нидән гыйбарәт?**

– Татфакның иң зур казанышы ул – татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләү өлкәсендәге күпьеллык фәнни-методик мәктәпне һәм гадәтләрне саклау, үстерү. Аңа нигез XIX гасыр башында Казаныбызда ачылган Император университеты һәм 1876 елда ачылган Казан укытучылар институтында ук салына башлый. Ә инде 1926 елда татар теле һәм әдәбияты юнәлеше буенча махсус кафедра ачылу милли мәгариф өчен борылыш ноктасы булды. Шушы еллар дәвамында яшәп килгән кафедра, соңрак бүлек, факультет меңләгән югары квалификацияле белгеч әзерләде, алар – илебез һәм республикабызның һәр почмагында милли мәгарифне саклау һәм үстерүче төп кадрлар.

*Шунысын да ассызыклап узу кирәк, дип саныйм: 1940 елга кадәр педагогика институтындагы татар бүлеге республикада бердәнбер югары белем бирү үзәге була. Казан дәүләт университетының әлеге юнәлешендә эшләгән галимнәре һәм белгечләренең дә шактый өлеше нәкъ монда хезмәт иткән. Бары тик 1944 елда гына КДУ базасында махсус татар теле һәм әдәбияты бүлеге оеша.*

2024 елда Казан дәүләт университетында оешкан татар

бүлегенең 80 еллыгын билгеләп үткән идек. Быел исә республикабызда югары педагогик кадрлар әзерли башлауга 150 ел тула. Татар филологиясе факультетының да 100 еллыгын билгеләп үтү планлаштырылган.

**– Еллар узу белән уку йортының исеме дә, структурасы да үзгәрде: Казан дәүләт педагогика университеты, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты, аннары Казан федераль университеты. Ә традицияләр саклап калындымы?**

– Әйе, уку йорты үзе дә, исеме дә зур үзгәрешләр кичерде. Ләкин төп гадәтләр – татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә тирән белем бирү, элек-электән килгән фәнни мәктәпләрне саклау һәм үстерү, милләтнең рухи мирасына хөрмәт – хәзер дә дәвам итә.

Бүгенге Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе – институт составында нәкъ менә шушы традицияләрне яңа шартларда дәвам иттергән үзәк. Иң элек, әлбәттә, уку йортындагы җылы, гаиләгә хас мөнәсәбәтләрне билгеләп үтәсе килә. Безнең укучыларыбыз элек тә бик тырыш, максатчан һәм милли рухлы булды, бүген дә шундый.

Элекке татар филологиясе факультеты белән бүгенге югары мәктәпне аерып карау мөмкин дә түгел. Чөнки тормыш дәвам итә. Элекке факультет белән бүгенге югары мәктәпнең уртак үзенчәлекләре, дистә еллар дәвамында формалашкан традицияләре бар һәм алар бүген дә сакланып килә.

Укыту шартларына һәм методикага килгәндә, бүген без заманча җиһазландырылган, барлык таләпләргә җавап бирә торган аудиторияләрдә белем бирәбез. Шундый мохиттә студентларыбызны тәрбиялибез. Моның өчен республикабыз Рәисенә, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына, университет җитәкчелегенә рәхмәтебезне белдерәбез.

Безгә кайсы гына төбәктән, хәтта кайсы гына илдән галимнәр, хезмәткәрләр һәм укучылар килмәсен, алар безнең шартларга сокланып, гаҗәпләнеп карыйлар. Без дә, үз чиратыбызда горурланып, әлеге юнәлештәге эшчәнлекне мөмкин кадәр эчтәлекле һәм нәтиҗәле итеп оештырырга тырышабыз.

Элекке КДУ һәм ТДГПУның татар филологиясе факультетларында эшләгән галимнәр, хезмәткәрләр һәм танылган укучыларыбызның исемнәрен мәңгеләштерү, бу факультетлардагы күркәм гадәтләрне саклау йөзеннән яңа бер зур проектка чыгарга ниятләдек. Бу – махсус Татфак энциклопедиясе булдыру проекты. Ул ике бүлектән торачак. Аның беренче бүлегендә татар филологиясе факультетларында эшләгән галимнәр турында, аларның хезмәтләре һәм фәнни эшчәнлек юнәлешләре хакында кыскача мәгълүмат бирергә уйлыйбыз. Икенче бүлек исә әлеге факультетларда белем алган һәм үзләрен төрле өлкәләрдә таныткан шәхесләргә багышланачак. Энциклопедия өчен материаллар инде туплана. Элеккеге студентларыбыз вакыт һәм мөмкинлек табып, үзләре турында мәгълүматларны безгә җибәрсә, бик рәхмәтле булыр идек.

**– Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының киләчәктәге төп максатлары нинди? Татар филологиясе институт стратегиясендә нинди урын алып тора? КФУ татар теле һәм әдәбияты укытучыларын нинди принциплар нигезендә әзерли?**

– Институтның төп максаты – дөньякүләм белем бирү мәйданында конкурентлы булган, милли мәдәниятне саклаучы һәм үстерүче филолог-белгечләр әзерләү. Татар филологиясе институт өчен стратегик юнәлеш булып тора. Институтта татар телен һәм мәдәниятен төрки дөнья,

Евразия контекстында өйрәнәбез. Лингвокультурология, чагыштырма тел белеме юнәлешләрен үстерәбез.

Без заманча, методик яктан әзерлекле, цифрлы технологияләрне куллана белүче укытучылар әзерлибез. Укытучы, телне гамәли белүдән тыш, аның мәдәният, тарих, психология белән бәйләнешен аңларга тиеш. Мәктәпкә шәхес булып формалашкан, иҗади фикерләүче, укучыларны үз телебезгә, мәдәниятебезгә мәхәббәт тәрбияли алырлык остаз кирәк. Без нәкъ шундый белгечләр әзерләргә тырышабыз.

Соңгы елларда глобальләшү шаукымы, җәмгыятьнең үзгәрүе нәтиҗәсендә бүген белгечләрнең мөмкин кадәр күбрәк компетенцияләргә ия булуы бик мөһим. Шуңа күрә соңгы елларда татар теле һәм әдәбияты юнәлешендә белем алучы студентларга өстәмә белгечлекләр тәкъдим итәбез. Аларның берсе – чит тел. Татар теле һәм әдәбияты юнәлешендә укучы балалар өстәмә рәвештә чит тел өйрәнә һәм киләчәктә аны укыта, төрле телләрдә аралаша ала. Беренче чиратта, әлбәттә, инглиз теле турында сүз бара. Моннан тыш, төрек, гарәп һәм кытай телләрен дә өйрәнү мөмкинлекләрен булдырдык.

Соңгы елларда «Татар әдәбияты. Гамәли журналистика» дигән белгечлегебез дә бик уңышлы эшләп килә. Бу юнәлештә без республикабызның «Татмедиа» агентлыгына, «ТНВ» һәм башка телеканалларга рәхмәтле. Алар белән тыгыз хезмәттәшлек итәбез.

Бүгенге көндә Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең уңышлы эшләп килүендә ТР Рәисе каршындагы татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясенең дә роле зур.

Югары мәктәп базасында гамәлгә ашырылучы тагын бер зур проект – республикабыз мәгариф оешмалары өчен ике һәм күптелле укытучылар әзерләү турында әйтми мөмкин түгел. Бүген математика, тарих, башлангыч мәктәпләр өчен шундый белгечләр әзерләнә. Алар үз предметларын татар, рус һәм чит телләрдә укыта алырлык дәрәҗәдәге белгечләр булып чыга. Укулары өчен республика хөкүмәте түли. Монда белем алучы студентларга республика күләмендә билгеләнгән 15 мең сум махсус стипендия бирелә. Әлбәттә, укуны тәмамлаганнан соң, аларның билгеле бер бурычы да бар: биш ел дәвамында республикабызның мәгариф системасында укытучы булып эшләргә тиешләр.

Моннан тыш, республикабыз хөкүмәте ярдәме белән без «Реклама һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр», «Нәшрият эше» кебек белгечлекләр дә ачтык. Анда да белгечләрне ике-өч телдә аралаша алырлык итеп әзерлибез. Ягъни алар рус һәм татар телләрен камил белү белән беррәттән, тагын бер чит тел өйрәнә һәм үз эшчәнлекләрендә аны куллана ала.

Тагын бер мөһим юнәлеш: музыка һәм рәсем укытучылары да әзерлибез. Алар да ике-өч телдә белем ала.

Безнең уку йортын, әлеге югары мәктәпне тәмамлаган яшьләр иң беренче чиратта татар телен камил белергә, әдәбиятыбызны тирәнтен өйрәнергә, мәдәниятебезне һәм тарихыбызны белергә тиеш. Шул ук вакытта алар рус телендә дә профессиональ дәрәҗәдә эшли алырга һәм ким дигәндә бер чит телне үзләштерергә тиеш. Киләчәктә дә үз эшчәнлегебезне шушы форматта оештырырбыз дип өметләнәбез.

**– Ясалма интеллект, цифрлы технологияләр, онлайн ресурслар мәгарифнең аерылгысыз өлешенә әверелә. Бу үзгәрешләр филологны һәм тел укытучысын әзерләүгә нинди яңалыклар алып килә?**

– Ясалма интеллект, цифрлы технологияләр белем бирү өчен яңа мөмкинлекләр ача. Алар телне

өйрәнүне, анализлауны тизләтә, яңа ресурслар тудыра. Ләкин төп сүз – филологның аналитик фикерләве, телнең мәдәният белән бәйләнешен аңлавы – ул һаман беренче планда. Технология ул – корал гына, ә сүз сәнгатен, телнең матурлыгын кеше генә тоя, аңлый ала. Без филологны ясалма интеллектны куллана белүче итеп кенә түгел, ә аңа кирәк вакытта каршы да тора, гуманитар карашны яклап та кала алырлык итеп әзерләргә тиеш.

Тагын шунысын да билгеләп үтәсем килә: бер яктан караганда, без – гуманитар юнәлештә эшләүче институт. Ләкин бу без заманча технологияләрне белмибез, күрмибез, аңламыйбыз дигән сүз түгел. Университет һәм республика җитәкчелеге ярдәме белән бүген заманча җиһазландырылган лабораторияләребез бар. Аларның берсе – журналистика һәм реклама юнәлешендә белгечләр әзерләү лабораториясе. Без аңа «Дулкын» дигән исем бирдек. Анда бүгенге көннең иң заманча җиһазлары һәм технологияләре кулланыла, студентларны шулар белән эшләргә өйрәтәбез. Моннан тыш, безнең институтның үз IT-паркы да бар. Ул – мәгариф технологияләрен үз эченә алган заманча үзәк.

**– Студенттан ректорга кадәр үткән хезмәт юлы Сезне нәрсәгә өйрәтте?**

– Әлеге юл – җаваплылыкны тоярга, түземлеккә һәм кешеләрне аңларга өйрәткән зур мәктәп. 1995 елдан бирле югары уку йортында ассистенттан профессорга, декан урынбасарыннан деканга, аннары проректор, ректор вазифаларына кадәр күтәрелү, бу баскычларның һәрберсен узу миңа мәгариф системасын тулысынча күрергә, аны эчтән, нечкәлекләре белән аңларга мөмкинлек бирде. Һәрбер вазифа үзенчә истәлекле, эчтәлекле һәм нәтиҗәле булды.

**– 300 гә якын фәнни хезмәт, монографияләр, уку-укыту әсбаплары, диссертацияләр... Сез татар тел белемендә лингвокультурология юнәлешен үстергән галимнәрнең берсе буларак билгеле. Бу фәнни юнәлешкә килүегезгә нәрсә сәбәп булды?**

– Лингвокультурология – тел аша халыкның рухи дөньясын аңлау. Телнең тирән мәгънәсе, тарихыбыз һәм мәдәниятебез белән кызыксыну мине шушы юнәлешкә алып килде. Татар теле базасында татар халкының теле, әдәбияты һәм мәдәниятен өйрәнеп, лингвокультурологик фәнни мәктәпне формалаштыру бәхетенә ирештем. Без алга таба үз тикшеренүләребездә, уку йортлары өчен язылган дәреслекләр һәм методик кулланмаларда нәкъ менә шушы принциплардан файдаланырга тырыштык. Бүгенге көндә әлеге юнәлештә шактый диссертацияләр якланды, монографияләр язылды.

**– Бүген гуманитар фәннәргә кызыксыну кими дип фикер йөртүчеләр бар. Филологиянең җәмгыять һәм дәүләт өчен әһәмияте нәрсәдә? Сезнеңчә, татар филологиясенең киләчәге нинди?**

– Филология – кешелекнең, милләтнең рухи нигезе. Ул тел аша тарихны, мәдәниятне, халыкның эчке дөньясын аңларга ярдәм итә. Филологиясез милләтнең киләчәге юк. Кеше үз ана телен белми, өйрәнми икән, киләчәктә милләтне саклау, аның эшчәнлек һәм аралашу даирәсен киңәйтү турында сүз алып бару бик кыен. Шуңа күрә татар филологиясе бүген дә үз әһәмиятен югалтмый. Тел һәм әдәбият – безнең иң кыйммәтле байлыгыбыз.

Киләчәктә татар филологын мин төрки дөньяда, Евразия киңлегендә татар телен һәм мәдәниятен тирән аңлаган, цифрлы технологияләрне нәтиҗәле куллана белгән, тел өйрәтүче һәм фәнни эзләнүләр алып баручы заманча белгеч буларак күз алдына китерәм. Ул гуманитар белем белән технологик белемне берләштергән белгеч булырга тиеш.

**Фәния ЛОТФУЛЛИНА**

МИЛЛИ
МӘГАРИФ

2




**Фираз ХАРИСОВ,**

педагогика фәннәре докторы, профессор,
Татарстанның атказанган фән эшлеклесе

# РҮЗӘЛ ЮСУПОВ – МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫГЫ

**Казан дәүләт педагогика институты (университеты) (1876–2011) Россиядәге югары уку йортлары арасында иң өлкәннәреннән санала иде. Аның тарихы 1876 елда Россиядә патша указы нигезендә Санкт-Петербург һәм Мәскәү укытучылар институтларыннан соң өченче булып ачылган Казан укытучылар институтыннан башлана. Пединститутның исеме 8 тапкыр үзгәртелә. Быел аңа 150 ел, андагы татар бүлегенең ачылуына 100 ел тула. Мәкаләбез бай тарихлы педагогика уку йортында 16 елдан артык ректор, 30 елга якын татар теле кафедрасы мөдире булып эшләгән олуг галим-филолог, җитәкче һәм җәмәгать эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясенең академигы Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның күпкырлы эшчәнлеген яктырта.**



*Рүзәл Юсупов*

## ТҮГӘРӘК БАГАНАЛЫ ЙОРТТА

Белүебезчә, традицияләр һәм гадәтләр – тотрыклы фикерне белдерә торган төшенчәләр. Шундыйларның берсе – игелекле, фидакяр гамәлләр кылган шәхесләрнең башкарган хезмәтләрен даими рәвештә күрсәтеп, зурлап искә алу. Әлеге фикерләр җирлегендә без укучыларыбызны академик Рүзәл Юсупов гыйльми-популяр, публицистик, җәмәгать эшләре һәм шуларга бәйле рәвештә тормышының кайбер мавыктыргыч эпизодлары белән таныштырып китәргә булдык. Аның кылган гамәлләре һәм кичергән вакыйгалары да күпләребезгә гыйбрәтле, файдалы үрнәк булырлык!

Булачак галимнең биографиясе, беренче карашка, авылда туып үскән меңнәрчә башка татар балаларыныкы һәм яшүсмерләрнеке кебек. Сугыш башланырга ике-өч ел кала Әтнә районының Кышкар авылында туып, дәһшәтле сугыш чорында бер яшьлек энесе, алты һәм ун яшьлек абыйлары белән дүрт малай һәм әнисе (әтиләре фронтта була) ачлы-туклы торып, сугыштан соң да күп еллар авыр тормышта гомер кичерәләр.

Рүзәлнең үзенчәлекле гамәлләре күбрәк белем алуы белән бәйләнешле була. Ул үз теләге белән авылларындагы мәктәпнең беренче классында яшьтәшләреннән бер ел иртәрәк, кышкы каникулдан соң гына укый башлый һәм шул ук елны икенче класска күчә. Мәктәпне «5»ле билгеләренә генә тәмамлый. Казандагы берәр техникумга кереп укырга ниятли.

Кызу урак өсте булганлыктан, Рүзәлне шәһәргә алып барып, укырга урнаштырып йөрүче булмый. Әле ундүрт яше тулмаган малай, беренче мәртәбә берүзе «Колхоз базары урамында түгәрәк баганалы йортта Зөләйха апа» дигән адрес белән Казанга барып урнашып, кооперация техникумына укырга керә. Ул, әлбәттә, кооперация сүзенең мәгънәсен дә белмәгән килеш, товароведлар (товар белгечлеге) бүлегенә кабул ителә (башка техникумнарда укучылар алу вакыты тәмамланган була).

**ХАКЛЫК ҖИҢӘ**

Гадәттәге дүртьеллыклардан үзгә, өчьеллык техникумда уку шартлары кырыс була. Дәресләр русча үткәрелә, һәр көнне җидешәр-сигезәр сәгать. Рүзәл кебек авыл мәктәбендә татарча укып килгән берничә малай өчен атнасына ике-өч тапкыр рус теленнән өстәмә дәрес. Өч елда гомуми урта мәктәп программасын үзләштерәсе, белгечлек буенча белем аласы, ике елда ай ярымышар производство практикасы һәм һәр елны кышын, җәен имтиханнар сессиясе. Имтиханнарда бер предметтан да өчле алырга ярамый, югыйсә семестр буена (ярты ел) стипендиядән мәхрүм буласың. Бөтен яшәү чыганагы – шул стипендия. Авылдан ярдәм юк: үз хәлләре авыр. Шуның өстенә, техникумның тулай торагы булмау аркасында, укучылар төрле гаиләләрдә квартирант булып яшиләр. Рүзәлгә дә бик авырга туры килә. Ләкин укуын «4»ле, «5»ле билгеләренә тәмамлап, товаровед дигән белгечлек алып чыга.

17 яше дә тулмаган яшүсмерне Курган өлкәсендәге Усть-Уйский райпотребсоюзына юллама (путёвка) белән эшкә җибәрәләр. Рүзәл, техникумда укыганда, тормышындагы беренче кырыс сынауны узган булса, Курган өлкәсендә товаровед булып эшләгәндә, аңа икенче авыр сынауны кичерергә туры килә.

Яшь егетнең анда эшләве һәм башыннан кичергәннәре турында сөйләп тормыйча, бер вакыйганы гына әйтеп китик. Сәүдә өлкәсендә кайбер гаделсез кешеләр хезмәт иткәнлеге мәгълүм. Курган өлкәсендәге кооперация сәүдәсендә дә була андыйлар, әлбәттә. Рүзәлне дә берничә мәртәбә алдый язып калалар. Бер очрагы шактый җитди була. Райпо складында озак саклану аркасында, сатарлык сыйфатын югалткан азык өчен, товаровед базадан бозылган товар алган дип, Рүзәлдән зур сумманы түләтергә дигән карар чыгаралар. Ләкин Рүзәл, базадан әйбәт азык алганлыгына инанган хәлдә, үзен гаепле дип танытудан баш тарта. Андый бәхәсле очракларда тиешле сумманы товароведның хезмәт хакыннан суд карары белән тотып калу ихтималы була.

Һәм менә, әле унсигез яше тулмаган булу аркасында, товар җаваплылыгы йөкләнергә дә тиеш булмаган егеткә суд каршына басарга туры килә. Әмма райпотребсоюз рәисе урынбасары суд утырышында аны яклап чыга, һәм судья да, гаделлек ягына басып, Рүзәлне гаепсез дигән карар чыгара. Хаклык җиңә.

Кышкар егетенең армиядә хезмәт итүе дә үзенчәлекләрәк була. Ул чик буе гаскәрләренә алына, ун тәүлек товар поездында Казаннан Кыргызстанның Ош шәһәренә кадәр урын-җирсез, коры паёк белән генә тукланып, юынмый-нитми такта сәндерәдә аунап барып, калган юлны, август ае булса да, иске тун, киез итекләр киеп, йөк машинасының кузовында чүгәләп утырган килеш, өстән брезент белән капланып, 738 километр араны 4–5 километр биеклектәге бормалы-сырмалы тау юлларыннан (перевалларда кар төшкәләп тора), өч тәүлеккә якын барып, Хорог исемле посёлок кебек кенә бик кечкенә шәһәргә килеп җитәләр. Анда Таҗикстан Республикасындагы Таулы Бадахшан автономияле өлкәсенең административ үзәгендә яшь солдатлар чик саклау хезмәтенә өйрәнә торган чик буе отряды урнашкан була. Җирле халыкның яшәү рәвешендә, үз-үзләрен тотышында, кием-салымнарында үзенчәлекләр зур була.

Рүзәлләрнең чик буе сакчылары хезмәтенә өйрәнүләре кызык та, авыр да була. Һәр солдатка берәр өйрәтелгән ат билгеләп, аның вакытлы иясе, ул атны ашатып-эчертеп,

җыештырып-чистартып, шул атында чаптырып барган көйгә махсус ясап куелган киртәләр аша сикереп узарга, төрле күнегүләр эшләргә өйрәнә. Өч километр биеклектә урнашкан тау-ташлы, һаваның кислороды аз җирдә хезмәт итү җиңел булмый. Кечкенәдән авырлыкларга күнеккән татар егете җебеп төшми, әлбәттә. Рүзәл чик буе хезмәте күнегүләре буенча «5»ле билгеләре генә алганга, аны мактап, «Молния»не махсус аңа багышлап чыгаралар һәм Сталинабадка сержантлар мәктәбенә җибәрәләр. Шулай итеп, Рүзәлнең армия хезмәтендәге өч елы бик уңышлы уза. Аны, алдынгы солдат буларак, партиягә алалар. Таҗикстан комсомолының үзәк комитеты, җәмәгать эшләрендә актив катнашканы өчен, Мактау грамотасы белән дә бүләкли.

Ниһаять, Рүзәл, армия хезмәтен тәмамлап, үз Ватанына – Татарстанына, Казанына әйләнеп кайта. Һәм шуннан бирле аның югары белем алудагы, җитди карашлы белгеч булып формалашудагы күркәм уңышлары башлана.

### БИШЬЕЛЛЫК УКУ ПРОГРАММАСЫН ДҮРТ ЕЛДА

Яшь егетнең күңеле белән халкына тартымлы булуы, татар мәдәниятен, телен яратуы Курган өлкәсендә рус милләте арасында яшәгән чагында ук башланып, армиядә көчәя бара. Ул Мәскәү радиосыннан бик сирәк кенә тапшырылган татар җырларын йотлыгып тыңлый, Татарстанны, Казанны сагынып яши һәм аның сагышлы хисләре яшьләрчә язган шигырьләрендә чагылыш таба. Армиядән кайтканда, аның Казан университетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укырга дигән нияте өлгергән була. Әмма бу теләккә ирешү сигез ел элек җидееллык татар мәктәбен тәмамлаган, татар урта мәктәбендә бөтенләй укымаган егет өчен артык авыр бурыч була: университетның татар филологиясе бүлегенә укырга керү өчен татар теле һәм әдәбиятыннан урта мәктәп программасы нигезендә кабул итү имтиханнары тапшырасы була һәм егет тәвәккәлли. Бу сыйфат анда кечкенәдән үк тәрбияләнгән. Бәхетенә ул армиядән берничә ай алданрак кайта, вакытының минутын да әрәм итмичә, көн-төн утырып, имтиханнарга әзерләнә. Тырышлыгы бушка китми, егет, имтиханнарын бик яхшы тапшырып, бер урынга биш кешелек конкурсны уңышлы уза һәм Казан дәүләт университетына укырга кабул ителә.

Үндүрт яшеннән зур авырлыклар күреп чыныккан Рүзәл дөнья күләмендәге шөһрәтле уку йорты студенты булуның кадерен яхшы белә һәм беренче көннәреннән үк бөтен көчен туплап, ару-талу белән исәпләшмичә, белем алуга керешә һәм гаять зур уңышларга ирешә. Ул барлык предметлардан да бишлегә генә укый, һәм аның дипломында барлык фәннәрдән дә «5»ле билгеләре генә тора. Шуның өстенә Рүзәлне зур җәмәгать эшенә җәлеп итәләр: аны тарих-филология факультетының комсомол секретаре итеп сайлыйлар. Ул меңнәрчә студентлардан бер генә кешегә эләгә торган иң зур бүләккә лаек була: өч ел буена инженер окладына тиң күләмле Ленин стипендиясе алып килә.

Гаять зур тырышлыгы аркасында, Рүзәл Юсупов, өченче курстан индивидуаль план белән укып, төп белгечлегенә өстәп, тәрҗемә теориясе һәм практикасы дигән квалификация ала һәм тагын бер казанышка ирешә: бишьеллык уку программасын дүрт елда башкарып чыга, дүртенче курсны тәмамлауга, Татарстан радиосында тәрҗемәче булып эшли башлый. Берничә айдан Рүзәл Юсуповны Татарстан телевидениесенең пропаганда редакциясенә редактор

итеп эшкә алалар. Өч ел телевидение редакторы вазифасын уңышлы үтәү Рүзәл өчен журналистлык тәҗрибәсен алып, дөньяга карашын ныгыту, фикерләрен киңәйтү өчен, бик бәрәкәтле дәвер була.

## ЖУРНАЛИСТИКАДАН РЕКТОРЛЫККА

Әмма Рүзәлгә, телевидениедә уңышлы эшләп, һөнәрен яратып башкарганда, Казан педагогика институты ректоры, аның диплом җитәкчесе профессор М.З. Зәкиев тәкъдиме белән шушы уку йортындагы аспирантурага күчәргә туры килә. Бу мәсьәләдә шунысы игътибарга лаек: монда да ул үзенең уңганлыгын, тырышлыгын күрсәтеп, диссертациясен бер ел алдан язып бетерә, аны уңышлы яклап, Казан педагогика институтының татар теле кафедрасы укытучысы булып эшли башлый.

Филология фәннәре кандидаты Рүзәл Юсупов өчен җитди яңа дәвер – гыйльми-педагогик хезмәт, административ һәм җәмәгать эшләре чоры башлана. Ул, нәселдән бирелгән һәм кечкенәдән сеңдерелгән тырышлык, максатчанлык сыйфатларын гамәлгә ашыра барып, югары уку йорты педагогының барлык хезмәт баскычларын уңышлы уза: ассистент, өлкән укытучы, доцент, декан урынбасары, Мәскәүдә докторлык диссертациясен яклагач, профессор, декан һәм, ректор М.З. Зәкиев икенче эшкә күчкәннән соң, Казан педагогика институты ректоры вазифаларын үти.

Без, аның кафедрасында бергә эшләгән хезмәттәшләре, күп еллар профессор Рүзәл Юсуповның уңышларына шатланып, ярдәмләшеп, бик тату яшәдек. Ул 17 елга якын җитәкчелек иткән дәвердә абруйлы Казан педагогика институты тагын да шөһрәтлерәк югары уку йортына әверелә, институт тормышына күп уңай яңалыклар кертелә, дәрәҗәсе буенча Россиянең югары педагогика уку йортлары арасында алдынгы урыннарда була. Институтның тырыш коллективы, ректорның акыллы җитәкчелек итүенә таянып, югары сыйфатлы укытучылар әзерләү, нәтиҗәле фәнни эшләр башкару һәм башка өлкәләрдәге эшләр буенча елдан-ел яңа уңышларга ирешә бара: Россиядәге педагогика уку йортлары арасында беренчеләрдән булып, Казан дәүләт педагогика университеты дәрәҗәсенә ирешә.

## ТАТАРСТАННЫҢ РЕСПУБЛИКА ПАРТИЯСЕ

Моңарчы да төрле җәмәгать эшләрендә актив катнашып килгән профессор Рүзәл Юсуповка башка иҗтимагый вазифалар йөкли башлыйлар. Ул, Казан шәһәр Советы депутаты буларак, мәгариф комиссиясе председателе сыйфатында, шәһәрдәге уку йортлары һәм балалар учреждениеләре эшләрен яхшыртуга өлеш кертә. Тиздән Рүзәл Абдуллаҗановичны тагын да җитдирәк җәмәгать эшенә җәлеп итәләр. Татарстан Югары Советына депутат итеп сайлангач, аңа парламентның милли мәсьәләләр һәм мәдәният мәсьәләләре комиссиясе (хәзергечә – комитеты) председателе һәм парламент президиумы әгъзасы вазифаларын йөкливәр. Комиссия җитәкчесе – башка эшләрдән азат ителеп башкарыла торган, ягъни штаттагы эш. Ләкин Рүзәл Абдуллаҗанович үзенең икенче йортына әверелгән университетны ташлап китми, парламенттагы эшләрен иҗтимагый вазифалар буларак башкара. Профессор Рүзәл Юсупов иң актив депутатлардан санала. Аның турыдан-туры катнашуында парламентта республикабыз өчен гаять әһәмиятле документлар – Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларация,

республиканың яңа Конституциясе, Татарстан халыкларының телләре турындагы Закон кабул ителә.

Рүзәл Юсуповның башка төрле җәмәгать эшләре дә байтак була. Мәкаләнең күләме чикләнгән булу сәбәпле, аларның барысын да сөйләү максат итеп куелмый. Тик бер бик җитди гамәлне искәртеп китмәү ярамас. Узган гасырның 90 нчы елларында Россиядә, шул исәптән Татарстанда да, халыкларның, милли аңнары җанланып, милләтләрне һәрьяклап алга җибәрү, күтәрү омтылышы башлана. Бу өлкәгә караган төрле эшләрнең берсе – республикаларда партияләр оешу. Әлеге хәл безнең республиканы да читләтеп узмый: Татарстанның үз партиясен булдыру идеясе калкып чыга.

Киров районы прокуроры Рәшит Вагыйзов, депутатлар Фәндәс Сафиуллин, «Востокстройтрансгаз»-ның генераль директоры Тәлгать Шиһабиев, күренекле журналист, «Шәһри Казан» газетасы баш редакторы Хәлим Гайнуллин, дәүләт хезмәткәре Николай Мышев, Татарстан прокуроры ярдәмчесе Гаял Мортазин, профессорлар Фираз Харисов, Рүзәл Юсупов һәм халыкның матур киләчәге өчен янып йөргән башка кешеләр оештыру җыелышында Татарстанның республика партиясе дигән демократик рухлы партия төзү турында карар чыгаралар. Аның җитәкче органы сайлана. Партиянең председателе итеп (җәмәгать эше тәртибендә) профессор Рүзәл Юсупов билгеләнә. Тиздән партиянең программасы, уставы төзелә, «Татарстан республикасы» исемле газетасы чыгарыла башлый. Татарстанның республика партиясе халыкта яклау таба, районнарда аның башлангыч оешмалары төзелә. Партия, Юстиция министрлыгы тарафыннан расланып, юридик яктан законлы хокукка ирешә.

Һичшиксез, Рүзәл Юсуповның уңышлары гаять зур, һәм бу республика халкының күбесенә мәгълүм. Аның яхшы педагог булганлыгын Казан techинститутында (педуниверситетында) укып чыккан меңнәрчә укытучылар һәм мәгариф хезмәткәрләре белә. Акыллы, тырыш җитәкче (кафедра мөдире, декан, ректор, партбюро секретаре) икәнлеге бу уку йортында эшләгән йөзләрчә педагог-галимнәр һәм хезмәткәрләргә мәгълүм. Ниһаять, әлеге күркәм затның республикабызның якты киләчәге, милләтебезнең имин, бәхетле тормышта яшәве өчен ялкынлы көрәшче булганлыгын Татарстан халкының күбесе әле дә хәтерли.

### ТУГАН ТЕЛ САФЛЫГЫ САГЫНДА

Академик Рүзәл Юсуповның зур галим икәнлеген, фәннең бик әһәмиятле тармакларында гаять күп файдалы гыйльми хезмәтләр иҗат итеп, бик игелекле эш эшләгәнлеген күп кеше белмидер, әлбәттә. Аның искиткеч күп эшләренең ышанычлы дәлилләре: профессор Рүзәл Юсупов язып бастырган сигез йөзгә якын фәнни-публицистик мәкаләләр, туксан китабы (шул исәптән Евросоюз илләрендә бастырып таратылган җитди монографиясе), йөзләрчә интервьюлары, радио-телевидениедән тапшырылган чыгышлары; аның Татарстан Фәннәр академиясенең академигы һәм вице-президенты итеп сайлануы һәм берничә чит ил фәннәр академияләренең академигы итеп сайлануы.

Бу язманың авторы, үзе дә гыйлем иясе буларак, фәнни эшнең бик авыр икәнлеген аңлап һәм, Рүзәл Абдуллаҗановичның шушы җиңел булмаган өлкәдә тау кадәр зур гамәлләр кылган шәхес булганлыгын белеп, бу олпат галимнең фәнни эшләрен тулырак итеп күрсәтергә кирәк дип уйлыйм.

**Галимнең фәнни хезмәтләрендә тормышның бик мөһим мәсьәләләре – мәдәнияттәге, социаль-сәяси тормыштагы проблемалары, әхлак-тәрбия бурычлары һәм башка күптөрле темалар бәян ителә. Автор хезмәтләрендә, бай тормыш тәҗрибәсеннән, мул белеменнән һәм зирәк акылыннан файдаланып, тормышыбыздагы җитди проблемаларны хәл итү һәм гомумән дөрес яшәү өчен әһәмиятле киңәшләрен бирә.**

Профессорның гыйльми-публицистик хезмәтләре күплеге белән дә һәм темалары эчтәлекләренең әһәмиятле булуы белән дә игътибарга лаеклы. Аның мәкаләләре, китаплары тормышның төрле тармакларына мөнәсәбәтле һәм практик эшләргә файда китерерлек. Төгәлрәк итеп әйткәндә, алар Татарстаныбыздагы фәнне баетуга, милли мәгарифне алга җибәрүгә, туган телнең сафлыгын саклауга, кулланылышын киңәйтүгә, аны мәктәптә өйрәтү-укытуга ярдәм итүгә багышланган.

Әлбәттә, бу мәкаләдә генә профессор Рүзәл Юсуповның меңләгән гыйльми хезмәтләре турында тулы итеп язып чыгу мөмкин түгел. Күпсанлы мәкаләләре һәм китаплары арасында, табигый рәвештә, тәрҗемә теориясе һәм практикасына, татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнүгә, бу темаларга якын торган сөйләм культурасына багышланган хезмәтләр, дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре зуррак урынны алып тора.

Академик Рүзәл Юсупов соңгы елларда ул күбрәк милләтебез, мәдәниятебез, мәгарифебез, телебезнең дөреслеге, сафлыгы мәсьәләләре турында яза. Бу аның халкыбызның рухи тормышын кайгыртуын күрсәтә. Гыйбрәтле тормыш юлы узган, төрле өлкәләрдә игелекле гамәлләр кылган, әһәмиятле күп фәнни хезмәтләр язган, өлкән яшьтә булуына карамастан, хәзер дә актив иҗтиһат итүче Рүзәл Юсупов – милләтебезнең горурлыгы. Аның кыйммәтле китапларыннан, мәкаләләреннән барлык кешеләр дә – укытучылар да, журналистлар да, башка һөнәр әһелләре дә файдаланса, нәтиҗәсе дә булачак. Гомумән, андый шәхесләр игътибар үзәгендә торып, зур хөрмәткә лаеклы булсын иде.

Рүзәл абый Юсуповка сау-сәламәт килеш, милләтебезгә нәтиҗәле хезмәт итәргә, фидакяр гамәлләренең игелеген күрергә насыйп булсын.

**Хөрмәтле аксакалыбызның күркәм сүзләре:**

*«Балаларына тумыштан ук туган телләрен өйрәтү – һәр ата-ананың әхлакый бурычы. Безнең телебез шуның өчен дә ана теле дип атала: ул – борынгы әби-бабаларыбыздан йөзләрчә буыннар аша тапшырылып, камилләштерелеп килгән иң кадерле, изге нәрсә. Ничек итеп үз телеңә, атаң-анаң, әби-бабаларың теленә илтифатсыз булырга, аны белмәскә, өйрәнмәскә һәм балаларыңа да өйрәтмәскә мөмкин?!»*

*«Дөнья үзенең төрлелеге белән күркәм, табигать тә бертөрлелекне яратмый. Дөньяның камиллеге, матурлыгы төрле милләт халыклары, төрле телләр, төрле төсләр, милли киемнәр, халык җырлары, биюләре булуда. Болар – халыкларның бай мирасы, кыйммәтле хәзинәсе бит!»*

МИЛЛИ
МӘГАРИФ

3



**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**

әдәбият галиме,
филология фәннәре докторы
Казан федераль университетының
атказанган профессоры

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КАФЕДРАСЫ: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ

**1876 елда Укытучылар институты итеп ачылган уку йорты 1922 елда Көнчыгыш педагогия институты, 1934 елда Казан дәүләт педагогия институты итеп үзгәртелә. 1931–1934 елларда хәтта Татар педагогия институты дигән исем белән дә эшләп ала. Мондый исемнәр йөрткән югары уку йортында, әлбәттә инде, милли телебезне һәм сүз сәнгатебезне укыту да ныклы урын алырга тиеш. Шулай булып чыга да, 1925–1926 елда биредә татар теле һәм әдәбияты кафедрасы ачылу шул ихтыяҗ белән аңлатыла. Бу гаять әһәмиятле вакыйгага быел нәкъ 100 ел тулды. Бу очракта без әлеге фәнни, педагогик һәм тәрбия үзәгенең шушы вакыт эчендәге үткәнен, халкыбызның мәгарифе һәм мәдәнияте үсешенә ул керткән өлешен барлауны максат итеп куйдык.**

### ТАТАР ГАЛӘМЕНДӘ БЕРЕНЧЕ МИЛЛИ ФӘННИ-ПЕДАГОГИК ҮЗӘК

Шунысын да әйтү мөһим: кафедра татар галәмендә беренче рәсми милли фәнни-педагогик үзәк булуы белән дә истәлекле. Дөрес, 1906 елда Уфада эшли башлаган «Галия» мәдрәсәсендә шуңа охшаш бер кабинет булганлыгы билгеле. Чөнки анда татар телен укыту да тормышка ашырыла. Әмма аны уку йортының кафедра башкара торган бурычларын хәл итүче бер үзәге итеп карап булмыйдыр. Безнең Казан Көнчыгыш педагогия институтында да башта милли лингвистика бүлеге оештырыла. Әмма ул нигездә тел укыту мәсьәләләрен генә кайгыртырга тиеш була. Шуңа күрә татар теле һәм әдәбияты кафедрасы итеп оештыру мәгъкуль күренә. Шушы уку елыннан студентларны да татар теле һәм әдәбияты бүлегенә кабул итү башлана.

Кафедраның беренче мөдире – күренекле галим **Габдрахман Сәгъди**. Ул – татар мәдрәсәләреннән тыш, Истанбулда университет тәмамлаган фәнни яктан яхшы әзерлекле шәхес. Бөгелмәдә, Урта Азия төбәкләрендә укытып, шактый тәҗрибә туплаган мөгаллим. Шуңа күрә Татарстанда туган телебезне һәм әдәбиятыбызны укыту мәсьәләләрен ныклы юлга салу бурычы көн тәртибенә куелгач, әлбәттә инде, моны әзерлекле кадрлардан башка хәл итеп булмый. Ул вакыттагы гыйльми үзәк җитәкчесе, язучы Галимҗан Ибраһимов тәкъдиме белән Татарстан хөкүмәте Габдрахман Сәгъдине Казанга чакырып кайтара. Көнчыгыш педагогия институтында кафедра оештыру эше дә аңа тапшырыла. Ул үз тирәсенә Җамал Вәлиди, Гали Рәхим, Галимҗан Шәрәф, Насыйх Мөхетдинов, бераз соңрак Галимҗан Нигъмәти кебек галимнәрне туплый. Никадәр зур исемнәр һәм күренекле галимнәр, халкыбызга ихлас бирелеп хезмәт итүчеләр, телебез һәм әдәбиятыбыз фәнен, аларны укыту методикасының нигезен салышкан шәхесләр!

Укытуны фәнни-методик югарылыкта алып бару өчен, беренче нәүбәттә дәреслекләр кирәк. Иң башлап кафедрада татар әдәбияты тарихы буенча ике зур хезмәт языла. Аларның берсен Габдрахман Сәгъди үзе, икенчесен Гали Рәхим белән Газиз Гобәйдуллин башкарып чыга. Аларда халык авыз иҗаты өйрәнелә, борынгы чорлардан алып унтугызынчы йөзгә кадәрге язма әдәбиятыбыз тикшерелә. Әлеге хезмәтләр әдәбиятыбыз тарихын өйрәнүдә күп еллар буена нигез булып хезмәт итте. Шул ук вакытта үзләре яшәгән елларда иҗат ителгән әсәрләрне барлап, аларның яңалыгы, үзенчәлекләре турында да фәнни нигезләнгән карашларны белдереп барырга да кирәк иде. Шушы зарурилыкны истә тотып, Г. Сәгъди «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» дигән хезмәт бирде.

Бу инде инкыйлабтан соңгы еллардагы әдәбиятны һәм идеологик, һәм сәнгати яктан бәяләүгә омтылыш иде. Сүз дә юк, галим ул елларның сәяси карашларын сәнгать чаралары белән җиткерүгә өстенлек бирүдән азат түгел иде.

Бу вакытта **Гали Рәхим**нең кафедрада эшләве шулай ук зур табыш булды. Ул күп телләр белүче, ягъни полиглот булуы аркасында, бик тә мәгълүматлы шәхес иде. Гарәп, фарсы, төрек телләрен белү аны бу әдәбиятлардан киң мәгълүматлы итте. Ул Хафиз, Руми, Хәйям, Сәгъди, Тагор әсәрләрен оригиналдан туган телебезгә тәрҗемә итте. Шуның өстенә ул, рус телендә югары белем алган кеше буларак, бу әдәбиятны да яхшы белә иде. Шул ук вакытта Г. Рәхим үз өслүбе булган, югары сәнгать кимәлендә иҗат итүче әдип буларак та чыгыш ясады. Аның «Идел» повесте прозабызның күренекле әсәрләреннән исәпләнә.

1929 елда кафедрага **Галимҗан Нигъмәти** килә. Ул – инкыйлабтан соңгы әдәбиятыбызның хәлен аеруча бөртекләп тикшергән галимнәребезнең берсе. «Әдәбият мәйданында», «Инкыйлаб елларында безнең әдәбият», «Татар совет әдәбияты күтәрелештә», «Әдәбият һәм тормыш» кебек хезмәтләре безгә шул еллар сулышын аңларга, бәяләргә мөмкинлек бирәләр һәм, әлбәттә, алар әлеге елларда тиешле җәмәгатьчелек фикерен барлыкка китерүгә хезмәт иткәннәр. Шул ук вакытта әлеге профессорыбыз Г. Тукай, Дәрдемәнд, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Гафури, Х. Туфан, К. Нәҗми, А. Шамов һәм башка бик күпләрнең иҗатларын монографик өйрәнүне дә игътибар үзәгенә алган. Күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе булып танылган Г. Нигъмәти Татарстан Язучылар берлеген оештыруның да үзәгендә булды. 1929 елда язучыларның һәм сәнгать эшлеклеләренең Кавказ төбәкләренә һәм Кырымга зур сәяхәтенә җитәкчелек итте, Ялтада Г. Ибраһимов, Мәскәүдә М. Горький белән очрашуны оештыруда да аның катнашы зур булды.

1932 елда кафедра каршында аспирантура ачуы да Г. Нигъмәтинең киләчәккә карап эш итүе нәтиҗәсе иде. Беренче аспирантлар: Мөхәммәт Гайнуллин, Җамал Вәзиева, Маһинур Фәйзуллина. Остазларыннан үрнәк алып, М. Гайнуллин әдәбиятыбызның XIX гасыр һәм XX йөз башы чорларын өйрәнүгә аеруча зур өлеш кертте. Аспирантура аша егерме ике яшь галим үтте. Латыйф Җәләй, Хәмит Ярми, Якуб Агишев, Үлмәс Беляева, Бәкер Яфаров, Мөхәммәт Мамин, Зыя Искужин һәм башкалар. Институтта укыган Гали Халит, Хатип Госман, Баян Гыйззәт, Хәсән Хәйриләр дә әдәбият фәненә саллы өлеш керткән галимнәр булдылар. Илленче еллар башында кафедрада ике фронтовик укытучы кандидатлык диссертациясе яклыйлар: Х. Госман «Һ.Такташ иҗатында эстетик идеяләрнең үсеше», А.Сайганов «Шәриф Камал хикәяләренең сәнгатьлелек үзенчәлекләре» дигән темаларга була алар. Шуннан соң А. Сайгановны кафедра мөдире итеп билгелиләр, ә Х. Госманны Казан университетында 1944 елда ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлегенә эшкә җибәрәләр. Җамал Вәзиева татар балалар әдәбияты буенча кандидатлык диссертациясе яклый. Тормыш иптәше М. Гайнуллин белән берлектә фәнебезгә «XIX йөз татар әдәбияты», ике кисәктән торган «Егерменче йөз башы татар әдәбияты» дигән дәреслекләр бирәләр.

**Абдулла Сайганов** җитәкчелек иткән егерме елда кафедра төрле яклап үсешкә ирешә бара. Мәдинә Җәләлиева Гомәр Бәширов иҗаты буенча диссертация яклый, 1959 елда монография чыгара. «Борынгы татар әдәбиятында кеше образы» дигән китабы да сүз сәнгатебезне өйрәнүдә уңышлы адым булып кабул ителә. А.Җ. Сайганов үзе Фатих Әмирханның эстетик карашлары формалашу үзенчәлекләрен өйрәнүгә

төп игътибарын туплый. Бу юлда аның «Проблемы типического в татарской реалистической литературе» (1972) дигән китабы фәнни җәһәттән аеруча тирән эшләнгән хезмәт булып бәяләнә. Шушы мәсьәләләргә багышланган докторлык диссертациясе Бакудагы гыйльми советта бертавыштан уңышлы дип табыла. Аңа филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә бирелә. Кызганыч, Абдулла Җамалетдин улы шуннан соң озак та тормый вафат була.

Инде 1965 елдан татар теле һәм әдәбияты кафедрасы икегә бүленә: татар тел белеме һәм татар әдәбияты кафедралары. 1972 елда кафедра җитәкчесе итеп Уфадан филология фәннәре кандидаты **Фәрит Хатипов** чакыртыла. 1986 елда ул фән докторы, профессор була һәм 1991 елга кадәр мөдирлек вазифасын башкара. Бу чорда коллектив яңа кадрлар белән тулылана тора. Төрле елларда Рифат Сверигин, Фоат Галимуллин, Эльмира Галиева, Әмир Мәхмүдов, Рәшит Ягъфәров, Равил Кукушкин, Марс Гыймадиев, Әлфия Мотыйгуллина, Әлфинур Зиннәтуллина, Ләйлә Минһаҗева, Луиза Җамалиева, Гөлүсә Каюмова, Рамил Ханнанов һәм башкалар килеп кушыла. Алар һәрберсе үзләре кызыксынган өлкәләр буенча фәнни тикшеренүләр алып баралар. Ф. Галимуллин 1999 елда, «1920–1930 еллар татар әдәбиятында эстетик кануннарның һәм социологик таләпләрнең үзара мөнәсәбәте» дигән темага докторлык дәрәҗәсе алу өчен, диссертация яклый. 2000 елда аңа профессор исеме бирелә. Э.Р. Галиева исә 2002 елда шулай ук филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алуга ирешә. Аның тикшергән темасы – «Татар әдәбият белемендә мәдәни-тарихи мәктәп». Әлеге хезмәт академик Мансур Хәсәнов җитәкчелегендә башкарыла. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан фән докторы дәрәҗәсенә ия булган Ә.Г. Мәхмүтов кушыла, шул рәвешле, кафедрада шактый көчле фәнни үзәк барлыкка килә. Болар һәммәсе булачак укытучы, фәнни кадрларны тәрбияләүнең сыйфатын тагын да күтәрүгә китерә. Кафедра әгъзалары дистәләгән монографияләр, уку әсбаплары, методик хезмәтләр бастырып чыгаралар. 1990–2011 еллар арасында кафедра мәктәп дәреслекләре әзерләп бастыру буенча төп үзәкләрнең берсенә әверелә. Бу дәреслекләр укытучыларның һәм методистларның югары бәяләрен ала.

1991–1995 еллар арасында кафедра мөдире вазифаларын **Эльмира Галиева** башкара. 1995–1999 елларда кафедра мөдире булып **Фоат Галимуллин** эшли. Ул Татарстан Язучылар берлеге рәисе итеп сайлангач, 1999–2003 еллар арасында мөдирлек вазифасы КДУ профессоры **Азат Әхмәдуллинга** йөкләнә. 2003 елда Ф. Галимуллин җитәкчелекне янә үз кулына ала. 2011 елда бу вазифага Төмән өлкәсенең Тубыл педагогия институтыннан профессор **Флёра Сәйфулина** кайтарыла. Флёра Сәгыйть кызы югары белемне заманында безнең институтта алган иде.

## ИҖАДИ МОХИТ

Татар теле һәм әдәбияты бүлеге халкыбызның бик күп күренекле шәхесләрен укытып, тәрбияләп бирде. Алар арасында без институт каршындагы рабфакны тәмамлаган Муса Җәлил, аның көрәштәше Абдулла Алиш белән хаклы рәвештә горурланабыз. Күп кенә язучыларыбыз күкрәген шулай ук безнең уку йорты значогы бизәде. Алар: Гадел Кутуй, Гариф Гобәй,

Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Мөхәммәт Мәһдиев, Габделхәй Әхәтов, Суфиан Поварисов, Хисам Камалов, Барлас Камалов, Гөлшат Зәйнашева, Энҗе Мөэминова, Әминә Бикчәнтәева, Роберт Әхмәтҗанов, Илдар Юзеев, Әнәс Хәсәнов, Равил һәм Раил Фәхретдиновлар, Фаяз Хуҗин, Ренат Харис, Әлфәт Закирҗанов, Зиннур Хөснияр, Марат Закиров, Гөлүсә Закирова, Лилия Хисмәтова һәм башка бик күпләр. Арада күкрәгенә безнең уку йорты значогын такмаган һәм дипломыбызны ала алмаганнары да бар. Мәсәлән, танылган язучы Ибраһим Салаховны, өченче курста укыганда, нахак бәла тагып кулга алалар, ул уналты ел Колымада интектерелә. Аннан соң, әлбәттә, уку кайгысы булмый. Әйләнеп кайткач, без аны мәңгелек студентыбыз итеп игълан иттек. Хәсән Туфан да (ул вакытта аның фамилиясе Кусыйныф була) Казанга килгәндә, педагогия институтында укырга ниятләнгән була. Гомәр Бәширов язуынча, ул биредә Гадел Кутуй белән очраша һәм алар дуслашалар. Икесе дә 1924 елда педагогия институтына укырга керәләр: Хәсән татар бүлегенә, Гадел рус бүлегенә. Икенче тау урамында (хәзерге Волков урамы) фатирда да бергә торалар. Институтта айга ике тапкыр бергәләп «Укы-төзе!» дигән дивар газетасы чыгаралар. Барлыгы 12 сан чыга. Бер ел укый да Хәсән Бишбалта мәктәбендә укыта башлый *(Казан утлары, 1972, № 3, 145 бит).* Шулай итеп, институтыбызда иҗади мохитне, студентлар матбугатын оештырып җибәрүчеләр дип киләчәктә күренекле каләм әһелләре булып китәчәк шушы күренекле шәхесләребезне атыйбыз.

Муса Җәлил дә 1922–1925 елларда Казан педагогия институты каршында оештырылган Татрабфакта укый. Уку елларында язган шигырьләреннән хәтта «Барабыз!» дигән җыентык та чыгара. Биредә безнең кафедра әгъзалары аеруча күңел җылылыгын салып укыталар. Дәүләт карамагындагы уку йортларында тиешенчә белем ала алмау сәбәпле, алга таба әзерлек алу өчен мөмкинлекләре булмаган татар яшьләрен институтларга, университетларга керергә әзерләү яңа буыннар кулына мәгърифәт ачкычларын тоттыру дигән сүз иде. Моның әһәмиятен халкыбыз шунда ук аңлап алды. Әлеге рабфакка килүче яшьләрнең күп булуы шуның дәлиле иде. Аның эшчәнлеге белән ил күләмендәге җитәкчеләр дә кызыксынып тордылар. 1924 елның октябрь башында биредә илнең мәгариф халык комиссары А.В. Луначарский була. Алар бирегә Татарстан мәгариф халык комиссары Шәһит Әхмәдиев белән бергә киләләр. М. Җәлилнең биредә укыган вакыты була бу *(Казан утлары, 1978, №3, 192 бит)*. 1928 елның 4 августында, Казанга килгәч, шулай ук бик кызыксынып, татар рабфагына М. Горький да килә *(Әдәбият баскычлары, төзүче А. Әхмәдуллин, 102 бит).* Олы әдип яшьләргә иҗат рухы белән ялкынланып яшәргә киңәш бирә.

> **Хәсән Туфан белән Гадел Кутуй – институттагы иҗади мохитне, студентлар матбугатын оештырып җибәрүчеләр.**

Аннан иҗади мохитне җанландырып алып китү вазифасын үз кулына Гали Рәхим ала. Әдәби түгәрәк оештырып, күбесе авылдан килгән егет һәм кызларның иҗат эшенә тартылуын тәэмин итәргә тырыша. 1926–1929 елларда татар бүлеге кулдан иҗтимагый-сәяси һәм әдәби журнал чыгара. Ул «Яшь педагог» дип атала. Басмада Г. Кутуй, Г. Кашшаф, Ф. Даутов, М. Богданова, М. Кашшафетдинова

һәм башкалар үз әсәрләрен урнаштыралар. 1928–1929 елларда биредәге әдәби түгәрәктә иллегә якын студент катнаша. Һ. Такташ, еш кына килеп, кулларына иҗат каләме алган яшьләр белән очраша. Ибраһим Салахов болайрак сөйли иде:

– Такташ абыйга тартынып кына үзебез язган әйберләрне бирә идек. Ул шигырьгә күз төшереп ала да кайсыдыр сүзләрне сызып, аларны икенчеләре белән алыштырып куя. Шунда ук шигырь мәгънә ягыннан да, камиллеге җәһәтеннән дә икенче рәвеш ала. Инде аны кешегә тәкъдим иткәндә, үзеңне ышанычлырак сизәсең. Г. Кутуйның да ярдәмен күп тойды институт шәкертләре.

Әмма утызынчы елларның икенче яртысында, сәяси вазгыять үзгәргәч, иҗади күтәренкелек әкренләп сүнә бара. Аннары сугыш еллары. Ниһаять, илленче еллар башында иҗади мохит яңадан тернәкләнә. Менә 1954 елда татар әдәби-иҗат түгәрәгендә катнашучылар чыгарган кульязма альманах – «Яшьлек тавышы». Аның тышына № 5 дип куелган. Димәк, әле монысына кадәр дүрт номеры чыккан булган. Бәлки, алтынчысы, җиденчесе дә булгандыр. Әлеге саны институтның татар теле һәм әдәбияты кабинетында сакланган. Укырга теләгән кешегә аны, китапханәдәге кебек, формулярга кул куйдырып биргәннәр. Шушы нөсхәдәге битләр арасында бер формуляр да сакланган. Ул «Яшьлек тавышы»ның 3 нче санынннан. Аннан күренгәнчә, бу саны 1951 елда чыккан булган. Аны шушы кабинеттан 1952 елның 26 октябрендә, укырга дип, икенче курс студенты Илдар Юзеев алган. Формулярда Илдар абыйның бик тә таныш имзасы бар. Күрәсең, ул да иҗат түгәрәге эше белән кызыксына башлаган.

Аның каравы өченче сан белән бишенче сан арасында без И. Юзеевнең шагыйрь буларак, шактый таныла башлавын күрәбез. Байтак шигырьләр белән беррәттән, шушы ике-өч елда ул инде «Тормыш җиңә» дигән поэма да язып өлгергән. Аны «Яшь ленинчы» газетасының 1953 елдагы 132, 134, 135 нче саннарында һәм «Үсү юлы» альманахында бастырып чыгаруга ирешкән. «Яшьлек тавышы» кульязма альманахының без сүз алып бара торган санында исә поэмага Марс Шабаевның бәяләмәсе урнаштырылган. Ул шәриктәшенең әсәре турында үз итеп, яратып, шул ук вакытта таләпчәнлек күрсәтеп яза. Киләчәктә үзе дә шагыйрь булып китәчәк М. Шабаев И. Юзеевнең күренекле элгәребез Һ. Такташ шигъри мәктәбенең дәвамчысы икәнлеген дә әйтә. М. Шабаевның шигъри сиземләве көчле булган икән, чыннан да, И. Юзеев иҗатында такташчалык нык сизелеп торды.

Альманахның редколлегия составы да күрсәтелгән. Илленче еллар башында әдәби түгәрәктә җитәкчелек эшен яшь укытучы Мәдинә Җәләлиева башкара. Түгәрәккә «Яшь көч» дигән исем дә бирәләр. Шул исемдә дивар газетасы да чыгарыла. Ул, биш-алты метр озынлыкта булып, ай саен чыгарыла. Анда урнаштырылган әдәби әсәрләр эчтәлеге белән генә түгел, бизәлеше белән дә игътибарны җәлеп итә. Бигрәк тә сатира-юмор өлеше кызыклы. 1974 елда мин, бу язманың авторы, әлеге кафедрада укытучы булып эшли башладым. Беренче очрашуда ук остазым Мәдинә Шәйхи кызы әйтте:

– Мин әдәби түгәрәк эшен егерме еллап тартып киләм. Яңа сулыш кирәклеген сизәм. Әйдә, шушы эшне син алып кит әле...

Без, студентлар белән бергәләп, түгәрәкнең эшен колачлырак итеп оештырырга булдык. Иң әүвәл аны иҗат берләшмәсе дип атадык. Чөнки әдәби әсәрләрне халыкка җиткерүнең сәхнә вариантларын да киң куллану, яшьләрне төрле яклап үстерү турында



да уйландык. Исемен дә «Илһам» дип үзгәрттек. Дивар газетабыз да шул исем белән атала башлады. Рафис Гыйззәтуллин, Зиннур Хөснияр, Марат Закиров кебек талантлы язучылар шул берләшмәдән үсеп чыкты. Меңләгән шәриктәшләре кебек, алар үзләренең туган уку йортларын ихлас яратып яшиләр, сагыналар, дөньяның, яшәүнең бик күп якларына күзләрен ачкан белем һәм тәрбия йортына рәхмәтле булып гомер кичерәләр.

2005 елда Казан педагогика университетына Татар гуманитар институтын куштылар. Ике югары уку йортыннан берне ясадылар. Ул Татар гуманитар-педагогика университеты дип атала башлады. Андагы «Дастан» түгәрәге дә «Илһам» белән берләште. Миңа, ул вакыттагы татар әдәбияты кафедрасы мөдире буларак, әлеге талантлы яшьләрне бергә тупларлык җитәкче табарга кирәк иде. Ниһаять, аспирантлар арасыннан иҗатка омтылган, тынгысыз каләмле Рамил Ханнановны билгеләргә булдык. Ул бераздан диссертация дә яклады, кафедрада укытучы буларак та эшкә керește. Бер үк вакытта «Илһам» иҗат берләшмәсенең эшен дә җанландырып җибәрде. Ел саен «Илһамлы каләм» дигән иҗади конкурс оештырылу гадәт итеелде. Анда, Татарстаннан тыш, башка республикалар, өлкәләрдән дә талантлар килә башлады.

Елның иң яхшы әсәрләреннән «Илһам канатында» дигән җыентык чыгару гамәлкә кертелде. Аның беренче чыгарылышына Татарстанның ул вакыттага Президенты М.Ш. Шәймиев үзе кереш сүз язды. «Һәрберебез, – диелә анда, – үзе яшәгән чор өчен җаваплы. Иҗатта да шулай. Заманында Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Г.Исхакый, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Ф. Кәримнәр булган. Алар үз чорларының бурычларын мөмкин булганча хәл итәргә тырышканнар. Тарихта бөек булып калганнар. Әмма бүгенгене инде алар җырлый алмый, бу сезнең өлешкә төшә».

Әйе, хәзергебез өчен генә түгел, иртәгәге көнебез өчен дә без, ягъни бүгенгеләр җаваплы. Хәзер Казан федераль университет кысаларында да кафедрабыз, үзенә заман йөкләгән бурычларны мөмкин кадәр җиренә җиткереп башкарырга тырышып, киң планлы эш алып бара. Башкача була да алмый, чөнки чын мәгънәсендәге фидакяр элгәрләребезнең бөек эшләренә сокланган хәлдә, аларның өмет белән төбәлеп әйткән васыятьләрен үтисебез бар.

МИЛЛИ МӘГАРИФ

4



**Чулпан ХАРИСОВА,**

педагогика фәннәре докторы, профессор,
Татарстанның атказанган фән эшлеклесе,
Татарстанның атказанган укытучысы,
Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты

# ТАТАР ТЕЛЕ КАФЕДРАСЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ: ДИАХРОНИК АСПЕКТ

**Көнчыгыш педагогика институтының татар һәм рус бүлекләрен үз эченә алган филология факультеты составында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы 1926 елда оештырыла, димәк, аңа да быел 100 ел тула. Мәкаләбез кафедраның күпкырлы эшчәнлегенә багышлана, аның да исеме, еллар узу белән, берничә тапкыр үзгәртелә.**

## МАКТАУЛЫ ТАРИХ

Кафедраның беренче мөдире – татар әдәбияты тарихы һәм теориясе, аны укыту методикасы буенча бик күп хезмәтләр авторы – профессор **Габдрахман Гайнан улы Сәгъди** (1889–1956). XX гасырның 20–30 нчы елларында кафедрада милли кадрлар әзерләүгә профессор, Хезмәт Герое Мөхетдин Корбангалиев (1873–1941), РСФСРның Педагогика фәннәре академиясе әгъза-корреспонденты, профессор Мөхәммәтхан Фазлуллин (1883–1964), күренекле фонетист-экспериментатор Галимҗан Шәрәф (1896–1950), Риза Газизов (1894–1981), Хуҗа Бәдигый (1887–1940) кебек танылган галим-методистлар зур өлеш кертәләр.

**1921 елда ТАССР Үзәк Комитетының махсус Декрет кабул итүе һәм татар теленең тарихта беренче тапкыр дәүләт теле дип игълан ителүе милләтебез язмышында бик зур урын алып торган ана телебезне укытуның эчтәлеген тамырыннан үзгәртү бурычын куя.**

Кафедра галимнәре яшьләрне, димәк, илнең киләчәген төзергә тиешле гражданнарны, аң-белемле һәм тәрбияле итеп үстерү өчен, программа һәм дәреслекләрнең эчтәлегенә яңалыклар кертү, укыту метод һәм алымнарын үзгәртү, кадрлар кытлыгын хәл итү юлларын эзлиләр, яңа программа һәм дәреслекләр төзиләр. 1920 еллар ахыры – 1930 еллар башында кафедра, илебездә гомуми башлангыч белем бирү программасын гамәлгә ашыру һәм өлкәннәр арасындагы наданлыкны бетерү өчен, киң көрәш җәелдерә.

Профессор **Мөхәммәтхан Әшрәфҗан улы Фазлуллин** 1929–1949 елларга кадәр педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире вазифаларын үти. Шуның белән беррәттән югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә дә зур әһәмият бирә: аның җитәкчелегендә 40 ка якын кеше аспирантурада укып чыга. Ул җитәкләгән кафедрада хезмәтләре белән татар тел белеменең үсешендә әһәмиятле урын алып торган шактый галимнәр формалаша. В.Н. Хангилдин (1891–1971) – шундыйларның берсе. Ул башлангыч һәм урта мәктәпләр өчен программалар һәм дәреслекләр төзүдә актив эшли. 1934 елда «Татар теле дәреслеге» дөнья күрә. 1935–1937 елларда күренекле галим, тюрколог Г.Х. Алпаров (1888–1936) белән берлектә язылган «Татар теле: 1–2 нче класслар өчен грамматика» дип аталган дәреслекләре дә берничә ел нәшер ителә. Ул вакытларда кафедрага тел галиме Ш.А. Рамазанов (1887–1948) аспирантура тәмамлап эшкә килә, Л.Җ. Җәләй (1894–1966) 1933–1939 елларда студентларга белем бирә. Л.И. Яфаров (1900–1983) 1930 елда педагогика институтын тәмамлый, 1954–1965 елларда татар теле кафедрасын җитәкли, телебезнең тарихи фонетикасы, орфографиясе һәм пунктуациясенә караган хезмәтләрен, төп фәнни хезмәтләреннән берсе – «Татар теле үсештә» исемле китабын яза.

1926–1930 елларда тел һәм әдәбият кафедрасында Ленинград көнчыгыш институтын тәмамлап, кандидатлык диссертациясен яклап кайткан күренекле галим, тюрколог Г.Х. Алпаров башта доцент, аннары профессор булып эшли. Шул елларда аның татар теле орфографиясе, морфологиясе һәм синтаксисына караган фәнни хезмәтләре арасында иң күренеклесе булган «Шәкли нигездә татар грамматикасы» дөнья күрә.

Институтта Татарстанның атказанган укытучысы, бөтен гомерен халык мәгарифенә багышлаган танылган методист **Мәрьям Шакир кызы Галләмова** (1892–1985) 1929–1939 елларда укытучы булып эшли. Ул – ана телен өйрәтүне күздә тоткан күпсанлы дәреслекләр авторы, башлангыч мәктәптә татар телен укыту методикасы өлкәсендә күп көч куйган шәхес. 1944 елда аның «Башлангыч мәктәптә сөйләм культурасын үстерү методикасы: «Педучилищелар өчен дәреслек һәм башлангыч мәктәп укытучылары өчен кулланма», 1945 елда «Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы: Педучилищелар өчен дәреслек» дигән зур күләмле хезмәтләре нәшер ителә.

Татар теле кафедрасында тел галимәсе **М.З. Закирова**, 1949 елда аспирантура тәмамлап, «Татар грамматикаларына тарихи күзәтү» темасына филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсен алу өчен, кандидатлык диссертациясен яклагач, доцент булып эшли башлый. Үз фәнен яхшы белгән кеше буларак, ул студентларның яраткан һәм хөрмәтле остазына әверелә. Аның кызыксыну өлкәсенә тарихи грамматика материаллары, татар әдәби теленең морфологиясе карый, шул өлкәләргә кагылган тикшеренүләре хакында фәнни-гамәли конференцияләрдә чыгышлар ясый, фәнни-теоретик мәкаләләрен үзәк матбугатта бастырып чыгара.

1940–1950 елларда кафедра галимнәренең эшчәнлеге СССРдагы гомуми сәяси, иҗтимагый һәм лингвистик процессларга бәйле рәвештә зур үзгәрешләр кичерә. Аерым алганда, латин графикасыннан кириллицага күчү, татар мәктәпләренең саны киму, студентларны укыту-тәрбияләүдә идеологик юнәлешнең көчәюе һәм белем бирү стандартларын унификацияләү бу чорда милли кадрларны әзерләүгә хас булган төп билгеләрдән санала.

1960–1980 елларда педагогика институтының тарих-филология факультетында шактый үзгәрешләр була, аерым алганда, 1965 елдан татар теле һәм татар әдәбияты кафедралары аерым эшли башлый, 1986 елга кадәр аны филология фәннәре докторы, профессор, ТФА академигы, Казан дәүләт педагогика институты ректоры **Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев** җитәкли. Ул – тюрколог һәм тарихчы («Татары: проблемы истории и языка») – татар телен, аның тарихын («Проблемы лингвоистории татарского народа»), синтаксисын өйрәнүгә («Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис»), шулай ук татарларның этногенезын («Төрки-татар этногенезы») һәм телләр арасындагы бәйләнешләрне тикшерүгә («Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков») фундаменталь өлеш керткән күренекле тел галиме; югары («Татар синтаксисы») һәм урта һөнәри уку йортлары («Хәзерге татар әдәби теле»), мәктәпләр өчен төзелгән һәм басылып чыккан бик күп программалар, дәреслекләр («Татар теле. 10–11нче сыйныфлар өчен дәреслек») һәм методик кулланмалар авторы да.

М.З. Зәкиев җитәкләгән татар тел белеме кафедрасында ул елларда эшләгән галимнәрнең хезмәтләре, беренчедән, элегрәк

чорда дөнья күргән хезмәтләрне студентларга җиткерү, икенчедән, телебезнең кулланылу даирәсен, дәрәҗәсен өйрәнеп, аның башка телләр чолганышында яшәвен, аларның бер-берсенә йогынты ясау мөмкинлекләрен ачыклау юнәлешендә языла. Кафедрада исемнәре зур танылу алган галимнәр, яшь белгечләр югары филологик белемле укытучылар әзерләүдә бик зур тырышлык күрсәтеп эшлиләр. Алар – филология фәннәре кандидатлары, доцентлар З.М. Вәлиуллина, Л.С. Гаделшин, Ә.И. Ишморатов, М.Ә. Сәгыйтов, К.З. Зиннәтуллина, Р.А. Юсупов, педагогика фәннәре кандидаты, доцент Ф.С. Вәлиева, укытучы-методист, доцент Р.Ә. Асылгәрәева, ассистент З.З. Сәитов һ.б. Хәзер кайберләрнең эшчәнлегенә аерым тукталып китәрбез.

## ЗЫЯЛЫ ОСТАЗЛАР

Педагогика институтында укып, белем алып, фән-гыйлем дөньясында үзен ныклап таныткан шәхесләр арасында **Фатыйма Сәгыйровна Вәлиева** (1918–2012) аерым урын алып тора. Ул үзен М. Фазлуллин, В. Хангилдин, Ш. Рамазанов, Л. Җәләй, Л. Яфаров кебек зур белемле, татар тел белеменең үсеп, ныгып китүенә бихисап зур өлеш керткән галим-методистларның шәкерте дип саный иде.

Доцент Ф.С. Вәлиева РСФСРның Педагогика фәннәре академиясе әгъза-корреспонденты М.Ә. Фазлуллин җитәкчелегендә 1954 елда «Мөхетдин Корбангалиевнең татар телен өйрәтү системасы» дигән темага, татар теле буенча беренче кандидатлык диссертациясен бик уңышлы яклап, педагогика фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алгач, татар тел белеме кафедрасы доценты булып эшли. Ул – берничә буын мөгаллимнәрнең остазы һәм киңәшчесе, алар өчен «Татар теле дәресләрендә техник чаралардан файдалану» (1972), «Татар теле дәресләрендә укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыру» (1975) исемле уку-укыту кулланмаларын, «Урта мәктәптә татар телен укыту методикасы» исемле монографиясен (автордашы – Г.Ф. Саттаров, 1978) бастырып чыгарды. Бу китап «Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы» исеме белән 2000 елда яңадан дөнья күрде, 90 нчы елларда ачылган төрле типтагы (мәктәп, гимназия, лицей) уку йортларында эшләүче укытучыларның, студентларның өстәл китабына әверелде. Бу хезмәтне республикабызда татар педагогикасын һәм методикасын үстерү тарихында мәртәбәле вакыйга дип тә кабул итәргә кирәк, чөнки М.Ә. Фазлуллинның 1954 елда басылган «Татар теле методикасы» исемле зур күләмле хезмәтеннән соң күп еллар үткән һәм илебезнең мәгариф системасы да шактый зур үзгәрешләр кичерә иде.

Татар тел белеме кафедрасында эшләгән күренекле галим, педагог, тюрколог, филология фәннәре кандидаты, доцент **Зөһрә Мәҗит кызы Вәлиуллина** (1925–2011) турында «Мәгариф» журналында (№ 6, 2025 ел) саллы гына мәкалә күрде.

Татар тел белеме өлкәсендә күп хезмәтләр куйган күренекле галим, филология фәннәре кандидаты, профессор, Россия Федерациясенең мәгариф отличнигы, Россия Федерациясенең югары уку йортлары мактаулы хезмәткәре, «Хезмәт ветераны» медале белән бүләкләнгән **Клара Зыятдин кызы Зиннәтуллина** телебезгә хас булган универсаль грамматик категорияне – юнәлешләрне – монографик планда беренче булып тикшерүче. Аның турындагы әтрафлы язма белән «Мәгариф» журналында (№ 10, 2025 ел) танышырга мөмкин.

Бөтен гомерен укыту-методик эшкә багышлаган мөгаллимә, Россиянең югары һөнәри белем бирү учреждениеләренең мактаулы хезмәткәре, Татарстанның атказанган укытучысы, «Мактаулы остаз» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән доцент **Роза Әминовна Асылгәрәева** татар тел белеме кафедрасында өлкән лаборант, ассистент, өлкән укытучы, доцент, кафедра мөдире урынбасары, факультетта деканның уку-укыту эшләре буенча урынбасары булып эшли, күп еллар буе студентларның педагогик практикаларына җитәкчелек итә, татар телен укыту методикасы буенча лекцияләр һәм семинар дәресләрен алып бара.

Ике телне дә яхшы белүче буларак, 90 нчы елларда мәктәп-гимназияләр өчен ул программа һәм дәреслекләр төзүгә җиң сызганып керешә: татар мәктәпләренең 4 нче сыйныфы өчен ике кисәктән торган дәреслек (доцент Р.Х. Ягъфәрова белән), рус мәктәпләренең 7–8 нче сыйныфларында укучы татар балалары өчен М.К. Зиннуров белән төзелгән дәреслек һәм башлангыч сыйныфлар өчен төзелгән программалары, күп тапкырлар басылып, аңа Татарстанда һәм чит төбәкләрдәге укытучылар арасында киң танылу китерде.

Доцент Роза Асылгәрәева – татар теле буенча оештырылып килгән төрле дәрәҗәдәге олимпиада биремнәрен оста төзүче, критерийларын объектив билгели ала торган төгәл һәм таләпчән кеше. Ул татар теле укытучыларының якын һәм көтеп алган киңәшчесе, ярдәмчесе, алар алдында күп еллар буе телне укыту-өйрәтүнең актуаль мәсьәләләренә багышланган лекция һәм семинар дәресләрен, тренингларны үткәреп килде. Гомумән, Роза Әминовна – телебез һәм милләтебез хакында, аларның киләчәге турында кайгыртып, җан атып яшәүче өлкән буын методист-галимнәребезнең берсе.

Академик Мирфатыйх Зәкиев җитәкләгән татар тел белеме кафедрасында эшләп килгән аспирантураны тәмамлаган яшь галимнәр татар теле буенча, шулай ук аны рус теле һәм башка Көнбатыш Европа телләре белән чагыштырып, алар арасындагы типологик охшашлык һәм аермаларны өйрәнеп язылган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклыйлар. Шунысы да әһәмиятле: һәр уку елында кафедра галимнәре, аспирантларның фәнни-тикшеренү эшләрен туплаган бер яки ике җыентык («Вопросы языкознания», «Вопросы татарского языкознания», «Тюркологический сборник» һ.б.) басылып чыгып, тиз арада таралып та бетә иде.

**КДПИның татар тел белеме кафедрасы Алабуга, Чаллы, Башкорт дәүләт педагогика институтлары галимнәре белән дә бик тыгыз хезмәттәшлек итте.**

1986 елдан башлап 25 елга якын татар тел белеме кафедрасының мөдире булып, филология фәннәре докторы, профессор, ТФА академигы, Казан дәүләт педагогика университеты ректоры Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов эшләде. Педагогика институтының университет статусын алуы да Р.А. Юсупов ректор булып эшләгән елларга туры килә.

Бу аның җитәкчелегендәге коллективның аеруча зур уңышларга ирешү нәтиҗәсе булды. *(Рүзәл Йосыпов турындагы мәкалә «Мәгариф. Татар теле» басмасында Фираз Харисов авторлыгында тәкъдим ителде.)*



## ЯҢА СТАНДАРТЛАР КУШУЫ БУЕНЧА

Мәгариф системасында Дәүләт белем бирү стандарты төзелеп гамәлгә ашырыла башлагач, милли кадрларны әзерләүдә кафедраның эшен яңартуны таләп итә иде. Татар теле һәм татар әдәбияты өч юнәлештә – татар мәктәпләрендә, рус мәктәпләрендә укучы татар укучыларына һәм телне белмәүче балаларга тигез күләмдә өйрәтелә башлау эш программаларына, кафедраның гомуми проблематикасына да үзгәрешләр кертте. Иң башта шул ачыкланды: милли республикаларда, шул исәптән Татарстанда да, анда яшәүче төп милләтнең телен өйрәтү – укыту методикасы буенча докторлык диссертациясен яклаучылар моңарчы булмаган. Димәк, телебезне бездә яшәүче төрле милләт вәкилләренә өйрәтүнең яңа фәнни-методик нигезләрен булдыруга ихтыяҗ көн тәртибенә килеп баскан. Әмма милли мәгариф алдында туган яңа проблемаларны хәл итү өчен, беренче чиратта шушы өлкәгә караган иң югары фәнни дәрәҗәгә ирешкән – докторлык диссертациясен яклаган белгечләрнең булуы кирәк. Әлеге мәсьәләне хәл итүгә педагогика институтының (университетының) рус теле кафедрасы мөдире, илебезнең күренекле галим-методисты, Башкортстанда туып үскән, Россиянең атказанган фән эшлеклесе, профессор **Лия Закир кызы Шакирова** алына. Гомере буе рус телен пропагандалаган олпат галимә, күңеле белән татар җанлы шәхес буларак, татар телен укыту теориясе һәм методикасы нигезләрен булдыру хакында уйлана.

2000 елда Ф.Ф. Харисов, 2002 елда Ч.М. Харисова профессор Лия Шакирова җитәкчелегендә, татар телен укыту методикасы тарихында беренчеләр булып, докторлык диссертацияләрен яклыйлар.

**Фираз Фахраз улы Харисов** 2000 елда рус телендә белем бирү мәктәпләрендә татар телен укыту кафедрасы мөдире итеп билгеләнә; аның җитәкчелегендә телебезне рус телендә белем бирү мәктәпләрендә укучы татар балаларына һәм татарча белмәүче укучыларга өйрәтү программалары төзелә; рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар телен укыту концепциясе эшләнә; университетның барлык факультетларында укыту өчен, кулланмалар төзелә. Бу исә татар лингвометодикасында яңа юнәлешкә нигез салынуга китерде.

5



**Нурия ГАЛИМОВА,**

Теләче районы Теләче 2 нче балалар бакчасының
югары квалификация категорияле өлкән тәрбиячесе

# ЭШ БЕТКӘЧ УЙНАРГА ЯРЫЙ

(Г. Тукай иҗатына һәм тормыш юлына багышланган уен-викторина)

МӘКТӘПКӘЧӘ ТӘРБИЯ

ИСТӘЛЕК

*Татфак минем күңелемдә бары тик матур хатирәләр, яңа очрашулар белән истә калды. Рәхмәт сиңа, Татфак! Төпле белем, матур тәрбия бирүең өчен. Ана телебезнең матурлыгын тагын бер кат ачкан, әдәбиятына чумдырган, методикасына төшендергән өчен... Халкымның тарихын аңыбызга сеңдерү белән беррәттән, танылган язучы, шагыйрьләр, бөек шәхесләр белән очрашырга мөмкинлек тудырган өчен.*

**Максат:** Г. Тукай иҗаты, тормыш юлы турында алган белемнәрен арттыру.

**Бурычлар:**

***Белем бирү бурычы:*** мәктәпкәчә яшьтәге балаларны, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып,

Г. Тукайның тормыш юлы (балачак хатирәләре), иҗаты белән таныштыруны гомумиләштерү.

***Үстерү бурычлары:***

– балаларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү;

– куелган сорауларга тулы, дөрес җавап алуга ирешү;

– бергә команда булып уйнауларына ирешү.

***Тәрбия бурычы:*** балаларда Г. Тукай әсәрләренә карата кызыксыну уяту; бердәмлек, татулык хисен тәрбияләү.

**Алдан үткәрелгән эш:**

Г. Тукай әсәрләрен балаларга уку, шигырьләрен яттан өйрәтү; аның сүзләренә язылган җырларны тыңлау, мультфильмнар карау; балаларга әти-әниләре белән берлектә Тукай иҗатына карата рәсемнәр һәм кул эшләнмәләре ясау.

**Җиһазлау:** Тукай портреты, Г. Тукай язган китаплар күргәзмәсе, балалар ясаган рәсемнәр һәм кул эшләнмәләре күргәзмәсе, Г. Тукай әкиятләренә иллюстрацияләр; «Туган тел», «Бишек җыруы», «Бәйрәм бүген» җырлары язылган диск, битлекләр, читлек, ширма, кара тартма, бүре башы, аппликация уены өчен рәсемнәр, җилем, очколар өчен тарак һәм балта рәсемнәре, экран, проектор.

**Уен-викторина барышы**

*Зал Г. Тукай әсәрләренә иллюстрацияләр, балалар һәм аларның әти-әниләре ясаган рәсемнәр, кул эшләнмәләре белән бизәлгән. Уртада Г. Тукай портреты. Бер почмакта Тукай иҗат иткән әсәрләр кергән китаплар күргәзмәсе һәм Тукай музееннан күренешләр. Уртада ике яклап командалар өчен урындыклар, биремнәр өчен такталар куелган.*

*«Бәйрәм бүген» җыры (Җ. Фәйзи музыкасы, Г.Тукай шигыре) яңгырый. Җыр барышында бүлмәгә балалар керәләр һәм ярымтүгәрәккә басалар. Бер кыз һәм бер малай уртага чыгалар.*

**Кыз.** Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген. Нәрсәдән бу?

**Малай.** Мин беләм: бәйрәм бүген,
бәйрәм бүген!

*Бүлмәгә алып баручы керә һәм балаларга мөрәҗәгать итә.*

**Алып баручы.** Исәнмесез, балалар! Нинди бәйрәм соң сездә, матур җыр яңгырый, йөзләрегез дә бик шат?!

**Кыз.** Бүген 26 апрель – бөек татар шагыйре Габдулла Тукай туган көн. Без быел аның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итәбез.

**Алып баручы.** Әйе, балалар, бәйрәм бүген! Без сезнең белән, шаулап-гөрләп яз килгәндә, татар халкының танылган шагыйре Габдулла Тукайны искә алабыз, аның туган көнен билгеләп үтәбез. Аның туган көнен Татарстан Республикасында гына түгел, ә дөньяның барлык почмакларында яшәүче татар халкы билгеләп үтә. *(Балалар шигырьләр сөйли.)*

**1 нче бала**. Мең сигез йөз сиксән
алтынчы ел,
Язның иң матур ае,
Егерме алтынчы апрель
Бүләк иткән Тукайны.

**2 нче бала**. Тормыш сынаган,
кыйнаган
Кечкенә Габдулланы,
Ничек түзгән нәни йөрәк,
Җиңгән каршылыкларны.
**3 нче бала.** Дөньяга килгән чагында,
Ипи сыныгы белән,
Хак тәгалә бу сабыйга
Кәгазь-каләм дә биргән.
**4 нче бала.** Кыска булган гомерләре,
Ә иҗаты шундый зур.
Гасырдан-гасырга күчеп,
Озын-озак барыр юл.
**5 нче бала.** Әкиятләрен,
шигырьләрен укып,
Ничә буыннар үскән.
Бөек Тукай – горур Тукай,
Татарны татар иткән.

**Алып баручы.** Безнең бакчага йөрүче балалар да Г. Тукай иҗаты һәм тормыш юлы белән яхшы таныш микән?! Хәзер шуны белер өчен, аларны залга **«Эш беткәч уйнарга ярый»** уен-викторинасында катнашырга чакырабыз. Каршы алыгыз!

*Музыка астында залга ике команда керә, алар үзләре өчен әзерләнгән урыннарга утыралар.*

**Алып баручы.** Барлык уенчылар урнашып бетте. Уенны башлап җибәрәбез. Иң беренче командалар белән танышып китәбез. Моның өчен сүзне капитаннарга бирәбез. *(Капитаннар алдан сайланып куела.)* Алар үз командаларының исемен атарга, девизын әйтергә тиеш булалар.

*Беренче команданың сәламләве:*

**Бергә.** Без – «Былтыр» командасы.
**Капитан.** Әле укый белмәсәк тә,
«Туган тел»не җырлыйбыз.
Бу – Тукай абый бүләге,
Иң матур бер җыр, дибез.
**Бергә.** Безнең девиз: «Былтыр кысканны, быел кычкырмыйлар!»

***Икенче команданың сәламләве:***

**Бергә.** Без – «Су анасы» командасы.
**Капитан.** Тукай әкиятләрен сөйләп,
Телләребез ачыла.
«Су анасы», «Шүрәле»ләр –
Безнең дуслар барысы да.
**Бергә.** Безнең девиз: «Су анасы кебек җитез булырбыз!»

**Алып баручы.** Менә командалар белән дә танышып киттек. Һәр команданың уенда бары тик җиңү, ә кайсы команда җиңүче булачагын без бары тик уен ахырында гына белә алырбыз. Шулай ук аларны жюри билгеләр. Уен-викторинада командаларның тапкырлыгын, зирәклеген бәяләргә жюри итеп без тәрбиячеләрне чакырдык. *(Жюри белән таныштырыла.)*

Уенның шарты белән таныштырып китәм. Уен берничә бәйгедән тора, бәйгедә җиңгән саен, «Былтыр» командасына – балта, ә «Су анасы» командасына алтын тарак биреп барылачак. Ахырдан ике команданың да балталарын һәм таракларын санарбыз да чагыштырып җиңүчене билгеләрбез. Уңышлар сезгә!

**1 нче бәйге: «Кем акыллырак?»**

**Алып баручы.** Ике командага да бер үк сорау бирелә, ә алар, үз чиратларында, куелган сорауга иң беренче булып өч җаваптан дөресен сайлап, җавап бирергә тиеш. Җавап бирергә әзер булгач, капитаннар сигнал бирәләр. *(Сигнал бирү тәртибе күрсәтелә.)* Кайсы капитан беренче булып сигналга баса, шул команда беренче булып җавап бирә, әгәр дә алар ялгышсалар, җавап бирү мөмкинлеге икенче командага күчә.

**Сораулар:**

**1.** Чәчен тарап алтын тарак белән
И бизәнә, ясана.
Вә шуннан соң кинәт суга чума –
Нәрсә кала басмада?
*(а) шампунь; б) кармак;* **в) тарак.)**

**2.** Экрандагы рәсемнәргә игътибар белән карагыз, кайсы әкиятне Г. Тукай иҗат итмәгән? Шул рәсем астындагы санны атагыз.
*(а) «Шүрәле»; б) «Су анасы»;* ***в) «Шалкан».)***

**3.** Г. Тукай музей комплексы Арча районының нинди авылында урнашкан?
**(а)** ***Яңа Кырлай;*** *б) Бәрәзә; в) Өчиле.)*

**4**. Шүрәле Былтырга нинди уен уйнарга тәкъдим иткән?

*(**а) «Кети-кети»;** б) «Качышлы»; в) «Йөзек салыш».)*

**5.** Г. Тукай нинди авылда туган?

*(**а) Кушлавыч;** б) Өчиле; в) Кырлай.)*

**6.** Кәҗә белән Сарыкның капчыгында ничә бүре башы булган?

*(а) 12; б) 6; **в) 1.)***

**Алып баручы**. Беренче бәйге тәмам. *(Нәтиҗә ясала.)* Хәзер бераз ял итеп алыйк. Музыкаль тәнәфес игълан итәм. Сезнең алдыгызда кызлар Г. Тукайның «Бишек җыруын» җырлап күрсәтерләр. *(Сәхнәгә курчаклар тоткан кызлар чыга һәм җырны башкаралар.)*

**Алып баручы.** Хәзер инде командаларны сынауны дәвам итик, алар да Г. Тукай шигырьләрен яттан сөйләп күрсәтсен. Икенче «Кем иң матур сөйли?» бәйгесен башлап җибәрәбез.

**2 нче бәйге: «Кем иң матур сөйли?»**

**Алып баручы.** Бу бәйгенең шарты бик гади: һәр командадан берничә бала Г. Тукайның үзләре теләгән бер шигырен сәнгатьле итеп сөйләп күрсәтергә тиеш. Залда утыручылар җиңүчене билгелиләр. Ничек дисезме? Бик гади: кайсы командага иң озак һәм каты итеп кул чабалар, шул команда җиңүче була. Тамашачылар, сез игътибарлы булыгыз. Алкышларыгызны жәлләмәгез. *(«Былтыр» командасы – «Кызыклы шәкерт», «Су анасы» командасы «Фатыйма белән Сандугач» шигырен сәнгатьле итеп сөйлиләр. Ахырдан нәтиҗә ясала.)*

*Залга Шүрәле керә.*

**Шүрәле.** Сез нишләп миннән башканиндидер уен оештырып ятасыз? Минем дә уйныйсым килә! Әйдәгез, кети-кети уйнап алыйк әле! *(Шүрәле, залдагы балалар, уенчылар янына килеп, аларны кытыкламакчы була.)*

**Алып баручы.** Хәерле көн! Шүрәле, тукта-тукта, безнең балаларны кытыклап үтерәсең бит. Алар Г. Тукай тууына 140 ел тулуга багышланган уен-викторинага җыелдылар. Әйдә, син дә кал безнең уенда. Безнең бакча балалары нинди акыллы, тапкыр икәнлекләрен син дә күрерсең.

**Шүрәле.** Минем бит уйныйсым килә.

**Алып баручы.** Г. Тукай да кечкенә чагында уйнарга яраткан, дуслары белән төрле-төрле татар халык уеннары уйнаганнар. Шуларның берсе «Шүрәле, Шүрәле» уены булган. Әйдә, шул уенны уйныйбыз.

**Шүрәле.** Бик теләп уйнар идем, уенның шартын белмим шул.

**Алып баручы.** Уенның шарты гади: балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Түгәрәк эчендә һәрвакыт бер бала була. Балалар такмак әйткәндә, аның исемен әйтеп җырлыйлар. Бу бала, такмак беткәч, татарча бии, түгәрәк эченә чираттагы бала керә, әйлән-бәйлән дәвам итә.

Җен дә түгел, җил дә түгел,
Күренеп йөри торган.
Шүрәлене саклап тора
Татар да кара урман.
Шүрәле, Шүрәле,
Син Айгөлне күр әле,
Үзе бии, үзе җырлый,
Куллар чабып тор әле.

*Балалар Шүрәле белән уен уйныйлар.*

**Шүрәле.** Бигрәк оста икән үзегез, төрле яктан һөнәрләрегезне күрсәттегез, ә менә сез табышмаклар чишә беләсез микән? *(Залга матур итеп кара тартма чыгарыла.)*

**Алып баручы.** Әлбәттә, Шүрәле, безнең балалар бик тапкырлар. Әйдә, әйт табышмагыңны.

**3 нче бәйге: «Кара тартма».**

**Шүрәле.** Сезгә кара тартма алып килдем. *(Кара тартма күрсәтелә.)* Аның эчендә бер предмет бар, сезгә сорауны тыңлап, тартма эчендә нәрсә яшерелгәнен әйтергә кирәк. Җавапны бер генә тапкыр бирергә була, ялгышсагыз, җавап бирү хокукы, икенче командага күчә. Предметны дөрес атаган команда бер очко ала. Сез әзерме? *(Балалар җавабы.)* Игътибар белән тыңлагыз!

Кәҗә әйтә: «Микикики! Микикики!
Капчыктагы ул бит бар унике!

Ах, уңмаган, юләр Сарык,
надан Сарык,
Моннан зуррагын китер табып!»
Сарык та тиз аңлап ала бу алдашны,
Капчыктан ул алып килә
яңадан шуны.
Өч-дүрт бүре чынлап инде
куркыштылар,
Бер-берсенә күзләренә йөрештеләр.
Түгел хәзер бүреләргә ашау кайгы,
Тиз-тиз генә бу урынны ташлау кайгы;
«Ничек качыйк? Ничек табыйк
качу юлын?» –
Һәрбер бүре шуңар салган
бөтен уен…

**Алып баручы.** Балалар, кара тартмада нәрсә яшерелгән икән? Шүрәле сезгә бигрәк авыр табышмак әзерләгән. Кайсы команда әйтә алыр? … *(команда исеме әйтелә)* командасы җитезрәк булып чыкты, шуңа күрә аларга бер очко бирелә.

**Шүрәле.** Рәхмәт сезгә, балалар! Мине иҗат иткән Г.Тукайны да онытмыйсыз, аның әсәрләрен тәрбияче апаларыгыз белән бергәләп укыйсыз икән. Хәзер инде миңа китәргә кирәк, Су анасы чәйгә чакырган иде. Сау булыгыз. *(Шүрәле чыгып китә.)*

**Алып баручы.** Инде безнең уеныбыз да ахырына якынлашып килә, командаларга тарakларын һәм балталарын санар вакыт җитә, ләкин әле аларның тагын бер очко алырга мөмкинлекләре бар. Ничек дисезме? Бик гади «Былтыр» командасына – залда утыручы малайлар, «Су анасы» командасына кызлар ярдәм итә.

**4 нче бәйге: «Ашыгыч ярдәм».**

**Алып баручы.** Уенның шарты бик гади: кемнәр Тукай әсәрләрен күбрәк атый, шулар командасына бер очко бирелә. Башладык! *(Җаваплар: «Туган тел», «Кызыклы шәкерт», «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык», «Карлыгач», «Фатыйма белән Сандугач», «Безнең гаилә», «Шаян песи», «Эшкә өндәү», «Эш беткәч уйнарга ярый», «Гали белән Кәҗә», «Бишек җыры», «Җир йокысы» һ.б.)*

**Алып баручы**. Сез барыгыз да бик акыллы икәнсез, Г. Тукай иҗат иткән бик күп әсәрләрне беләсез, ләкин малайлар *(кызлар)* җитезрәк булып чыктылар. Шуңа алар командасына бер очко *(тарак яки балта)* бирелә.

Хәзер һәр команданың да җыелган таракларын, балталарын санар вакыт та җитте. *(Тарак, балталар санала һәм саннары тамашачыларга әйтелә.)*

**5 нче бәйге: «Супер уен-аппликация».**

**Алып баручы.** Сезнең барыгызның да шөгыльләрдә кисеп ябыштырганы бар, шулаймы? *(Җаваплар.)* Шуңа күрә сезгә биремне үтәү бик җиңел булачак, ләкин шул ук вакытта игътибарлы булырга онытмагыз! Һәр командага Г. Тукайның бер әкиятенең рәсемен җыярга һәм ак кәгазьгә ябыштырырга кирәк булачак. Ике команданың да биреме бер үк төрле түгел, шуңа күрә игътибарлы булыгыз. Кайсы команда беренче биремне үтәп бетерә, шул очко ала. *(Өстәлләрдә уен өчен алдан барлык кирәк-ярак әзерләп куела. Командалар биремне үтиләр, нәтиҗәгә карап, бәйгедә җиңүче команда билгеләнә.)*

**Алып баручы.** Шулай итеп, «Эш беткәч уйнарга ярый» уен-викторинасы ахырына якынлашты һәм нәтиҗәдә җиңүчеләр булып … *(команда исеме)* командасы танылды. Балалар барысы да бик тырыштылар, үзләренең Г. Тукай шигырьләрен яратуларын һәм белүләрен күрсәттеләр. Моның өчен бик зур рәхмәт аларга. *(Командаларга дипломнар һәм бүләкләр тапшырыла.)*

Габдулла Тукай – өлкәннәрнең дә, балаларның да иң яраткан шагыйрьләреннән берсе. Без аның әсәрләрен укып, тормыш сабагы алабыз, тәрбия нигезләренә төшенәбез, туган телебезне яратырга өйрәнәбез. Киләчәктә дә Г. Тукай шигырьләрен онытмасак иде. Рәхмәт сезгә! Әйдәгез, бүгенге уеныбыз тагын да күңеллерәк тәмамлансын өчен, Г. Тукайның «Туган тел» җырын бергә күмәкләшеп җырлыйбыз.

*(Күмәкләшеп «Туган тел» җыры башкарыла. Уен тәмамлана.)*

6



**Надия ВӘЛИЕВА,**

Казандагы 168 нче балалар бакчасының
югары квалификация категорияле
татар теле тәрбиячесе

# ТУКАЙ ҺӘРЧАК БЕЗНЕҢ БЕЛӘН...

(5–7 яшьлек балалар өчен бәйрәм чарасы)

МӘКТӘПКӘЧӘ ТӘРБИЯ

ИСТӘЛЕК

*И күңелле, матур, яшь чаклар! Хыялларга, өметләргә бай студент еллары. Гомер буена җитәрлек, сагынып искә алырлык, җаннарны җылыта, нәфисләндерә, онытылмаслык истәлекләрне очрашканда сөйләп туя алмый торган хатирәләр!*

*Беренче курста укый башлаганчы ук, безне Мамадыш районына Түбән Оча авылына бәрәңге алырга җибәрделәр. Биш-алты кыз удмурт әбидә яшәдек. Иртән биштә торабыз, ашап-эчеп кырга китәбез, көлешә-шаярыша бәрәңге чүплибез. Колхоз ашатты, эчертте, хезмәтебез өчен бирелгән акчага Казанга кайткач, матур киемнәр алдык.*

*Иң күңеллесе, истә калганнары – авыл клубындагы «вечерлар» инде, егетләр-кызлар белән танышу, аралашу, күңел ачу булды...*

*Исемнәре йөрәкләргә уелган кешелекле, гыйлемле могтәбәр укытучыларыбызга да изге теләкләремне җиткерәсе килә. Сезнең һәркайсыгызга олы рәхмәтләребезне белдерәбез, озын гомер телибез.*

*Зал бәйрәмчә бизәлгән. Чәчәкле урман аланы.*

**Алып баручы.** Исәнмесез, саумысыз, балалар! Без бүген сезнең белән сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуга багышланган бәйрәм кичәсенә җыелдык. Сүзне балаларга бирәм.

1. Тукай – безнең йөрәкләрдә,
Тукай – безнең күңелләрдә.
Үтәр еллар, үтәр гасыр,
Онытмабыз беркайчан да.
2. Илдә кояш, күктә кояш,
Йөздә кояш, җирдә кояш,
Көндәгечә көлә кояш.
Әмма бүген үзгә кояш.
3. Илдә кояш, җирдә кояш,
Тукай көне канат җәйгән.
Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген,
Тукай көне – безнең бәйрәм!

**Алып баручы.** Ничек уйлыйсыз, балалар, без ни өчен Тукайны онытмыйбыз? *(Балаларның җаваплары тыңлана.)*

– Ул матур шигырьләр, әкиятләр язган.

– Ул безгә «Туган тел» җырын язган...

– Ул табигатьне, хезмәтне, гаиләне, телебезне яратырга өйрәткән.

– Ул китаплар укыгыз дип әйткән.

**Алып баручы.** Бик дөрес уйлыйсыз, балалар. Тукай ул – үлемсез шагыйрь.

Тукай булмас иде шундый бөек,
Ятимлектә әгәр үсмәсә.
Тукай үлмәс иде шундый иртә,
Тормыш михнәтләрен күрмәсә.
Әткәң-әнкәң сиңа биргән, Апуш,
Мирас итеп шигъри зур күңел, –
Әби-бабайлардан килгән күңел,
Шагыйрәнә ямьле, нур күңел!
Яшьләй киткән Тукай...
Гел яшь булып
Яши бирә халкым күңелендә.
Телен, динен, халкын һәм намусын
Бар нәрсәдән өстен күргәнгә.

*Надия Вәлиева шигыре*

*Презентация күрсәтелә.*

**Алып баручы.** Кечкенә Тукайга әтисе белән әнисе Габдуллаҗан дигән исем кушканнар. Ә дус малайлары Кырлайда аңа Апуш дип дәшкәннәр. Әмма дүрт айлык чагында Тукай әтисез, дүрт яшьлек чагында әнисез калган. Ятим үскәнгә, аның балачагы бәхетле булмаган, балалар. Егерме җиде ел гына яшәгән ул, әмма бик күп укыган, шигырьләр, әкиятләр, мәкаләләр язган. Без аның әсәрләрен яратып укыйбыз, ятлыйбыз, җырлыйбыз. Шуңа күрә без Тукайны

«Үлемсез» дип атыйбыз.

Япь-яшь матур егет безгә экраннан карап тора. Халкыбыз өчен Тукай һәрвакытта да матур һәм бөек, үлемсез.

Кайсы гына бала – әнисен, ә кайсы әни баласын яратмый, аның турында кайгыртмый икән? Әнисе Бибимәмдүдә, кечкенә улын бик яратып, бишек җырлары җырлаган.

*Уртанчылар төркеме «Бишек җырын» башкара.*

**Алып баручы.** Балалар, һәркайсыбыз туган илен, туган җирен ярата, аны сагына, аның турында уйлый, җырлар җырлый, шигырьләр укый. Тукай да туган авылын, табигатен бик яраткан.

*«Җир йокысы» шигыре.*

*«Туган авыл» шигыренә җыр (А. Монасыйпов көе).*

**Алып баручы.** Хәзер сезгә зурлар төркеме кызлары Тукай шигырьләреннән табышмаклар әйтерләр. Җавапларын табарга.

1. Кешенең якын дусты, тугры сакчысы.

2. Кеше кебек үзе, маңгаенда мөгезе.

3. Чуар, йомшак күлмәге, тотсаң, уңа бизәге.
Тоттырмый, китә очып, я кала җирдә посып.

4. Тукай шигырендә сөтле банкага нинди җәнлек төшкән?

*«Сөткә төшкән тычкан» шигыре укыла.*

**Алып баручы.** Сез бик тапкыр, балалар, рәхмәт сезгә. Ә хәзер сез Тукай иҗаты буйлап сәяхәткә китәргә әзерме? Алайса, киттек.

*«Мин башлыйм, сез дәвам итәсез» уены.*

– Әйт әле, күбәләк… / «Бала белән күбәләк» – кечкенәләр төркеме балалары белән сәхнәләштерелгән күренеш.

– Әйдәле, Акбай, өйрән син… / «Кызыклы шәкерт» – уртанчылар төркеме.

– Бик матур бер җәйге көн… / «Эш беткәч уйнарга ярый» – уртанчылар төркеме.

– Һич сине куркытмасыннар… / «Сабыйга» – зурлар төркеме.

**Алып баручы.** Безгә кунакка Тукай әкиятләре геройлары килгән. Кемнәр дип уйлыйсыз?

**Балалар.** Бала, Күбәләк, Кәҗә, Сарык, Әтәч, Гали, Кояш, Ай…

**Алып баручы.** Балалар, әйтегез әле, Тукайның кайсы әкияте безне тәртипле булырга, кеше әйберсенә кагылмаска өйрәтә?

**Балалар.** «Су анасы» әкияте.

*«Су анасы» әкияте.*

**Алып баручы.** Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл… Балалар, нинди әкият шулай башлана?

**Балалар.** «Шүрәле» әкияте шулай башлана.

**Алып баручы.** Бик дөрес, балалар. Димәк, безгә бүген кунакка урманнан… Шүрәле килгән.

*Шүрәле керә.*

**Шүрәле.** Исәнмесез, балалар. Мин кешеләргә дә, балаларга да тимим. Мин – явыз түгел. Әмма минем дусларым юк. Шуңа мин сезнең янга дуслашырга килдем.

**Алып баручы.** Шүрәле, балалар синең белән дуслашырга әзер. Әйе бит, балалар?

**Балалар.** Әйе.

**Алып баручы.** Әйдәгез, бергәләшеп, Шүрәле белән уйнап алабыз.

*Шүрәле белән уен.*

**Алып баручы.** Безнең балалар күптән Шүрәле, Су анасы, Убыр белән дуслар. Ышанмасагыз, әкият карагыз.

*Мәктәпкә әзерлек төркеме. «Салават күпере төсләре» әкияте. (Н. Вәлиева)*

*Урман кызы керә, җырлый. Күбәләкләр бии.*

**Урман кызы**.
Исәнмесез, кошларым!
Агачларым, дусларым!
Урманда бераз йөрим,
Хәлләрегезне белим.

*Карга йөгереп чыга.*

**Карга.** Караул, караул, талаганнар!
Салават күперен урлаганнар!

**Урман кызы.** Ай-яй-яй, ни хәл итик? Барысына хәбәр итик!

**Карга.** Кар-кар! Хәбәр итик! Хәбәр итик!

**Урман кызы** *(тыңлап тора)*. Ишетәсеңме, кемдер килә. Әйдә, качыйк!

*Тавык тәпиле Йорт, аның артыннан Убыр керәләр.*

**Убыр.** Тукта! Тукта! *(Йорт артыннан йөгереп.)*
Качма, качма, Йортым!
Ике төсне генә урладым,
Шүрәлене куркыттым.
Тәрәзәмне буярмын,
Урынына куярмын.

**Йорт.** Юк, Убыр, китәм,
Булмыйм йортың бүтән.
Ул төсләргә кагылма,
Миңа тагылма. *(Йөгереп чыгып китә.)*

*Агач артыннан Урман кызы, Карга чыга, Убыр янына киләләр.*

**Урман кызы.** Убыр, син – урлаучы?
Тәрәзә буяучы?
Җибәр Салават күперен,
Дусларыңны тыңлачы!

**Убыр.** Юк, юк, бирмим! Барыбер бирмим! *(Китә. )*

*Куян керә.*

**Куян.** Мин – Куян, күп күрәм.
Салават күперен
Урлаучыны беләм!
Әйдә, минем арттан,
Курыкма карактан! *(Китәләр.)*

*Шүрәле керә. Кулына Салават күпере тасмалары тоткан.*

**Шүрәле**. Менә бит кызык иттем,
Былтырга үч иттем.
Бармагым сызласа да,
Ничә ел кычкырсам да,
Ярдәмгә чакырсам да
Килмәде беркем.
Шуңа урладым Салават күперен. *(Төсләрне саный.)*
1, 2, 3, 4, 5…
Ай-яй-яй, бу ни эш?
Җиде төс булырга тиеш!

*Куян һәм башкалар керәләр.*

**Куян.** Каравыл, каравыл, менә ул! Менә ул! *(Шүрәлегә күрсәтә.)*

**Урман кызы.** Исәнме, Шүрәле, урманым бизәге!
Салават күпере әллә синдәме?

**Шүрәле.**
Миндә! Бирмим беркемгә дә!
Барыгыз ташладыгыз,
Дошманлаштыгыз!

**Урман кызы**.
Без сине ташламадык,
Дошманлашмадык.
Үзең киттең,
Безне ят иттең.
Үч тотып яшәмә,
Дус булыйк, әйдә!
Шүрәле, бир инде
Салават күперен.

**Убыр.** Дөрес әйтәсез, дуслар! Менә миннән тасмалар.

*Төсле ике тасманы Урман кызына бирә.*

**Йорт.** И хуҗам! Рәхмәт сиңа,
Йортың булырга мин риза.

**Шүрәле.** Хәлләремә керегез,
Зинһар, кичерегез!
Бүтән болай урламам,
Кешеләрне хурламам.
Дус булуга ни җитә?
Мә, ал Салават күперен.

*Төсле биш тасманы Урман кызына бирә.*

**Барысы бергә.** Яхшылыкка ни җитә?
Татулыкка ни җитә?
Дуслар белән күңелле,
Дус булуга ни җитә?

**Урман кызы.** Яхшылыкка юк киртә.
Татулыкка ни җитә?
Дуслар белән күңелле,

Дус булуга ни җитә?
*Р. Корбан сүзләренә «Дуслар җыры», күмәк бию.*
Дуслар белән күңелле,
Яшәве рәхәт.
Дустым булганың өчен
Сиңа зур рәхмәт.
Син – минем якын дустым,
Мин – синең дустың.
Яхшы һәрвакытта да
Булганы дусның.
Безнең дуслык нык булсын,
Мәңгелек булсын.
Көннәребез гел шулай
Шатлыкта узсын!

**Алып баручы.** Афәрин! Кечкенә артистларыбыз! Сез бик матур әкият күрсәттегез. Бүгенге бәйрәмдә барыгыз да бик актив булдыгыз, сөекле шагыйребез Габдулла Тукайны яратуыгызны тагын бер тапкыр исбатладыгыз. Без, тәрбияче апаларыгыз, әти-әниләрегез, сезгә гомерегез буе бөек Тукаебыздан аерылмавыгызны телибез. Милли җанлы, милли рухлы булып үсәсегез килсә, Тукаебызның үлмәс әсәрләрен укудан туктамагыз!

*Апушлар килә.*
Моңлы халкы күңеленнән
Моңнар алган,
Каз каурыйлы каләменнән
Акыл тамган.
Җилекләргә кадәр үткән
Туры сүзе,
Кан йөгерткән, тетрәндергән
Чәчәнлеге.
Әткә-әнкә каны белән
Күчкән зиһен.
Затлы нәсел – шуны аңлау
Кыен түгел.
Күтәрелгән һәм күтәргән
Халкы аны.
Мәңге яшәр Мәңгелектә
Шагыйрь улы.
Апушларың тел өйрәнә
Шигырь тыңлап,
Милләтпәрвәр булмакчылар
Синең сымак.
Телебезне, илебезне,
Динне зурлап,
Яшәсеннәр Тукай телле
Гимн җырлап.

*Надия Вәлиева*

*Бәйрәм «Туган тел» җыры белән тәмамлана.*

**Файдаланылган әдәбият**

Г. Тукай әдәби музее альбомы, брошюралары, открыткалары.
Г. Тукай. Бала белән күбәләк. – Казан: ТКН, 1996.
Г. Тукай. Забавный ученик.– Казань: ТКН, 1983.
Г. Тукай. Кәҗә белән Сарык әкияте.– Казан: ТКН, 1991.
Г. Тукай. Су анасы.– Казан: ТКН, 1985.
Г. Тукай. Шүрәле. – Казан: ТКН, 2024.
Г. Тукай. Шүрәле. – Казан: «Мы и наше дело» нәшрияты, 1999.
Латышина Д.И. По берегам Идели. – Москва: изд.-во «Центр гуманитарного образования».
«Тылсымлы сәхифәләр», Г.Тукай шигырьләре.– Казан: «Татармультфильм», 2012.
Тукай темасына кагылышлы «Салават күпере» журналлары.
Шигырьләр, поэмалар. Тукай. – Казан: ТКН, 1987.

7



**Алсу ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**

Казандагы 117 нче балалар бакчасының
югары квалификация категорияле
татар теле тәрбиячесе

МӘКТӘПКӘЧӘ ТӘРБИЯ

# КЫСТЫБЫЙ БӘЙРӘМЕ

(Мәктәпкәчә әзерлек төркеме өчен көзге уңыш бәйрәме)

ИСТӘЛЕК

*1993 елны институтка укырга килгәч, мин авыл баласын Пушкин урамындагы тулай торакка урнаштырдылар. Дүрт кыз җыелышып, дуслашып беткәч, бүлмәбезне обойларга булдык. Туксанынчы елларда без авыл балаларына обой каян килсен, артык акчасы да юк. Лидиябез район җиреннән, аларда калган обой табылды. Матур итеп ябыштырып чыктык, бүлмәгә ямь кереп китте. Арып-талып, эшләгән эшебездән канәгать булып, йокларга яттык.*

*Төнлә белән сәер тавыштан уянып китеп, күзләребезне ачсак, стена безнең өскә таба авыша иде. Көчкә ут яндырып карасак, бер стенадагы обойлар яртылаш кубып төшкән булып чыкты. Әллә иске обойлар өстенә ябыштырган ярамаган, әллә тәрәзә ачылган, бусы мөһим түгел. Мөстәкыйль тормышка менә шулай да өйрәтте безне тулай торак.*

**Максат:** татар милли аш-суы (кыстыбый) белән таныштыру, көзге уңыш бәйрәме «Сөмбелә» рухында шатлыклы мохит тудыру.

**Бурычлар:**
***1. Тәрбияви:*** татар халкының милли традицияләренә, аш-су мәдәниятенә карата кызыксыну тәрбияләү, хезмәткә һәм уңышка хөрмәт тәрбияләү.
***2. Үстерүче:*** балаларның актив сүзлек запасын баету (көз, уңыш, бәрәңге, кыстыбый, камыр, эчлек һ.б.), иҗади сәләтләрен, кул моторикасын үстерү.
***3. Белем бирү:*** балаларны көзге уңыш бәйрәме «Сөмбелә» һәм татар ризыгы «Кыстыбый» белән таныштыру, кыстыбый ясау технологиясе турында төшенчә бирү.

**Алдагы эш:** «Көз», «Уңыш» темаларына әңгәмә, бәрәңге турында табышмаклар, «Сөмбелә» бәйрәме турында презентация карау.

**Җиһазлау:** көзге бизәкләр, бәрәңге сурәтләре, 2 кәрзин, кашыклар, бәрәңге (уен өчен), кыстыбый өчен әзер юка һәм эчлек, пластилин яки төсле кәгазь, мультимедиа, кечкенә туп (яки йомшак бәрәңге уенчыгы).

**Бәйрәм барышы**
**1. Кереш өлеш (5 мин)**
**Тәрбияче.** Исәнмесез, балалар! Бүген без сезнең белән матур көзге бәйрәмгә җыелдык. Бәйрәмебез «Кыстыбый» дип атала. Бәрәңгегә багышланган бәйрәм ясыйбыз.

– Бәрәңге турында нәрсә беләсез? *(Балаларның җаваплары.)*

Көз турында әңгәмә.

– Хәзер елның кайсы вакыты? *(Көз.)*

– Көзнең нинди айларын беләсез? *(Сентябрь, октябрь, ноябрь.)*

– Көзнең безгә нинди байлыклары бар? *(Уңыш.)*

«Сөмбелә» бәйрәме белән таныштыру.

– Борынгы татар халкы, көзге уңышны җыйганнан соң, «Сөмбелә» бәйрәмен уздырган. Бу көнне алар уңышларына шатланган, кунак чакырган, төрле милли ризыклар пешергән.

**2. Төп өлеш. (20 минут)**
**Хәрәкәтле уен: «Бәрәңге бәйрәме» (5 мин)**
*Балалар түгәрәккә баса. Тәрбияче беренче юлны әйтә, балалар кабатлыйлар һәм хәрәкәтләр ясыйлар.*

1 нче куплет:
Көз җитте, көз җитте.
*(Кулларны өскә күтәреп, ян-якка болгыйлар – «җил исә».)*
Бәрәңге безгә килде.
*(Алга бер адым атлыйлар, куллары белән түгәрәк күрсәтәләр.)*
Чистартык та юдык без,
*(Уң кул белән сул кулны ышкыйлар.)*
Табага салып кыздырдык.
*(Ике кулны алга сузып әйләндерү хәрәкәте – «таба боргалыйлар.)*

Кушымта *(2 тапкыр):*
Бәрәңге, бәрәңге,
*(Кул чабалар.)*
Тәмле бәрәңге!
*(Кулны алга сузып, баш бармакны күрсәтәләр.)*
Ашап бетереп булмый,
*(Корсакка кулны куялар.)*
Яратабыз без аны.
*(Ике кулны күкрәккә куеп – «ярату» хәрәкәте.)*
2 нче куплет:
Кыстыбый эченә салдык,
*(Кул белән «салу» хәрәкәте ясыйлар.)*
Май белән майлап алдык.
*(Бер кулны икенче кул белән «майлау» хәрәкәте.)*
Чәй белән бергә ашыйбыз,
*(Чәйне эчкән кебек хәрәкәт, аннары ашаган хәрәкәт.)*
Бәйрәм итеп алабыз!
*(Әйләнеп, кул чабалар.)*
Кушымта *(кабатлана, хәрәкәтләр шул ук).*

**Уен-эстафета: «Уңыш җыю» (5 минут)**
*Балалар ике командага бүленә. Идән өстенә төрле яшелчәләр (бәрәңге, кишер, кәбестә, кыяр) сибелә. Сигнал буенча, балалар, берәр яшелчәне алып, команданың кәрзиненә салалар. Җиңгән команданы мактау. Яшелчәләрнең исемнәрен татарча кабатлау: бәрәңге, кишер, кәбестә, кыяр.*

**Өстәмә.** Бәрәңгене кашыкта күчерү *(кыенрак вариант, вакыт калса).*
**Яки хәрәкәтле уен: «Кайнар бәрәңге» (5 минут)**
*Балалар зур түгәрәккә басалар. Кулларына бер «бәрәңге» (кечкенә туп яки бәрәңге сыман йомшак уенчык) бирелә. Татар халык көе (гармун яки язма) уйный башлый. Балалар бәрәңгене тиз-тиз бер-берсенә тапшыралар, аны кулда тотып калмаска тырышалар. Музыка кинәт туктагач, кулында бәрәңге калган бала түгәрәк эченә утыра (яки бер адым артка чыга). Уен кабатлана. Соңында эчтә утырган балаларны читтәгеләр кулларын сузып «коткаралар» (яки аларга кечкенә приз бирелә).*
***Өстәмә кыенлаштыру.*** *Бәрәңгене баш өстеннән яки аяк арасыннан тапшырырга була.*

**1 нче вариант. Кыстыбый тарихы һәм ясау (10 минут)**
**Тәрбияче.** Без бәрәңге уңышын җыйдык, ә хәзер аны ничек әзерләргә? Татар халкы бәрәңгедән төрле ризыклар ясый. Иң популярларының берсе – кыстыбый.
*Кыстыбый турында сөйләү.*
Бу – камырдан ясалган яссы коймак, эченә бәрәңге боламыгы (пюре) салына. «Кыстыбый» сүзе «кыстыру»дан килеп чыккан, чөнки камыр эчлекне «кыстырып» тота.
*Мастер-класс (күрсәтү):*
– әзер юканы тарату;
– эченә бәрәңге боламыгы салу;
– икегә бөкләп, май ягу.

**2 нче вариант. Кыстыбый турында әкият + күрсәтү (10 мин)**
***Әкияттән соң фикер алышу:***
***Күрсәтү.*** *Кыстыбый ясау. Мөмкинлек булса, балалар белән чын кыстыбый ясау яки пластилиннан яки кәгазьдән кул эшләнмәсе ясарга була.*
Алдан пешерелгән юкаларны балаларга тарату.
Эченә бәрәңге боламыгын салу.
Икегә бөкләү, май сөртү.
Балаларга ярдәм итү. *(Ата-аналар ярдәменнән файдаланырга була.)*

**3. Йомгаклау. Чәй табыны (5 мин)**
**Тәрбияче.** Без бүген нинди бәйрәмдә булдык? Нинди милли ризык белән таныштык? Кыстыбый эченә нәрсә салалар? Кемнәр бәрәңгене ярата? *(Балалар җавап бирә.)* Кунаклар белән бергә кыстыбый һәм чәй эчү. *(Әгәр мөмкинлек булса, әзер кыстыбыйны пешереп, балалар белән бергә ашау.)*
*Бәйрәмне йомгаклап, балалар «Көз» турында шигырьләр сөйли яки «Бәрәңге бәйрәме» җырын кабатлый.*

8



**Рүзия ГЫЙМРАНОВА,**

Казандагы 166 нчы балалар бакчасының
I квалификация категорияле
татар теле тәрбиячесе

# БҮЛӘКНЕ КЕМ КАЛДЫРГАН?

(Өлкәннәр төркеме өчен квест-уен)

МӘКТӘПКӘЧӘ ТӘРБИЯ

ИСТӘЛЕК

*Студент еллары – һәр кешенең тормышында иң бәхетле, онытылмаслык чор. Казан дәүләт педагогика университетында укыган елларым, аеруча Пушкин урамындагы тулай торакта үткән көннәрем күңелдә мәңге сакланачак. Төрле район-авыллардан җыелган булсак та, тулай торак безнең өчен уртак йортыбызга әйләнде. Кызлар белән тулай торакта бик тату, дус яшәдек. Сессия вакытларында имтиханнарга бергә әзерләндек, кичләрен бүлмәдән бүлмәгә чәй эчәргә йөри идек, анда һәркем өеннән килгән күчтәнәчне өстәлгә чыгара иде.*

*Тулай торакның мәдәни тормышы да искиткеч бай булды. Актлар залында узган бәйрәмнәрне, «дискәтүкләрне» түземсезлек белән көтеп ала идек. Бәйрәмгә сценарийлар яза, үзебез костюмнар әзерли идек. 2 нче курста укыган чакта, «Аулак өй» күренешен әзерләдек. Ул вакытта әбиләрнең ничә ел сандыкта яткан киемнәре эшкә җигелде. Бик матур, истәлекле кичә булды ул.*

*Тулай торакта үткән студентлык еллары безгә ныклы дуслык, тормыш тәҗрибәсе, онытылмаслык мизгелләр бүләк итте. Шул елларда туган дуслык бүген дә дәвам итә.*

**Максат:** уенлы биремнәр аша балаларның татар телендәге башлангыч белемнәрен ныгыту һәм активлаштыру, татарча сөйләм күнекмәләрен үстерү, балаларда командада эшләү, бер-берсенә ярдәм итү һәм җаваплылык хисе тәрбияләү.

**Бурычлар:**

***Белем бирү бурычлары:***

– предметны, аның билгесен һәм хәрәкәтен белдергән сүзләрне балаларның сөйләмендә активлаштыру;

– рәсемнәр ярдәмендә гади җөмләләр төзү күнекмәсен ныгыту;

– татар телендәге көндәлек сүзләрне һәм гыйбарәләрне дөрес кулланырга өйрәтү.

***Үстерү бурычлары:***

– бәйләнешле диалогик сөйләмне, мәгънәгә туры килгән сүзләрне сайлап алу сәләтен үстерү;

– хәтер, игътибар, фикерләү сәләтен камилләштерү;

– биремнәрне мөстәкыйль башкару күнекмәләрен ныгыту;

– төрле аралашу ситуацияләрендә яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән татар телендә сөйләшергә кызыксыну уяту.

***Тәрбия бурычлары:***

– иптәшләренең җавапларын игътибар белән тыңларга, кирәк булганда аларны әдәпле итеп төзәтергә өйрәтү;

– хезмәттәшлек итү, мөстәкыйльлек, сабырлык һәм дуслык сыйфатларын тәрбияләү;

– татар телен өйрәнүгә кызыксыну арттыру.

**Белем бирү өлкәләрен интеграцияләү:** социаль-коммуникатив, танып белү, нәфис-сәнгать үсеше.

**Җиһазлар:** конвертлар, төрле төстәге түгәрәкләр төшерелгән келәм, тартма, курчак, интерактив такта, рәсемнәр һәм пиктограммалар, яулык, пазл, кечкенә чемодан, Песи Мияу һәм Акбай образлары.

**Шөгыль барышы**

**I. Оештыру өлеше**

– Хәерле көн, дуслар! Хәлләрегез ничек? Балалар, бүген безгә кунаклар да килгән. Әйдәгез, алар белән танышыйк. Үзебез турында сөйләп күрсәтик.

*Тәрбияче туп яки микрофон ярдәмендә «Син кем?» дигән сорау бирә.*

– Син кем?

– Мин – Илария, матур кыз.

– Мин – Наил, батыр малай.

*Балалар тупны яки микрофонны бер-берсенә тапшырып, сорауларга җавап*

*бирәләр. Шул вакытта елаган тавыш ишетелә.*

– Балалар, миңа кемдер елый кебек тоела. Әйдәгез, кем икәнен белик.

– Кем анда?

*Залның бер читендә урнаштырылган өйчек яныннан Песи Мияу күренә.*

– Бу мин – Песи Мияу.

– Песи Мияу, син нигә елыйсың?

– Минем туган көнем булды. Бик матур бүләк бирделәр, ләкин аны кем калдырганын белмим. Бүләк янында зур конверт кына бар. Ә мин укый белмим. Балалар, миңа ярдәм итмәссезме?

– Әлбәттә, ярдәм итәбез!

*Тәрбияче конвертны ала һәм андагы хатны укый.*

– «Сезгә бик катлаулы биремнәрне үтәргә кирәк булачак. Аларның барысын да уңышлы үтсәгез, бүләкне кем калдырганын белерсез. Табышмакларга игътибар белән иярегез!»

– Ничек уйлыйсыз, дуслар, сез Песи Мияуга ярдәм итәргә әзерме?

– Әйе.

**II. Төп өлеш**

**1 нче бирем. Төсле келәм.**

*Тәрбияче конверттан беренче табышмакны ала.*

– Диварда эленеп тора, урамга карап тора, эчкә таба ачыла, кышын бизәккә төренә.

– Тәрәзә!

– Дөрес. Димәк, киләсе биремне тәрәзә янында эзләргә кирәк.

*Балалар тәрәзә яныннан тартма табалар. Тартма эчендә төрле төстәге түгәрәкләр төшерелгән келәм була.*

– Балалар, монда безне яңа бирем көтә икән. Әйдәгез, «Төсле келәм» уенын уйнап алыйк.

*Балалар келәм тирәли утыралар. Келәмдә төрле төстәге түгәрәкләр урнаштырылган. Бер бала бер түгәрәккә баса һәм шул төсне белдергән сүзтезмә әйтә. Мәсәлән, кызыл түгәрәккә басса:*

– Кызыл күлмәк.

– Кызыл алма.

*Бернichә сүз әйткәч, ул уенны дәвам итү өчен чиратны икенче балага тапшыра.*

– Наил, сикер!

*Уен барлык балалар катнашып чыкканчы дәвам итә.*

– Молодцы, балалар! Беренче биремне дә уңышлы үтәдегез.

**2 нче бирем. Җөмлә төзе.**

*Тәрбияче чираттагы табышмакны укый.*

– Балалар аны ярата, «Йокла, бәләкәй», – дип юата. Аның белән уйныйлар, үскәч, аны оныталар.

– Курчак!

– Дөрес.

*Балалар кулында конверт булган курчакны эзләп табалар. Конверт эчендә чираттагы бирем: «Җөмлә төзе». Балалар парлап интерактив такта янына чыгалар. Аларга төрле рәсемнәр һәм пиктограммалар тәкъдим ителә. Балалар рәсемне карыйлар, тиешле сүзләрне сайлыйлар һәм аларны дөрес тәртиптә урнаштыралар. Аннан соң җөмләне татар телендә әйтәләр.*

***Бирем үрнәкләре:***

1. Красивая девочка, на съешь красное яблоко! *(Матур кыз, мә, кызыл алма аша!)*

2. Мама, на одень красивое красное платье! *(Әни, мә, матур, кызыл күлмәк ки!)*

3. Большая собака, съешь 2 вкусных хлеба! *(Зур эт, ике тәмле ипи аша!)*

4. Бабушка, дай мне, зелёную, красивую, чистую чашку! *(Әби, яшел, матур, чиста чынаяк бир әле!)*

– Булдырдыгыз, балалар! Бу биремне дә уңышлы үтәдегез. Ә хәзер алга таба юл тотыйк.

**3 нче бирем. Рәсем буенча җөмлә төзе.**

*Тәрбияче чираттагы табышмакны укый.*

– Тышы ябылган, эче тулы белем. Аны ачкан кеше күп нәрсә белә.

– Китап!

*Балалар китап почмагыннан чираттагы конвертны табалар. Конверт эчендә «Рәсем буенча җөмлә төзе» дигән бирем була. Балалар өстәл артына утыра. Аларга төрле рәсемнәр һәм пиктограммалар тәкъдим ителә. Һәр бала, рәсемгә карап, мөстәкыйль рәвештә җөмлә төзи һәм аны татар телендә әйтә.*

– Афәрин, балалар! Сез бу биремне дә бик яхшы үтәдегез. Ә безне әле тагын бер сынау көтә.

**4 нче бирем. «Яулык салыш» татар халык уены.**

– Балаларның борынын сөртә, кесәдә һәрчак йөри. Аны онытып калдырсаң, кирәк чакта бик авыр.

– Яулык.

– Дөрес. Әйдәгез, төркемнән яулыкны эзләп табыйк.

*Балалар яулыкны табалар.*

– Безнең алда яулык белән бәйле тагын бер кызыклы бирем бар. Яулык белән нинди татар халык уенын беләсез?

– «Яулык салыш».

– Әйе, бик дөрес. Әйдәгез, кем беренче башлаячагын санамыш ярдәмендә ачыклыйк.

**Бала.** Әке, бәке, кыек сәке, эремчек, син торып тор, энем, чык!

*Балалар түгәрәккә басалар. Бер бала кулына яулык ала. Уен барышында балалар түгәрәк буенча йөреп җырлыйлар.*

Кулъяулыгым яшел, яшел,
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.

*Уен татар халык уены кагыйдәләре буенча дәвам итә.*

– Булдырдыгыз, балалар! Конвертта тагын бер соңгы табышмак калды.

**5 нче бирем. Табышмакны чиш.**

*Тәрбияче табышмакны укый.*

– Язу өчен дә була, ашар өчен дә була. Эшләгәндә дә кирәк ул, ансыз бик кыен була. Нәрсә ул?

– Өстәл!

– Дөрес.

*Балалар бүлмәдә өстәлне эзлиләр. Өстәл астыннан яки шкаф эченнән кечкенә чемодан табалар.*

– Ура! Таптык! Ләкин чемоданны ничек ачарга икән? Ул гади генә ачылмый бугай. Бәлки, татар телендә әдәпле сүзләр әйтеп карарбыз.

– Исәнмесез! Хәерле көн! Рәхмәт! Зинһар өчен! Сау булыгыз!

*Чемодан ачыла.*

– Карагыз әле, дуслар! Без барыбыз бергә биремнәрне үтәп чыктык һәм чемоданны да ачтык. Ә анда нәрсә бар икән?

– Пазллар.

– Әйдәгез, пазлны бергәләп җыеп карыйк. Бәлки, бүләкне кем калдырганын шулай белербез?

*Балалар интерактив тактада пазл җыялар. Пазл җыелып беткәч, Акбай рәсеме килеп чыга.*

– Балалар, бу кем?

– Эт – Акбай!

– Дөрес! Молодцы! Песи Мияу, хәзер син бүләкне кем калдырганын беләсең.

– Балалар, сезгә зур рәхмәт! Миңа бик ярдәм иттегез. Ә хәзер мин сезнең белән саубуллашам. Сау булыгыз!

– Сау бул, Песи Мияу!

**III. Йомгаклау өлеше**

– Дусларым, бүгенге квест-уен сезгә ошадымы?

– Без бүген нинди яхшы эш башкардык?

– Песи Мияуга ничек ярдәм иттек?

– Бүген өйрәнгән сүзләребезне кемгә сөйләп бирә аласыз?

*Балалар үз фикерләрен әйтәләр.*

– Дусларым, бүген сез бик тырыш булдыгыз. Барлык биремнәрне дә бергәләп, дус һәм тату булып үтәдегез. Бер-берегезгә ярдәм иттегез, татарча матур сөйләшергә тырыштыгыз. Афәрин!

– Сау булыгыз, дусларым!

– Сау булыгыз!

МӘКТӘПКӘЧӘ ТӘРБИЯ

9



**Эльмира ШАКИРОВА,**

Казандагы 36 нчы балалар бакчасының
I квалификация категорияле
татар теле тәрбиячесе

# КУЛЪЯУЛЫК – ВӘГЪДӘ БИЛГЕСЕ

(Өлкәннәр төркеме өчен татар теле буенча театральләштерелгән шөгыль)

ИСТӘЛЕК

*1998 елның сентябрь ае... Әле дә бүгенгедәй исемдә... Укырга мин 2 сентябрь көнне генә килдем. Чөнки 1 е бик каты суык тиеп, бераз температура белән ятарга туры килде. 2 сентябрь көнне иң беренче булып деканатка менеп, кайсы группага эләгүемне белештем. Һәм расписание буенча аудиториягә юл тоттым. Дәрес (пар) башланган иде. Кыңгырау шалтыраганга 10 минут узгандыр. Тиз генә ишекне ачтым да «Здравствуйте!» дип кереп бастым. Бар студентлар торып басып, шулай ук сәламләделәр. «Мине сезнең группага җибәрделәр, сезнең белән укыячакмын», – дидем. Барысы да шаркылдашып көлеп җибәрде. «Куркыттың, укытучы керде дип уйладык», – диештеләр. Алгы партадагы буш урынга мин дә утырдым. Таныштык. Якташым – Балык Бистәсе кызы Алсу Гарифуллина белән аннан соң гел бергә булдык.*

**Шөгыльнең максаты:** балаларда татар халкының милли мәдәнияте, гореф-гадәтләре һәм әдәп-әхлак кыйммәтләре турында күзаллау формалаштыру; татар телендә аралашу күнекмәләрен үстерү һәм туган телгә кызыксыну тәрбияләү.

***Алдан үткәрелгән эш:*** татар халык киемнәре, чигелгән кульяулыклар, сөлгеләр белән танышу; татар халык җырларын тыңлау һәм өйрәнү; милли уеннар уйнау; «Кызлар нинди була?», «Егетләр нинди була?» темаларына әңгәмәләр үткәрү; татар халкының кунакчыллыгы, кул эшләре һәм милли бизәкләре турында сөйләшү.

***Җиһазлар:*** татар милли киемнәре, чигелгән кульяулыклар, сандык, чигү үрнәкләре, милли бизәкләр, өй күренешен чагылдыручы атрибутлар, уенчыклар, музыка язмалары.

**Шөгыль барышы**

*Зал татар авылы йорты итеп бизәлгән. Бер читтә сандык, чигелгән сөлгеләр, кульяулыклар. Әби белән бабай капка төбендә сөйләшеп утыралар.*

**Әби.** Картым, кара әле, кем малае китә анда бүген солдатка?

**Бабай.** Ник, син ишетмәгән идеңмени? Югары очның Марат малаен озаталар ди бит бүген. Солдатка китәм дип әйтә, ди.

**Әби.** Аның шундый зур малае бармыни?

**Бабай.** Иии, син бигрәк артта калгансың икән бит, карчык. Бар инде, ник булмасын.

**Әби.** Әй, гомернең узулары диген… Без картаймый кем картайсын.

**Бабай.** Илләр, көннәр тыныч булсын! Исән-сау әйләнеп кайтсын балалар.

**Әби.** Әйе… Яшь чаклар искә төшә инде. Без дә шулай җырлашып, уеннар уйнап, бер-беребезгә бүләкләр бирә идек.

**Бабай.** Әйе, ул чакта һәр бүләкнең үз мәгънәсе булган. Кульяулык та гади генә әйбер түгел иде.

**Әби.** Дөрес әйтәсең. Кульяулыкны кызлар үз куллары белән чигә. Аңа күңел җылысын, матур теләкләрен сала.

**Бабай.** Әйдә, карчык, балаларга да күрсәтик әле безнең матур йолаларыбызны.

*Музыка яңгырый. Өй күренеше. Кызлар түгәрәкләнеп, җырлашып утыралар. Алар кульяулык чигәләр, сөйләшәләр.*

**1 нче кыз.** Резедә, синең кульяулыгың бигрәк матур килеп чыккан.

**2 нче кыз.** Әйе, карагыз әле, нинди матур чәчәкләр чигелгән!

**Резедә.** Рәхмәт, кызлар. Тырышам инде, кызлар. Солтанга бүләк кульяулык бит бу. Ә сез беләсезме соң кайдан килгән бу йола?

**3 нче кыз.** Ә син беләсеңме, Резедә, ни өчен элек кызлар кульяулык чиккәннәр?

**Резедә.** Беләм. Кулъяулык – матур теләк, күңел җылысы һәм хөрмәт билгесе.

**1 нче кыз.** Дөрес. Кызлар чигү чигәргә, тегәргә, бәйләргә өйрәнгәннәр. Һәр эшне ятатып һәм пөхтә итеп башкарганнар.

**3 нче кыз.** Исән-имин йөреп кайтсын инде, Солтан.

**2 нче кыз.** Әйдәгез, Резедә, җырлап та алыйк.

*Резедә яки кызлар башкаруында «Чияләр чәчәк ата» җыры яңгырый.*

**Резедә.** Кызлар, ишетәсезме? Ниндидер тавышлар килә!

**2 нче кыз.** Әллә егетләр киләме?

*Егетләр тавышы ишетелә. Резедә тәрәзәгә килеп карый.*

**Резедә.** Киләләр, кызлар, киләләр.

*Музыка астында егетләр керә.*

**Егетләр.** Исәнмесез, кызлар. Менә без дә килеп җиттек.

**1 нче кыз.** Түрдән узыгыз! Безнең кулъяулыкларыбыз әзер. Бик тырышып чиктек.

*Егетләрнең муенына кулъяулыкларны бәйлиләр. Иң соңгы итеп кулъяулыгын Резедә бәйли.*

**Солтан.** Кулъяулыклар? Нинди матурлар!

**Резедә.** Без аларны үз кулларыбыз белән чиктек. Һәрберсенә матур теләкләр теләп бизәдек.

**Егетләр.** Рәхмәт сезгә! Мондый бүләкне саклап йөрербез.

**Резедә.** Бу – сиңа бүләгем. Аны һәрвакыт сакла.

**Солтан.** Саклармын. Ә мин сиңа сүз бирәм: дуслыгыбызны кадерләрмен, һәрвакыт ярдәм итәргә тырышырмын.

**Резедә**. Мин дә дуслыгыбызны сакларга сүз бирәм.

**Бабай.** Менә шулай, балалар. Татар халкында кулдан эшләнгән бүләк аеруча кадерле булган. Чөнки аңа кешенең хезмәте генә түгел, күңел җылысы да салынган.

**Әби.** Кызлар – уңганлыклары белән, егетләр әдәплелеге һәм сүзендә торуы белән матур.

*Кави Нәҗминең «Җиңеп кайт!» шигырен укыйлар.*

**1 нче кыз.**
Чулпан калка, таң ата,
Кыз сөйгәнен озата,
Исән барып, исән кайт,
Дошманнарны җиңеп кайт!

**Резедә.**
Теләр идем тагын да,
Бик сагынган чагында,
Язып җибәр сәлам хат!
Сау бул, җиңеп кайт!

**Солдат.** Вәгъдәме?

**Резедә.** Вәгъдә! Тыныч хезмәт ит, ярыймы?

*Вәгъдәләшкәч, җырлашып чыгып китәләр. Кызлар озатып калалар.*

**Егетләр.**
Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде солдатка.
Мин китәм инде солдатка,
Сүз бирдек ташлашмаска.

**Солтан.** Сау булыгыз, туганнар, дуслар!

**Барысы.** Сау бул, исән-сау әйләнеп кайт!

*Ахырда татар халык көе яңгырый. Балалар милли бию хәрәкәтләре белән бию башкаралар.*

***Методик искәрмә.** Шөгыльне театральләштерелгән формада үткәрү балаларның татар телендә иркенле аралашуына, сәнгатьле сөйләменә һәм милли мәдәният белән эмоциональ бәйләнешенә уңай йогынты ясый. Сюжетта кулъяулык образы төп символ буларак алына: ул хезмәт сөючәнлек, күңел җылысы, изге теләк һәм дуслык билгесе буларак ачыла. Бу алым балаларга милли традицияләрне коры мәгълүмат рәвешендә түгел, ә эмоциональ-сәнгати образлар аша кабул итәргә мөмкинлек бирә.*



**Алия БОРҺАНЕТДИНОВА,**
Апас районы Табар Черкене урта мәктәбенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

10

# Фәнис Яруллинның «Зәңгәр күлдә Ай коена» әкияте

(4 нче сыйныфта әдәбият дәресе)

ИСТӘЛЕК

*Татфакта 1998–2003 еллар арасында укыдым. Төркем җитәкчебез Мулланур Гаян улы Габитов иде. Бу исемне ишеткәч, әлбәттә, хор искә төшә. Хор – үзе бер тормыш мәктәбе ул! Авылдан чыккан кыюсыз балалар кеше арасына кердек, үзебезне күрсәтергә өйрәндек. Ә чыгыш ясаулар, репетицияләр! Казанның без аяк басмаган берәр сәхнәсе калды микән? Иң күп чыгышлар шунда булгач, Камал, Тинчурин, Җәлил театрларының һәр почмагын ятлап бетердек, артистлар белән аралаша торгач, дуслашып ук беттек. Һичшиксез, педагогика университеты безгә күпне бирде: белем, тәрбия, тормыш тәҗрибәсе, яңа дуслар... Еллар узгач, инде тәҗрибәле укытучы буларак, мин моңа һаман саен төшенәм. Горурланам, мөгаллимнәребезгә олы рәхмәтемне җиткерәм!*

**Максат:** Фәнис Яруллинның «Зәңгәр күлдә Ай коена» әкиятенә гади анализ ясау төре белән танышуны дәвам итү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Предмет нәтиҗәләре:*** Фәнис Яруллинның «Зәңгәр күлдә Ай коена» әкиятен аңлап уку, эчтәлеген һәм төп идеясен билгеләү, әсәрне өлешләргә бүлеп анализлау күнекмәсен камилләштерү.

***Метапредмет нәтиҗәләр:*** үз фикерен дәлилләп әйтү, сорауларга тулы җавап бирү, сүзлек белән һәм төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшләү күнекмәләрен үстерү.

***Шәхси нәтиҗәләр:*** яхшылык эшләү, ярдәмчел һәм игелекле булу, кешенең эчке матурлыгын бәяли белү сыйфатларын формалаштыру.

**Бурычлар:**

1. Әсәрне аңлап һәм йөгерек уку күнекмәләрен, фикерләү сәләтләрен һәм сөйләм телләрен үстерү.
2. Бер-береңә, таныш түгел кешеләргә ярдәм итү теләге уяту, яхшылыкның яхшылык булып кайтуына инандыру, ярдәмчел булу сыйфатлары тәрбияләү.
3. Сүзлек белән эшләү, сөйләм телен үстерү.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне ачу дәресе (дәрес-дискуссия).

**Җиһазлау:** ЦЭР, Ф. Яруллин портреты, Ф. Яруллинның «Зәңгәр күлдә Ай коена» һәм төрле елларда басылган китапларыннан күргәзмә, презентация.

**Дәрес этаплары:**

**Мотивация**

– Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн! Барыгыз да күргәнегезчә, тышта яз ае. Җиһан ак төстәге шомырт чәчәкләренә күмелгән. Бар җирдә аклык, сафлык хөкем сөрә. Менә шушы аклыкның, сафлык нурларының күңелләрегезгә иңүен телим, балалар. Күңелегез чиста һәм пакь булсын! Әйдәгез әле, бер-беребезгә елмаю бүләк итик һәм дәресебезне башлап җибәрик. *(Укучыларның үз фикерләре белән уртаклашуы, иптәшләрен сәламләү.)*

**Актуальләштерү**

– Без сезнең белән алдагы дәрестә татар шагыйре, язучы һәм драматург Фәнис Яруллинның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштык. Сезгә өй эше итеп әдипнең «Зәңгәр күлдә Ай коена» әсәрен укып килергә иде.

– Әкиятне игътибар белән укыдыгызмы?

– Әйдәгез, өй эшен тикшерү максатыннан, тест эшләп алабыз. Тест эшләнелә. *(2 нче слайд)*, үзбәя *(3 нче слайд). (Сөйләшүдә катнашу. Тест биремнәре үтәү.)*

**Яңа материалны аңлату**

– Укучылар, әйдәгез әле, әкияттәге геройларны санап китик.

*(Әкияттәге персонажларны санату рәсемнәре 4 нче слайдта чыга бара.)*

– Әкияттәге төп геройның исемен атагыз. *(Ай.)*

– Әкиятнең исемендә Ай ни өчен баш хәреф белән язылды икән?

*(Ялгызлык һәм уртаклык исемгә караган кагыйдәләрне искә төшерү.)*

– Икенче герой нәрсә? *(Җил.)*

– Алдагы герой нәрсә? *(Сукыр тычкан.)*

– Иң беренче булып Айның тавышын нәрсә ишеткән? *(Чуртан.)*

– Чуртаннан соң Айның тавышын нәрсә ишетеп килгән? *(Гөберле бака.)*

– Айга кем ярдәм иткән? *(Айсылу.)*

– Укучылар, игътибар иттегезме Җил, Сукыр тычкан, Чуртан, Гөберле баканы сораганда, нәрсә? соравы куйдым, ә Айсылуны әйткәндә, кем? дип әйттем. Ни өчен мин барысына да бер сорауны куймадым?

*(Татар телендә кешеләргә генә кем? соравы куела, рус телендә барлык җан ияләренә кто? соравы бирелә.)*

– Афәрин, укучылар, бу кагыйдәне дә онытмагансыз.

– Укучылар, әйтегез әле, ни өчен автор әкиятне «Зәңгәр күлдә Ай коена» дип атаган?

*(Чөнки әкияттәге вакыйгалар Зәңгәр күлдә бара һәм Ай белән бәйле.)*

– Ә хәзер әкиятебез белән эшне дәвам итәбез. Әсәрне ничә өлешкә бүлеп була? *(Өч.)*

– Ни өчен шулай бүлдегез? Аларны ничек атадыгыз? *(5 нче слайд. Телдән әңгәмә кору.)*

**Материалны беренчел ныгыту**

– Дөрес, рәхмәт, ә хәзер без парларда биремнәр үтәрбез.

***Мөстәкыйль эш:*** 1 нче өлешне кыскача сөйләп чыгалар. Сүзлек белән эш: чуртан, бака ефәге, әчке матурлык сүзләренә тукталу һәм аңлату, язып алу башкарыла.

***Анализлау өчен куелган сораулар:***

а) Айның ничек коенуын сурәтләгән җөмләләрне табып укыгыз. Ни өчен коена, сәбәбен күрсәтегез. Нинди нәтиҗә ясап була? *(Ул чисталыкны ярата, чөнки Ай якты булырга тиеш.)*

ә) Ай тагын ниләр эшли? Ни өчен? *(Төнбоеклар җыеп, күккә алып менеп сибә. Алар йолдызларга әйләнә. Йолдызлар күп булгач, тагын да якты була.)*

б) Ай ни өчен кирәк? *(Төрле җаваплар: күчмә кошларга юл күрсәтә, океан-диңгез суларының хәрәкәте белән идарә итә, төнлә яктырту өчен кирәк.)*

*2 нче өлешнең кыскача эчтәлеген сөйләтү.*

***Анализлау өчен куелган сораулар:***

а) Ай ни өчен бата башлый? Сәбәбе нәрсәдә? *(Сукыр тычкан җилне уятты, җил – камышларны, камышлар – дулкынны, дулкын бака ефәген ярга чыгарды. Ул Айны әйләндереп алды.)*

ә) Нәтиҗә нинди? *(Ай бата башлады.)*

б) Бу өлеш беренчесеннән ни белән аерыла? *(Беренче өлештә матурлык турында сөйләнә, монда куркыныч бар: Ай батарга мөмкин.)*

в) Нишләргә? *(Айны коткарырга кирәк.)*

*3 нче өлешнең эчтәлеген сөйләтү.*

***Анализлау өчен сораулар:***

а) Ай нәрсәләрдән ярдәм сорады? *(Чуртан белән Гөберле бакадан.)*

ә) Ул Айсылудан ярдәм сорадымы? *(Юк, Айсылу үзе килде.)*

б) Чуртан ни өчен ярдәм итмәде? *(Сәбәбе – көнләшү.)*

в) Бака ни өчен ярдәм итмәде? *(Сәбәбе: Айның үзен мактавын теләде,*

*ә Ай ялган сөйләргә теләмәде, чөнки ялганнан аның йөзе каралачак.)*

– Нәтиҗәсе? *(Айга тагын да ныграк куркыныч яный: аның бөтенләй хәле китә.)*

г) Айны кем коткарды? *(Айсылу.)* Аның турында сөйләгез. *(Айсылуга бәяләмә бирелә.)* Ни өчен ул Айны коткарды? *(Сәбәбе: Айны саклап калу, чөнки ул кирәк.)*

– Нинди нәтиҗә ясыйбыз? *(Ай исән калды.)*

– Яхшы, балалар, рәхмәт. Димәк, Айсылуда нинди үзгәреш булды? *(Аның ямьсез миңнәре юкка чыкты, ул чибәрләнде.)*

Өлешләп әкиятнең кыскача эчтәлеген сөйләү, сүзлек запасын баету. Әдәби әсәрне анализлау. Төрле фикерләрне исәпкә алу һәм үз позицияңне нигезләү. Укыган әсәр буенча сораулар бирә белү.

**Кабатлау һәм ныгыту күнегүләре**

– Бу әкият безне нәрсәгә өйрәтә? Нәрсәгә өнди? *(Кыен чакта башкаларга ярдәм итәргә.)*

– Әкиятнең идеясе нинди? *(Яхшылык яхшылык булып үзеңә әйләнеп кайтыр.)* Әсәрнең төп идеясе кайсы юлларда чагыла? *(Өзек укыла.)* Төрле мәгълүмат чыганаклары белән эш итү.

**Рефлексия**

– Ә сез яхшы гамәлләр кыласызмы? Бу гамәлләр кешенең нинди матурлыгын күрсәтә: эчке матурлыкнымы, әллә тышкы матурлыкнымы?

– Тышкы матурлыкны күрергә җиңел, ә эчке матурлыкны ничек күрергә?

– Кешедә нинди матурлык әһәмиятлерәк?

– Минем фикеремчә, сезнең дә күңелегез чиста. Әкият тә безне шуңа өйрәтте.

– Дөрес, яхшылык һәрвакыт яхшы була. Кешеләргә яхшылык эшләү турында бик күп мәкальләр дә бар. Берничәсен укып үтик. *(6 нчы слайд.)*

– Игелекле эшнең иртәсе-киче юк. *(Татар халык мәкале.)*

– Игелек иткән юлда калмас. *(Татар халык мәкале.)*

– Изгелек итә алмасаң, яманлык кылма. *(Татар халык мәкале.)*

– Кешегә игелек итсәң, үзеңә булышасың. *(Кытай мәкале.)*

– Матурлык – бер көнлек, игелек – мәңгелек. *(Чуваш мәкале.)*

Билгеләр кую. *(7 нче слайд.)*

**Өй эше:**

1. «Матур кеше нинди булырга тиеш?» темасына кечкенә инша язып килегез.
2. Айсылуның портретын ясарга.

Укытучы белән бергәләп үз иптәшләренең җавапларын бәяләү. Үз хезмәтеңне бәяли белү осталыгы.

– Гамәл дәфтәрләребезгә яхшылыклар гына язылсын иде. Сау булыгыз, укучылар!



**Фәйрүзә ХӨСӘЕНОВА,**

Азнакай шәһәре гимназиясенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы



**Чулпан ИБРАҺИМОВА,**

Азнакай шәһәре гимназиясенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

11

# «Үзем турында үзем»

Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәре буенча

ИСТӘЛЕК

*Туган тел укытучысы булу теләге шундый көчле иде миндә. Бу хыялым мине КДПУның татар теле һәм әдәбияты факультетына алып килде. Иң тәҗрибәле укытучылар, танылган шәхесләр безгә ныклы белем бирде. Укуның һәр көне бәйрәмгә тиң иде. Без шундый дус, тату укыдык, бүгенге көндә дә аралашып торабыз, иң кызыгы, укытучылар безне һаман хәтерлиләр.*

*1996 елда Казан дәүләт педагогика университетында «Мизгел» студентлар театры эшли башлады. Бу нәкъ безнең укый башлаган чорга туры килде. Уку вакытының күңелгә якыны – 1998–2000 елларда «Мизгел» театрында катнашу, спектакльләр кую. Беренче курслар бәйрәмендә егетләр җитмәгәч, егет булып киенеп чыккан идем. Әллә шул этәргеч булды, мине театрга уйнарга чакырдылар. Марсель абый Җаббаров безне театр сәнгатенә тартты, телебезнең нечкәлекләренә өйрәтте. Без сәхнәдә еларга, көләргә, дуслашырга өйрәндек. Марсель абый ут янып эшләде, җаны белән безнең өчен тырышты. Спектакль әзерләгәндә, Руфия, Ләйсән, Азат, Инсаф, Мөслимә белән якыннан таныштык. «Яңа гасыр» каналыннан «Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле берничә тапкыр күрсәтелде. Безне күреп укытучыларыбызның, әти-әниләрнең бик горурланганнары истә калган.*

*Чулпан Ибраһимова*

**Максатлар:**

***Белем бирү максаты:*** Габдулла Тукай биографиясенең төп фактларын кабатлау һәм повесть эчтәлеген аңлауны ныгыту.

***Үстерү максаты:*** текстны анализлау күнекмәләрен камилләштерү, фикерләрне формалаштыру һәм нәтиҗәләр ясау.

***Тәрбия максаты:*** шагыйрь иҗатына кызыксыну һәм хөрмәт уяту, туган телгә һәм мәдәнияткә кыйммәтле мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Предмет нәтиҗәләре:***

– Г. Тукайның «Исемдә калганнар» автобиографик әсәренең эчтәлеген, темасын һәм төп идеясен аңлау;

– әсәрнең автобиографик характерын билгеләү һәм «автобиографик әсәр», «биографик әсәр» төшенчәләренең аермасын аңлату;

– әсәрдәге төп вакыйгаларны эзлекле рәвештә искә төшерү, Г. Тукайның балачактагы тормыш юлын һәм яшәгән урыннарын карта-маршрут ярдәмендә билгеләү;

– әсәрдәге геройларны, аларның Тукай тормышындагы урыннарын ачыклау;

– тексттан кирәкле өзекләрне табу һәм аларны рәсем, фотография, тарихи вакыйга белән бәйләү;

– әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларга һәм геройларга карата үз мөнәсәбәтен белдерү;

– әсәрдәге авыр һәм кадерле мизгелләрне аерып күрсәтү, аларга бәя бирү;

– автобиографик әсәрдә авторның үз тормышы, кешеләр, вакыйгалар, хисләр һәм уйлар турында яза алуын аңлау;

– әдәби әсәрдәге мәгълүмат белән тарихи-биографик фактларны аера белү;

– Г. Тукайның татар әдәбияты һәм татар мәдәнияте үсешендәге әһәмиятен аңлау.

***Метапредмет нәтиҗәләр:*** дәреснең максатын аңлау һәм уку бурычларын мөстәкыйль билгеләү; биремнәрне үтәүнең эзлеклелеген планлаштыру; үз эшчәнлеген һәм җавапларын

бәяләү, хаталарны ачыклау һәм төзәтү; дәрес ахырында башкарылган эшкә нәтиҗә ясау, үз уку эшчәнлеген рефлексияләү; әдәби текстны анализлау, вакыйгалар арасындагы бәйләнешләрне ачыклау; текст, тарихи фотография, картина һәм башка визуаль чыганаклар арасындагы бәйләнешне ачыклау; парларда һәм төркемнәрдә хезмәттәшлек итү, уртак карарга килү; әдәби әсәр буенча фикер алышуда актив катнашу.

***Шәхси нәтиҗәләр:***

– Г. Тукайның шәхесенә һәм иҗатына карата кызыксыну, хөрмәт хисләре формалашу;

– бөек шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗади мирасы аша туган телгә, татар әдәбиятына һәм милли мәдәнияткә кыйммәтле мөнәсәбәт тәрбияләү;

– кеше тормышындагы авырлыкларны җиңәргә омтылу, сабырлык, рухи ныклык кебек сыйфатларның әһәмиятен аңлау;

– үз хисләреңне һәм кичерешләреңне тану, аларны әдәби әсәр геройлары кичерешләре белән чагыштыра белү;

– әдәби әсәрне эмоциональ һәм әхлакый яктан бәяләү, кешелеклелек, миһербанлылык, шәфкатьлелек кыйммәтләрен аңлау.

**Дәрес тибы:** йомгаклау дәресе.

**Җиһазлау:** дәреслек, проектор, ноутбук, презентация, картиналар, рәсемнәр.

**Дәрес барышы**

– Хәерле көн, укучылар! Бүген без тагын бер истә калачак матур әдәбият дәресебезне үткәрербез. Кеше хәтере – искиткеч әйбер ул. Без үзебезнең 3–4 яшьлек вакытыбыздан башлап гомер азагына кадәр булган тормышыбызны истә тотабыз. Истә тоту гына түгел, һәр вак детальне, күренешләрне, мизгелләрне истә калдырырга сәләтле без. Сезнең дә әле яшь булуга карамастан, исегездә, хәтерегездә балачак мизгелләре, тәүге тапкыр мәктәпкә килү һәм башка бик күп вакыйгалар якты булып сакланып тора. Укучылар! Сез мин әйтергә теләгән фикерне ишеттегезме, аңладыгызмы?

– Ә хәзер игътибарны экраннарга юнәлтәбез. *(Г. Тукайга, аның иҗатына багышланган кыска видео карау.)*

– Ничек уйлыйсыз, минем фикер белән видео арасында нинди бәйләнеш бар? *(Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәре турында сөйләшәчәкбез.)*

– Әйе, без бүген сезнең белән Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрен анализларбыз, йомгак ясарбыз. Мин бүгенге дәреснең темасын «Үзем турында үзем» дип атадым. Тема бик кызыклы һәм әһәмиятле. Сездән бик игътибарлы булуны сорыйм.

– Әйдәгез, бергәләп уйлап карыйк әле, нигә дәрес безнең шулай аталды икән? *(Чөнки Г. Тукай «Исемдә калганнар» әсәрендә үзе турында язган.)*

– Бик дөрес. Бүген без ике термин белән танышырбыз.

**Автобиографик әсәр** – авторның шәхси биографиясен, андагы аерым вакыйгаларны сурәтләп бирүгә корылган әдәби-документаль әсәр. Биредә төп герой – хикәяләүче, ул тормышындагы булган вакыйгаларны беренче зат исеменнән сөйли.

**Биографик әсәр** ул – кемнең дә булса тормыш юлын язу. Бу турыда без сезнең белән Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романын укыганда сөйләшербез.

– Ничек уйлыйсыз, «Исемдә калганнар» әсәренең төп герое кем? *(Г. Тукай.)*

– Г. Тукай үзе автобиографик әсәр язарга планлаштырмаган була. Әсәрнең язылу тарихын авторның үзеннән ишетик әле.

***Ясалма фәһем Г. Тукай булып сөйли:***

– «Исемдә калганнар»ны язуыма сәбәп: типографиянең миннән

тәрҗемәи хәлемне язып бирергә үтенүләре булды. Мин аларга тәрҗемәи хәлемне кыска гына рәвештә язып бирү нияте илә кулыма каләм алган идем, әллә ничек сүз озынга китте. Минем гомерем (укучылар күрерләр) шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарның һәммәсен язасым килде. Шунлыктан башыма килгәннәрне икесен ике китап итеп чыгарырга уйладым.

– 1909 елның 29 сентябрендә язылган автобиографик әсәр шул ук елның 12 ноябрендә (Казан, «Үрнәк» матбагасы) басылып та чыга. Тышлыкта Тукайның фоторәсеме бирелгән. Китап 38 битле, 4000 данә басыла.


– Укучылар, хәзер без сезнең белән әсәрнең үзенә күчик. «Исемдә калганнар» әсәрен тулысынча укып чыктык. Шагыйрь узган юл озын түгел кебек. Ләкин ул шулкадәр катлаулы, бай, кызыклы һәм кызганыч. Ул төрле гаиләләрдә, авылларда, шәһәрдә яшәргә мәҗбүр була. Әйдәгез, искә төшереп, бергәләп кечкенә Тукайның сәяхәт маршрутын төзибез. *(learningApps платформасы нигезендә Тукай яшәгән урыннар маршруты төзелә.)*

– Һәр яңа урында кечкенә Апуш тормышына яңа кешеләр килеп керә. Уку барышында без әсәрдәге геройларны аерып язып бардык. Ничә геройны билгели алдыгыз? *(22 геройны язып алдык, 9 ының исеме аталмый.)*




– Г. Тукай «Исемдә калганнар» әсәрендә күп кенә геройларның исемнәрен атамый. Ул кешеләр бит чынлыкта булганнар, тормыш иткәннәр. Кемнәр алар? *(Геройлар белән эш.)*

– Габдулланың тормышына кинәт кенә килеп кергән кешеләр күп, һәм алар кинәт кенә Габдулланың тормышыннан югалалар да кебек. Ләкин бу алай түгел, аның тормыш юлының кайсыдыр мизгелендә алар кабаттан килеп чыгалар, очрыйлар, аңа ярдәм итәләр. Бу кызыклы күренеш ул яшәгән авыллар белән дә бәйле. *(Авыллар, кешеләр әйтеп үтелә.)*




– Укучылар, Г. Тукайның тормыш юлы бик күп рәссамнарның картиналарында, тарихи фотографияләрдә чагылыш таба. Язучылар – сүз ярдәмендә, рәссамнар буяулар ярдәмендә бөек шагыйрьнең аянычлы язмышын сурәтлиләр. Сезнең каршыгызда картиналар, фотосурәтләр һәм әсәрдән, башка чыганаклардан өзекләр ята. Сезнең бурыч: картиналарга, фотосурәтләргә туры килгән өзекне дөрес итеп табарга.

| |
|---|
| Миңа әти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Торулары Яңа Бистәдә иде. Әти талчокта сату итә идеме, әллә тирече идеме шунда – анысын яхшы белмим. Әни, бер дә ар-мый-талмый, байларга кәләпүш эшләп чыгара иде. |
| Иске-москы бишмәтләремне, тишек киез каталарым-ны кидереп, күп тә утми, мине арбага чыгарып утырт-тылар. Әти-әни, бичаралар, һәр икесе елаган хәлдә, мине басу капкасына кадәр озата бардылар. |
| «Мәмдүдә озынчарак йөзле, сызылып киткән кара кыйгач кашлы, матур кылыч борынлы, тәскә-биткә чибәр, матур буй-сынлы, кирәк чакта шигырь белән җавап бирә торган оста телле, үзе тегү-чигүгә маһир бер мөлаем сылу булган». |
| Мине укытачак мулла кулына чыбык тотып утырган, аның тирә-ягында, минем яшемдәге кечкенә балалар күп булганы кеби, шактый җитеп килә торган кызлар да бар иде. |

| |
|---|
| Бабайлар өеннән чыгып, Сәгъди абзыйның арбасына утырдым. Бабай белән әби мине озатырга чыктылар. Тагы да минем китүемне кызык күргән яланаяклы малайлар да арба тирәсендә җөгергәләп җөриләр иде. |
| Ул мулла мине Өчиле авылындагы анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән. |
| Ямщик, Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан 60 кына чакрым), Печән базарында: «Асрамага бала бирәм, кем ала?!» – дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктан алган. |
| Тамак туйгач, әнинең рөхсәте илә урамга чыктым. Мин, анда чыгып, адашудан куркып, артыма ка-рый-карый гына барадыр идем, менә берзаман тирә-ягымны әллә кайдан килеп чыккан авыл малай-лары сарып алдылар. |
| Әни дә, баздан катык алып менеп, миңа зур гына икмәк телеменең яртысын тоттырды. Мин исә, Казан-нан кайтканнан бирле җүнләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, бик шәп бер иштиһа илә икмәк белән катыкны ялт иттердем. |
| Истәлекләргә караганда, Мөхәммәдгарифның «буе уртача булып, тәсе коңгырт, күзе зәңгәрсу, борыны җәенке, сүзгә оста һәм мәзәкчән булып, киенергә купшы, башына кара кама бүрек киеп, аны кырын салып җибәрә торган булган»лыгы әйтелә. |
| Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвеш бардым, мине кемнәр каршылады – анысын белмим, ләкин үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куан-ганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә. |
| Анам илә бер ел ярым кадәр торгач, беренче бала ула-рак, Кушлавыч авылында мин дөньяга килгәнмен. |

| |
|---|
| Кырлайда яшәгән чорда Габдулла авыл кешесе тормышы белән якыннан таныша. Сәгъди абзый Габдулланы да сабан эшенә җәлеп итә. Язын сабанга чыккач, Сәгъди абзый Габдулланы тырмага өйрәтә. |
| Юлда яшел чапан бөркәнгән бер яшь кенә хатын очрады, Алты-биш Сапый: «Бу – апаең, күреш», – дигәч, моның илә күрештем. |
| Кайчакта әни белән Ташаяк базарына барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самокатларда шатланып-шатланып агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем. |
| Г. Тукай – «Исемдә калганнар» автобиографик әсәрнең авторы. Ул – татар халкының бөек шагыйре. |

– Булдырдыгыз, афәрин. Без сезнең белән тулы бер галерея төзедек. Тагын бер тапкыр Тукайның биографиясендәге мизгелләрне искә төшердек. Әлеге сурәтләрдә тулы бер хисләр чагыла. Игътибар итегез әле, бу галерея, язучының тормышы, әсәр сездә нинди хисләр тудыра. *(Ятимлек, үгилек, хәсрәт, сагышлану, сагыну, юксыну, шатлык, аптырау, кимсенү, кирәксез итеп тою, кызгану, җәлләү, соклану.)*

– Чынлап та, әсәрне укыганда, шагыйрьгә карата без төрле хисләр кичерәбез. Әйдәгез, әлеге хисләрне без әсәрдәге вакыйгалардан эзлик һәм ике төркемгә бүлеп карыйк. *(Иң авыр, иң кадерле мизгелләр.)*

– **Иң авыр мизгелләр?** *(Әнисе үлү, Шәрифә карчыкның кертми торуы, бабасының өендә яратмаулары, Кырлайдагы әнисенең ачулануы, базарда кычкырып торулары...)*

– **Иң кадерле мизгелләр?** *(Әнисенең Саснага алып китүе, Яңа Бистәдә рәхәт булуы, Кырлайда ипи, катык белән сыйлаулары, әтисенең яратуы, Сабан туена бүләк җыю, мәдрәсәгә укырга баруы.)*

– Рәхмәт, бик тырыштыгыз. Чынлап та, Г. Тукай үзенең тормышын караңгы һәм ямьсез дип язса да, барыбер Тукай тирәсендә яхшы кешеләр күбрәк булган, алар һәрберсе Тукайны үзенчә яратканнар, якын күргәннәр. Ул бик нечкә күңелле, каты сүзле, сизгер йөрәкле. Бәлки шуңа күрә дә тормышында булган авыр минутлар аның күңелендә ныграк уелып калгандыр. Тукайны, аның тормышын, иҗатын үзен хөрмәт иткән һәр татар кешесе белергә тиеш. Тукай ул –тарих. Ул шушы авырлыкларга бирешми, бөек Тукай булып җитешә. Ләкин аның гомере бик, бик кыска була. Бу турыда инде без сезнең белән алдагы дәресләрдә сөйләшербез.

– Дәресебезнең темасы «Үзем турында үзем» иде. Нәтиҗә ясыйк әле, автобиографик әсәрләрдә автор нәрсәләр турында яза ала? *(Тормыш юлын, кешеләр, вакыйгалар, хисләрен, эшләрен, үзенең уйларын.)* Шулай да автобиографик әсәрне, андагы мәгълүматны автор тормышының чын тарихы дип кабул итәргә ярамый. Чөнки язучы әсәрдә сурәтләнгән малайга зур кеше күзлегеннән карый.

**– Өй эше: *Хаҗиморат Казаковның «Үксез бала» картинасы белән танышырга, картина буенча иншага әзерләнергә.***

– Һәр кеше Тукайны үзенчә күз алдына китерә, үзенчә күрә. Минем өчен Г. Тукай – бик кызыклы шәхес, ә сезнең өчен? *(Ятим бала, бөек шагыйрь, балалар өчен күп шигырьләр язган, батыр кеше, аны ятарканнар, бик яхшы укыган.)*

– Рәхмәт. Сезнең фикерләр минем өчен бик кызыклы һәм кыйммәтле. Тагын бер кызыклы әдәбият дәресебез өчен сезгә бик зур рәхмәт. Дәрес тәмам, чыгарга мөмкин. *(Музыка куела.)*



**Рузилә ВАГЫЙЗОВА,**

Казандагы 107 нче гимназиянең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

12

# Илсөяр Иксанова ижатына сәяхәт

(8 нче сыйныфта әдәбият дәресе)

ИСТӘЛЕК

**Быел 41 нче ел хезмәт эшчәнлегемне башлап җибәрәм. 35 ел Лаеш районы Кече Елга авылында эшләдем. Эшемне бик яратам. Төрле иҗади эшләр белән шөгыльләнәм. Интернет челтәрләрендә «Укытучы истәлекләре», «Без дә студентлар идек», «Балачагым истәлекләре» һәм башка темаларга үз фикерләремне урнаштырып барам. Безгә төпле белем биргән татар филологиясе укытучыларына аеруча зур рәхмәтлемен. Безнең төркем шәкертләренең барысы да укып чыккан һөнәрләре буенча эшләде. Күбесе әле бүген дә эшен дәвам итә. Керү имтиханнары бирүләр, биш ел буе анда белем алуларның барысы да хәтердә саклана. Тулай торакта яшәүләр безнең дуслыкны бик ныгытты. Без әле дә бөтен төркемебез белән аралашып торабыз. Кадерле укытучыларыбыз әле дә йөрәк түрендә. Бөтен дөньяга таралган татар теле укытучыларының барысы да диярлек шушы югары уку йортында тәрбияләнеп, канатларын ныгыткан бит. Кайда гына эшләп, нинди генә уңышларга ирешсәк тә, без сиңа бурычлы, Татфак!**

**Максат:** укучыларны Илсөяр Иксанова һәм аның иҗаты белән таныштыру, иҗатына хас темаларның нечкәлекләрен тоярга өйрәтү; язучының иҗатына мәхәббәт тәрбияләү; бәйләнешле сөйләм телен үстерү, сәнгатьле уку өстендә эш алып бару.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**
***Предмет нәтиҗәләре:***
– Илсөяр Иксанованың тормышы һәм иҗаты турында төп мәгълүматларга ия булу;
– шагыйрәнең иҗатына хас төп темаларны (туган як, балачак, әни, гаилә, мәхәббәт, тормыш һәм яшәеш һ.б.) билгели һәм характерлый алу;
– төрле чорда иҗат ителгән шигырьләрне чагыштыру, шагыйрә иҗатындагы үзгәрешләрне һәм үсешне күрсәтә белү;
– шигъри әсәрләрнең идея-тематик үзенчәлекләрен, авторның хис-кичерешләрен аңлау һәм бәяләү;
– укылган шигырьләргә карата шәхси мөнәсәбәт формалаштыру һәм аны дәлилләр ярдәмендә белдерү;
– әдәби әсәрләрне сәнгатьле уку, анализлау һәм мөстәкыйль нәтиҗә ясау күнекмәләрен ныгыту.

***Метапредмет нәтиҗәләр:*** дәреснең уку мәсьәләсен аңлау һәм аны чишү юлларын билгеләү; үз эшчәнлеген планлаштыру, биремнәрне эзлекле үтәү; Илсөяр Иксанованың тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүматны системалаштыру; шигырьләрне тематикасы, эчтәлеге һәм эмоциональ үзенчәлекләре буенча төркемләү; төрле чыганаклардан (шигырь җыентыклары, вакытлы матбугат, электрон ресурслар һ.б.) мәгълүмат табу һәм аны эшкәртү; шигъри текстның төп фикерен, автор позициясен, сурәтләнгән хис-кичерешләрне ачыклау; иҗади һәм тәнкыйди фикерләү күнекмәләрен формалаштыру; үз фикерен дәлилләп, эзлекле һәм бәйләнешле сөйләм белән җиткерү; сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү, шигырьнең эмоциональ-эстетик

үзенчәлекләрен тавыш, интонация һәм пауза ярдәмендә җиткерү.

***Шәхескә юнәлтелгән нәтиҗәләр:***

– укучыларда татар әдәбиятына, аерым алганда, Илсөяр Иксанова иҗатына кызыксыну һәм хөрмәт хисе формалашу;

– туган якка, әти-әнигә, якын кешеләргә, туган телгә һәм милли кыйммәтләргә мәхәббәт, ихтирам тәрбияләү;

– шигъриятнең кеше күңеленә эмоциональ һәм рухи йогынтысын аңлау, матурлыкны тоя һәм бәяли белү;

– үз фикереңне ачык белдерү, үзбәя бирү, иҗади эшчәнлеккә омтылу күнекмәләрен үстерү.

**Материал һәм җиһазлау:** Илсөяр Иксанованың шигырь җыентыклары «Казан утлары», «Ялкын» журналлары, плакатлар, яраткан җырлар, компьютер, интерактив такта, А4 форматындагы кәгазьләр.

**Дәрес технологиясе:** иҗади үсеш һәм информацион технологияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру. Психологик уңай халәт тудыру**

– Исәнмесез, укучылар,
Хәерле көннәр сезгә,
Зиһен һәм тел ачкычлары
Телим мин һәммәгезгә.

Кәефләрегез ничек, укучыларым?

Матур, кояшлы иртә күңелләрегезгә шатлык, бәхет китерсен. Бүген дәресебезгә күп кунаклар да килгән, алар бу сыйныфта нинди укучылар укый икән дип кызыксыналардыр. Әйдәгез, аларга үзебез турында сөйлик әле. Без нинди укучылар? *(Матур, ягымлы, әдәпле, белемле, акыллы һ.б.)*

– Күтәренке күңел белән дәресебезне башлап җибәрик. Һәр дәрестә без белергә тиешле берничә кагыйдә бар. Ниндиләр алар? *(Укучы слайдтан укый.)*

1. Тулы, матур җөмләләр белән сөйлә.
2. Иптәшеңне игътибар белән тыңла, бүлдермә.
3. Кеше фикерен кабатлама.

– Без бүген аерым районнарның язучыларын, шәхесләрен өйрәнүне дәвам итәбез. Сыйныфыбызда әби-бабалары Лаеш районыннан булган укучыларыбыз да күп. Шуңа күрә бүген чиратта – Лаеш районы. Анда яшәп, иҗат итүче нинди бөек шәхесләрне беләсез?

– Саралан авылында туган Илсөяр Иксанова, Державинодан – Фирдәвес Хәйруллина, Имәнкискәдән – Минвәли Габдуллин, Асылъяр, Яушыйктан – Фирдәвес Әхтәмова, Лаештан – Мөхәммәт Әблиев, Пәрәүдән Тимур Зиннуровларны зур горурлык белән искә алабыз. Борынгы шагыйребез Кол Гали дә Кашанда туган дигән фикерләр йөри. Д. Заваришин кебекләрнең дә Чырпы һәм безнең район белән бәйләнеше бар.
Ә бөек рус шагыйре Г.Р. Державинның тормышы турыдан-туры Лаеш районы белән бәйләнгән.
*(2 нче слайд, картадан әлеге авыллар табып күрсәтелә.)*

– Лаеш төбәгенә багышланган нинди җырлар беләсез?

– Берничә ел элек мәдәният йортында эшләүче Мөнир абый «Әй, Лаешым – минем сагышым» дигән җыр язган иде. Зиннур Гыйбадуллин сүзләренә язылган «Якты Елга» җыры да башта Кече Елга авылына багышлап язылган булган. Вакытлар узу белән никтер аның исеме «Кече Елга»дан «Якты Елга»га әйләнгән. Һәрбер мәктәпнең, авылның үз җырлары бар. Мәктәпләр дә мәктәп гимны итеп, яңа җырлар иҗат итәләр. *(Җыр текстлары күрсәтелә, җыр тыңлана.)*

– Ә хәзер, укучылар, нәтиҗә чыгарыйк әле.

– Димәк, Лаеш җире күренекле

кешеләргә бай икән. Гүзәл табигатьле Кама, Кашан урманнары да аларның иҗатына йогынты ясагандыр. Күбесенең татарлар булуы безнең өчен аеруча куанычлы.

**II. Уку мәсьәләсен чишү**

– Укучылар, без бүген сезнең белән Лаеш районында туган шагыйрә, бүгенге көндә Казанда яшәп иҗат итүче Илсөяр Иксанова иҗаты белән танышып китәчәкбез. Шигырьләренең күбесе сезгә таныш. Күптән түгел генә ул безнең гимназиядә кунакта булып китте. Аның белән очрашканнан соң кызыксынуыгыз тагын да арткандыр дип уйлыйм. Ә хәзер, әйдәгез, аның шигырь китаплары буенча сәяхәткә чыгыйк. Сезнең яшьлеккә кереп бару чорыгыз. Шуңа күрә аның беренче җыентыгы сезгә күбрәк ошаячак. Җыентыкта миңа иң ошаган шигырь – «Кешеләргә ышанасы килә» шигыре. Әйе, яшәеш көннән-көн кырыслана, авырая, кешеләрнең күңеле күз алдында үзгәрә. Бәгырьләр катылана, хисләр салкын корычка әверелә. Бүгенге матбугатны, әдәби әсәрләрне укуы көннән-көн авырая бара. Бер генә мәлгә булса да, чын асылыңа кайтасы, табигатьнең бер сулышы булган кеше итеп, янып ярата, хыяллана, соклана белгән кеше итеп тоясы килә.

Яшьлекнең иң ихлас шигырьләре күп дигәндә 16 яшькә кадәр языла. Иң кадерлесе дә шулар аның. И. Иксанованың «Ышанасы килә» китабы да нәкъ менә шуның өчен күңелгә якын. Барлык кешенең дә яшьлеккә, пакь хисләргә кайтасы килә. «Ышанасы килә» дигән китап һәркемне яшьлеккә кайтара. Һәркемгә дә беренче мәхәббәт кадерле, якын. Соңгы елларда чыккан «Мин сине яратам» китабы күренекле кешеләрнең беренче мәхәббәтенә багышланган сөю тарихларын бастырып чыгарды. Ул китап безнең китапханәдә бар. Якташыбыз турында да «Илсөяр+» дигән мәкаләне кем тапты? *(Укучының җавабы тыңлана.)*

– Якташыбызның шигырьләр китабындагы шигырьләрен берничә бүлеккә бүлдем. Беренчесе туган якка, балачакка багышлана. Хәзер аларны укучылар башкаруында тыңлап үтик. *(«Минем җәем», «Ай калды», «Кайтасы иде» шигырьләре укыла.)*

– Икенче бүлек: Әниләр турындагы шигырьләр. *(«Әни» шигыре укыла.)*

– Мәктәп еллары, классташларга багышлана. *(«Җидегән» шигыре укыла.)*

– Туганнарга багышланган шигырьләре. *(«Күбәләк» шигыре укыла.)*

– Тормыш, яшәешкә багышланган шигырьләре. *(«Әллә ничек кенә үтә гомер», «Мин тумыштан сагыш белән туган» шигырләре укыла.)*

– Һәр кешенең күңелендә яңа хисләр тудырган чын мәхәббәт турындагы шигырьләр аның иҗатында төп урынны билгели. Мәхәббәт турындагы шигырьләр циклын тәкъдим итәбез. *(«Хәбәр», «Алыштырдым сине», «Калдырма», «Сагындым», «Син кайттың», «Сиңа атап җырлар», «Көтү» шигырьләре укыла.)*

**Физкультминут.**

– Хәзер, әйдәгез, нәтиҗә чыгарыйк. Өстәлдәге ак битләрне алабыз. Башта икегә, аннан тагын икегә бөклибез. Йомык почмагын бөклибез. Килеп чыккан сызыкларны ручка белән сызып чыгабыз. Килеп чыккан «Темалар төрлелеге» дип язабыз. Беренче өлешкә – «Шагыйрәгә хас темалар», икенче өлешкә – «Хас булмаган темалар», өченче өлешкә – «Язарга кирәкле темалар», дүртенче өлешкә «Шагыйрә иҗатындагы кимчелекләр» дип язабыз. Хәзер һәрбер өлеш аерым-аерым тутырыла. 5 минут вакытта сез тутырып бетерергә тиешсез. *(Нәтиҗә ясала.)*

– Укучылар, хәзер Илсөяр Иксанованың бүгенге заман иҗатына

күз ташлыйк. Алар башлангыч иҗатыннан кайсы ягы белән аерыла? *(«Яз инде. Яз», «Төн», «Юк» шигырьләре укыла. Укучы нәтиҗә чыгара.)*

– И. Иксанованың шигырьләре хәзер күпмедер дәрәҗәдә фәлсәфигә әйләнгән. Ул тормыш турында күбрәк уйлана. Ниндидер кайгысы да бар кебек.

– Сез бу шигырьләрдә нинди хисләр белән очраштыгыз?

– Әти-әнигә, сөйгән ярга, туган җиргә мәхәббәт хисе, кызгану, рәнҗү һ.б.

– Шагыйрь гомере буена иҗат итә. Аның сүзләренә җырлар да язылган. Ул яңадан-яңа үрләр яулый. Төрле төбәкләрдә була, яңа идеяләр белән яна. «Ялкын», «Сөембикә», «Түгәрәк уен» журналларында эшләде. Сез очрашуда аның бик киң күңелле, аралашучан кеше икәнлеген белдегез.

– Якташларыбыздан тагын кемнәрне актив иҗат итүчеләр дип атый аласыз? Алдыгыздагы кәгазь битләренә һәрберегез актив иҗат итүче язучыларыбызны яза. Аннары түгәрәк буенча үз җавапларыгызны укыйсыз. Бүтән төркемнәрнекен дә кулланып, бердәм җавапны бирәсез. *(Бер минут вакыт бирелә. Җавап тыңлана.)*

*(Слайд күрсәтелә.)*

– Бүгенге көндә Лаеш районының актив язучылары дип, Гүзәл Сафина-Кадыйрованы, күрше Имәнкискә авылыннан Айсылу Имамиеваны, яшь драматург Раилә Мөхсинованы, Атабай авылыннан Булат Ибраһимовны һәм башка бик күпләрне саный алабыз. Районда иҗади кешеләрне берләштергән «Чулман акчарлаклары» дигән әдәби оешма да уңышлы гына эшләп килә. Аларның иҗатлары көннән-көн чәчәк атса иде, яңа әсәрләрен күбрәк күрсәк иде.

– Хәзер язучыларга зур уңышлар теләп, дәресебезне төгәллик. Үзебезнең эшчәнлегебезне ничек бәялибез инде. *(Укучылар үзләренә билгеләр куялар.)*

– Барыбыз да басабыз һәм яхшы билге алган укучыларга салютлар җибәрәбез.

**III. Өйгә эш бирү**

1. Арча районы язучылары турында материаллар туплап килергә.

2. «Шагыйрә сурәтләгән табигать» темасына рәсем ясарга.

– Сау булыгыз, укучылар, бу дәрес сезнең күңелегезгә иҗат очкыннарын көйрәтсен! Уңышлар сезгә!



**Рамилә АБДУЛЛИНА,**

Казан шәһәре Г. Ибраһимов исемендәге
17 нче татар гимназиясенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы,
педагог-методист

13

# Яра тулы күңел...

(8 нче сыйныфта Гөлүсә Батталованың «Чыра» хикәясе буенча дәрестән тыш уку дәресе)

ИСТӘЛЕК

*«И, йөзең таныш, син Татфакта укымадыңмы? Әйтәм бит!» Бу сүзләрне берәр конференция-фәлән, я семинарларга баргач, еш ишетәсең. М. Мәһдиев үзе турында «Мин Болак буенда гына белем алдым» дип әйтергә яраткан. Әйе, мин дә – данлыклы уку йортының бер укучысы.*

*90 нчы еллар башы. Татарстанда милли күтәрелеш чоры. Әле анда, әле монда татар университетлары, институтлары ачылган чак. Казан дәүләт университетының журналистика факультетына имтихансыз керү мөмкинлегем була торып та, әни, минем ай-ваема карамыйча: «Монда безне Сайганов абый укытты, Зәкиев, Зиннәтуллина, Сәгыйтовлар», – дип, үзе укыган белем йортына – Казан дәүләт педагогика институтының татар филологиясе һәм тарихы факультетына алып килде. Уку йортымны да, мөгаллимнәребезне дә бик яраттым, курсташларымнан да уңдым.*

*Бер генә белгечлек белән дә чикләнмәдек: тарих, татар теле һәм әдәбияты укытучысы булачагыбызга чиксез сөендек. 4 ел эчендә нинди генә фән өйрәнмәдек! Мәңге тел әйләнмәс дип борчылган инглиз теле сүзләрен дә ятладык, «мәхәббәт теле ул» дип, җан бәгырьләребезгә үткән француз телен дә өйрәнеп зачёт тапшырдык. Хәтта музыка буенча да безгә башлангыч белем бирелде. Укытучыларыбыз, тырыша-тырыша, безгә дә музыка серләрен төшендерде. Хатирәләр генә менә ничә еллар буе баян моңы кебек күңелне иркәләп җылытып тора...*
*Истә, бары да истә...*

**Максат:** Гөлүсә Батталованың «Чыра» хикәясенә анализ ясау; эпик төрдәге әсәрне анализлау күнекмәләрен ныгыту; укучыларның тәнкыйди фикерләвен, анализлау дәрәҗәсен үстерү; аларда тәрбиялелек, кешелеклелек сыйфатларын тәрбияләү, рухи дөньяларын баету.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Предмет нәтиҗәләре:*** Г. Батталова иҗаты һәм «Чыра» хикәясенең әхлакый кыйммәтен ачыклау.

***Метапредмет нәтиҗәләр:*** әдәби әсәр белән тормышны чагыштыра, нәтиҗәләр ясый белү күнекмәләрен булдыру; хәзерге чор белән бәйләп, әсәрнең актуальлеген аңлата алу.

***Шәхси нәтиҗәләр:*** әсәр геройлары үрнәгендә үзеңдә уңай сыйфатлар тәрбияләү.

**Материал һәм җиһазлау:**

1. Г. Батталова. «Чыра». – Казан: Татар. кит. нәшр., 2026.
2. Хикәянең электрон вариантына сылтама: *https://kazanutlary.ru/news/hikaya/cyra-xikaia*
3. Чыралар салынган махсус тартма.
4. Агачтан ясалган агач сын.
5. Тактага беркетер өчен, күрсәтмә материаллар, карточкалар әзерләнә.

***Искәрмә.*** *Дәреснең исеме тактага кисмә хәрефле карточкалардан тезелеп языла: «Яра тулы күңел». Әлеге язу дәрес ахырында «Яратулы күңел» дип үзгәртелергә тиеш.*

**Дәрес барышы**

**Оештыру-мотивлаштыру этабы**

**Этапның максаты:** *дәрестә уңай эмоциональ мохит булдыру; укучыларның дәрестән тыш татарча нинди китаплар укуын, бүгенге көндә яшәп иҗат итә торган язучыларны белүләрен сораштыру, дәреснең максатын билгеләү.*

*Укытучы дәрес башында бәхет турында шигырь укый.*

– Хәерле көн, хөрмәтле укучылар! Дәресебезне шигырь белән башлап

китүем тикмәгә түгел. Шигырь нәрсә турында? (...) Бүген без нәрсә турында сөйләшербез?

– Укучылар, сезгә бәхетне тояргга кемнәр ярдәм итә?

**Фикер алышу оештырыла.**

– Әлеге фикерләрне тактадагы «Кояш» моделенә яза барыйк. *(Укучылар такта янына чыгып, модельгә үз җавапларын язалар. Мәсәлән: әти, әни, укытучы, туганнар, дәү әни, дуслар һ.б.)*

– Үзенең бер әңгәмәсендә язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин: «Бәхет ул – сине тирә-юньдәгеләрнең аңлавы», – дигән иде. Бу сорауга тиз генә җавап бирә алмавыгызга да аптырамыйм, чөнки бәхетле кеше бәхет турында уйламый ул, ә бәхетне тояр, аңлар өчен безгә матур әдәбият ярдәм итә. Сез сыйныфтан тыш уку дәресенә бик матур әсәр буенча әзерләнеп килдегез. Әлеге әсәр нинди жанрда язылган? *(Хикәя.)*

– Ә нәрсәгә без «хикәя» дибез? *(Хикәя – кечкенә күләмле проза әсәре. Эпик әсәр. Гадәттә, бер вакыйга тасвирлана, геройлар күп булмый.)*

– Ә сез укып килгән әсәр башкалардан нәрсәсе белән аерыла? *(Кечкенә күләмле булса да, бүлекләргә бүленгән. Аларга исем кушылган һәм алар кабатланып барыла.)*

*Тактага бүлекләрнең «Алия апа», «Айнур» дип язылган карточкаларын беркетергә бер укучы чакырыла.*

– Беренче бүлек ничек дип атала? Анда сүз кем турында бара? *(Беренче бүлек «Айнур» дип атала. Ул I заттан – Айнур исеменнән сөйләнелә.)*

– Бу бүлектә без нәрсәләр белдек?

– Айнур үзен яратамы? Үзенә нинди бәя бирә? *(Яратмый, түбән сортлы дип саный. Артык кашык. Барыбер миннән кеше чыкмаячак. Бөтенесенең миннән котыласы килә.)*

– Бүлекнең соңгы юлларын укыгыз әле. *(«Күралмыйм барысын да...»)*

– Айнурның күңелендә нинди хис яши? *(Нәфрәт хисе.)*

– Ни өчен автор икенче бүлеккә «Алия апа» дип исем биргән? *(Укытучы Алия апа хисләре, уйлары сурәтләнсә дә, без Айнур турында беләбез.)*

– Нәрсә белдек? *(Айнурның язмышы турында белдек: әтисе башкага өйләнгән, Айнурның әнисе кечкенә энекәшен алып чыгып киткән. Ул әбисендә тәрбияләнә. Тәртипсез. Укытучылар аны яратмыйлар. Укуы начар: «денгә кертә торган бала түгел, явызның явызы» сүзләре шуны раслый.)*

– Укытучы Алия апа нишләргә уйлый? Нияте нинди? *(Җаббаровны кеше итү.)*

– Укучылар, дәрес башында сез үзегезнең бәхетегезне схемага язган идегез. Әйдәгез әле, Айнурның язмышын карыйк.

**Такта янында эш.**

Әти, әни, укытучылар, дуслар – берсе дә бәхетле мизгелләр бүләк итмиләр. Ә карт әбидән кала аның беркеме юк. Димәк, бу схемаларга карагач, кем бәхетле?

– Без.

– Димәк, безгә бәхетне аңлау өчен, бәхетсезләр язмышын аңлау кирәк. Бүгенге дәресебезнең максаты да нәкъ менә шушыннан чыга. *(Фикер алышу.)*

**«Әгәр мин.... булсам» дигән карточка** ярдәмендә сезнең фикерегезне беләсем килә. Укучылар, әгәр сез Айнур булсагыз нишләр идегез? *(Укучылар фикере тыңланыла.)*

– Әгәр сез укытучы, завуч, директор булсагыз, бу укучы белән ничек эшләр идегез? *(Укучылар фикере тыңланыла.)*

– Укучылар, безнең дәрестә эксперт укытучылар да катнаша. Сүзне аларга да биреп карыйк әле: Айнур белән нишләргә яки мондый тәртипсез баладан ничек «котылырга»? *(Дәрестә катнашкан укытучылар фикере тыңланыла. Айнурдан «котылу» түгел, ә аңа ярдәм итү юллары ассызыкланыла.)*

– Бу ситуациядән чыгу юлын әсәрнең алдагы бүлеген укыгач белербез.

Алдагы «Айнур» бүлегендә Айнур нишли? *(Ачуын басар өчен агачтан сын ясый.)*

– Ә сез ачу килгәндә нишлисез?

– Айнурның яралы күңелендә нинди хис туа? *(Ачу хисе.)*

– Алия апаның Айнурларның өйләренә баруы нигә кирәк? *(Айнурның яшәү рәвешен күрә, әбисе белән таныша. Чырадан ясалган сынны сорап ала. Димәк, укытучы апа бала язмышына битараф түгел. Аңа чын-чынлап булышырга тели.)*

– Алдагы бүлектә Айнурның яралы күңелендә нинди хисләр барлыкка килә? Нинди вакыйгалар тасвирлана? *(Укытучы аны дәрестән соң калдырып үзенә ярдәм итәргә сорый. Айнур гөл чүлмәкләренең кыршауларын рәтләп куя. Алия апа аңа тәмле печенье белән чәй эчертә.)*

– Айнурның ризыкка гаҗәпләнүен сурәтләгән урынны табып укыгыз әле.

– Ә хәзер Айнурның күңел халәтен тасвирлагыз. *(Ул тынычлана төшә.)*

– Алдагы ике бүлекне гомумиләштереп алсак, сүз нәрсә турында бара? *(Алия апа аны «Без бергә» фестиваленә әзерли. Агач серләрен аңа Илсур абый өйрәтә, Алия апаның ире. Ниһаять, Айнур районда 1 нче урын ала. Аңа диплом белән 3 мең акча бирәләр.)*

– Конверт алгач, Айнурның күңел халәтен тасвирлагыз. *(Ул үксеп елап җибәрә. «Әни киткәннән бирле беренче елавым иде бу...»)*

– Айнур күңелендә нинди хисләр биреләә? (*Горурлык хисе, шатлык хисе, курку хисе, ышаныч хисе, җиңү хисе.)*

– Айнурның эше нидән гыйбарәт? *(Бу шедевр «Ышаныч» дип атала. Ул аны укытучы Алия апага багышлый. Алда торган малай – Айнур үзе, ә артта – укытучысы.)*

– Укучылар, без укыган әсәрләрдән аермалы буларак, әлеге хикәядә «P.S. Айнур» бүлеге бар. Ул кем исеменнән сөйләнелә? (...)

– Анда бер үк образ берничә кат кабатлана? Ул нәрсә? *(Чыра.)*

– Чыра нинди образ? Әйдәгез, аның мәгънәләрен ачабыз?

**Тактада эш:**

*Чыра: йомычка, кушамат, ябыклык, ут кабызу өчен чимал, әсәр исеме, көчле позиция һ.б.*

Әлеге «Чыра» хикәясенең авторы – язучы, шагыйрә Гөлүсә Батталова. Бу хикәя «Казан утлары» журналы уздырган «Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» конкурсында икенче урын алды һәм интернет киңлекләрендә электрон варианты таралса, быел ул китап булып та басылып чыкты. Дәресебезгә мин «Яра тулы күңел» дип исем куйган идем. Гадәттә, лирик әсәрдә генә лирик геройның хисләр кардиограммасын төзибез. Әлеге хикәя – искәрмә, чөнки Айнурның хисләре беребезне дә битараф калдырмады. Нинди хис-тойгыларны аерып ала алабыз? *(Нәфрәт – үч – рәхәтлек – курку – горурлык хисе – шатлык хисе – курку хисе – ышаныч хисе – җиңү хисе – ярату хисе... Әлеге хисләр электрон тактадагы кардиограммага языла. Хисләр тирбәнешенә игътибар ителә, нәтиҗә ясала.)*

– Әсәр сезгә ошадымы? Ни өчен? *(Фикер алышу.)*

– Әсәр матур тәгәлләнә, сезгә дәреснең темасын үзгәртергә тәкъдим итәм, кемдә нинди фикерләр бар? (...)

– Дәрес башында «Сез бәхетлеме?» дигән сорауга җәһәт кенә җавап бирә алмаган идегез. Ә хәзер ни диярсез икән? *(Фикер алышу.)*

– Бәхет төшенчәсенә чыннан да төгәл җавап биреп тә булмый. Гадәттә, тулы канәгатьләнү халәте һәм хисен, яисә эштә, тормышта, укудагы уңышны бәхет диләр. Һәрнәрсә чагыштырудан туган кебек, без дә бәхетне үзебезчә бәялибез, нәтиҗә ясыйбыз. Ә моның өчен безгә матур әдәбият ярдәмгә килә. Бәхетегезнең кадерләрен белеп, тормыштан ямь һәм тәм табып яшәвегезне телим.



**Зөһрә МИҢНЕБАЕВА,**

Казандагы 171нче урта мәктәпнең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

14

# Алда юллар, кайсын сайларга?

## Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәрен укыганнан соң уйланулар

(9 нчы сыйныфның рус төркемендә әдәбият дәресе)

ИСТӘЛЕК

*Еллар... Сикәлтәле тормыш юллары буйлап ашыга, чаба. Арчаның 2 нче урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт педагогика институтына укырга кердем. Укуны тәмамлаганга быел – 45 ел. Бүген дә яраткан эшемдә.*

*Август аенда Казанда группадашлар белән очраштык. Чәчләргә чал кергән, ә йөрәк яшь, күңелләр шат. Уку елларын, тулай торак тормышын искә төшердек. Иң мөһиме – остазларыбыз да янәшәдә. Олы тормышка туры юл күрсәтүче, ныклы белем бирүче Роза апа Асылгәрәева, Фоат абый Галимуллин, Рүзәл абый Юсуповларның киңәшләре укытучы хезмәтенә мәхәббәт тәрбияләде. Рәхмәт сиңа, Татфак!*

**Максат:** «Ак чәчәкләр» әсәре аша укучыларда матур әдәбият әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү; табиблар, авырулар дөньясы белән танышу аша әсәрнең тормышчан икәнен дәлилләү, һөнәрләр һәм татар кино сәнгате турында мәгълүмат бирү, балаларның сөйләм активлыгын үстерү, һөнәр сайлауга кызыксыну тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Предмет нәтиҗәләре:***

– Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәренең темасын, идеясен, төп геройларын һәм исеменең мәгънәсен аңлату;

– әсәрдә күтәрелгән һөнәр сайлау, кешенең тормыштагы урынын табу проблемаларын ачыклау;

– табиб һөнәренең үзенчәлекләре һәм аңа хас мөһим сыйфатлар турында фикер йөртү;

– һөнәрләргә кагылышлы лексик берәмлекләрне сөйләмдә дөрес куллану;

– татар телендә һөнәрләрнең исемнәрен дөрес ясау, сүзләрне килешләр белән төрләндерү;

– өйрәнелгән сүзләрне һәм грамматик конструкцияләрне диалогик һәм монологик сөйләмдә куллану;

– бирелгән сорауларга тулы һәм дәлилле җаваплар бирү, үз фикерен татар телендә ирекле белдерү;

– татар әдәбияты һәм кино сәнгате арасындагы бәйләнешне аңлау, әдәби әсәрләрнең экранлаштырылуы турында мәгълүматны үзләштерү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:** дәреснең максатын һәм бурычларын аңлау, уку эшчәнлеген планлаштыру; биремнәрне мөстәкыйль һәм төркемдә башкару; үз эшчәнлеген бәяләү, хаталарын табу һәм төзәтү; дәрес нәтиҗәләрен куелган максат белән чагыштыру; тексттан кирәкле мәгълүматны табу, аны анализлау һәм гомумиләштерү; әдәби әсәрдәге вакыйга һәм геройларны тормыштагы һөнәрләр белән бәйләү; төрле чыганаклардан алынган мәгълүматны чагыштыру һәм нәтиҗә ясау; проблемалы сорауларга җавап эзләү, үз фикерен дәлилләү; парларда һәм төркемнәрдә нәтиҗәле хезмәттәшлек итү.

***Шәхси нәтиҗәләр:***

– укучыларда һөнәр сайлауга җаваплы караш формалашу;

– үз мөмкинлекләреңне, кызыксынуларыңны һәм шәхси сыйфатларыңны бәяләү күнекмәсе үсү;

– хезмәткә, белем алуга, һөнәр ияләренә хөрмәт тәрбияләү;

– табиб, режиссёр һәм башка һөнәр ияләренең җәмгыять тормышындагы әһәмиятен аңлау;

– үз киләчәгеңә карата җаваплылык хисе формалашу;

– татар әдәбиятына, кино сәнгатенә һәм татар мәдәниятенә кызыксыну арту.

**Җиһазлау:** карточкалар, мультимедиа, язучыларның һөнәр

иялəре турында язылган китаплары, аудиоязма, презентация.

**Эпиграф:** «Тормышта бəхетле булу, үз урыныңны табу өчен нык белемле булырга, хезмəт яратырга кирəк».

**Дəрес барышы**

***1. Оештыру моменты.***

– Хəерле көн, укучылар. *(Дəрескə əзерлекне тикшерү. Уңай психологик халəт урнаштыру.)*

***2. Фонетик күнегү.***

– Минем арттан кабатлыйбыз.
һе-һө – һөнəр, җə-җа – җаваплы,
ту-тү – түлəүле, кə-ка – канəгать,
ңа-ңə – шуңа, һа-һə – əһəмиятле.

***3. Өй эшлəрен тикшерү.***

– Алдагы дəрестə өйрəнгəн əсəрнең исемен, авторын, төп геройларын искə төшереп үтик əле? *(О чём мы говорили на прошлом уроке?)*

– Габдрахман Əпсəлəмовның «Ак чəчəклəр» əсəрен укыдык. Гөлшаһидə, Мансур, Юматша, Дилəфрүз, Əбүзəр Гиреевич – төп геройлар. Фазылҗан Яңгура – каршылыклы герой.

– Əсəр кемнəр турында? *(О ком произведение?)*

– Табиблар турында, алар арасында да төрлесе бар икəнлеген күрсəтə; табиб тормышының никадəр катлаулы, авыр икəнен дəлилли.

– Əсəр ни өчен «Ак чəчəклəр» дип атала? *(Почему произведение называется «Белые цветы»?)*

– Язучы табибларны ак чəчəклəр белəн тиңли; ак чəчəклəр җирне бизи, ə ак халатлы табибларыбыз кешелек сау-сəламəт булсын өчен тырышалар. *(Укучыларның җаваплары бəялəнə.)*

– Дəрес башында беренче яңгыраган сүзебез һөнəр сүзе иде. Без сезнең белəн һөнəр сайлау турында сөйлəшербез. *(Эпиграфны укыйбыз, алда торган бурыч һəм максатларны билгелибез.)*

– Укучылар, һөнəр сайлау – һəркемнең тормышында бик мөһим нəрсə. Һəрбер кеше үзенең күңеленə хуш килгəн һөнəрне сайлый һəм аңа гомерен багышлый. *(Выбор профессии – очень серьёзный момент для каждого человека. Каждый человек выбирает профессию по душе и посвящает свою жизнь.)*

– Безнең бүгенге дəресебезнең темасы да – һөнəр сайлау. Алда юллар, кайсын сайларга? Ə нəрсə соң ул һөнəр? *(Как понимаете смысл слова «профессия»?)* Аңлатмалы сүзлектə һөнəр, профессия сүзлəренə мондый аңлатма бирелгəн: һөнəр ул – кеше хезмəте һəм эшчəнлегенең төп төре. *(Профессия – вид трудовой деятельности человека, требующий определённой подготовки и специальных знаний, умений.)*

– Максатыбыз – һөнəр сайлау турында сөйлəшү, фикер йөртү. Ə хəзер инде өйрəнелгəн һəм бүгенге дəрестə куллану өчен кирəк булачак сүзлəрне кабатларбыз.

***4. Сүзлек өстендə эш:***

а) сүзлəрне тыңлыйбыз, минем арттан кабатлыйбыз:

– һөнəр сайлау – əһəмиятле – җаваплы – шəхси проблема – исəпкə алырга;

– максатка ирешү – омтылу – киңəш бирəлəр – эшкə урнашырга;

– үскəн саен – взрослея – шəхси проблема – личная проблема.

*(Укытучы укып чыга, балалар кабатлыйлар, тəрҗемəсен əйтəлəр, шул сүзлəр белəн җөмлəлəр төзеп карыйлар, тəрҗемə итəлəр.)*

б) Төркемнəрдə эшлəү.

***5. Карточкалар белəн эш.***

1 нче карточка. 1 нче бирем: дөрес тəрҗемəне тап.

Моя будущая профессия должна быть высокооплачиваемой.

1. Һөнəрне сайлау бик əһəмиятле һəм бик җаваплы.

2. Һөнəр сайлаганда, үзеңнең

характерыңны, белемеңне исәпкә алырга кирәк.

3. Минем киләчәк һөнәрем югары түләүле булырга тиеш.

2 нче бирем: -чы/-че кушымчалары ярдәмендә һөнәр исемнәре яса *(җыр, укыту, бию, гармун, курай, уку, элемтә, тәрбия һ.б).*

2 нче карточка. 1 нче бирем: дөрес тәрҗемәне тап.

Выбор профессии личное дело каждого.

1. Һөнәр сайлау – кеше тормышында иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе.

2. Һөнәр сайлау – һәркемнең шәхси эше.

3. Замана үзгәргән саен, тормыш яңа һөнәрләр таләп итә.

2 нче бирем: һөнәр сүзен килешләр белән төрләндер. *(Җаваплар экранда тикшерелә, нәтиҗә ясала. Үзбәя бирелә.)*

***6. Динамик пауза.*** «Сез минем белән килешәсезме?» уены. ***Әйе***: басабыз, куллар белән бер-беребезне сәламлибез. ***Юк***: утырабыз, күзләрне йомабыз.

– Сәламәтлек – зур байлык.
– Кешегә сәламәтлек кирәкми.
– Сәламәтлекне сакларга кирәк.
– Күп ашарга ярамый.
– Компьютерда көненә 5 сәгать утырырга ярый.
– Сәламәт булу өчен зарядка ясарга кирәк.
– Тәмәке тартырга ярамый.
– Сәламәтлекне сатып алып булмый.
– Зарядка ясау бик файдалы.
– Егет кешегә 70 төрле һөнәр дә аз.

***7. Һөнәр сайлау проблемасын күп кенә әсәрләрдән табарга була.*** Мәсәлән, Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романында – табиблар.

– Табиб булу өчен үзеңдә нинди сыйфатлар тәрбияләргә кирәк?

– «Профессия врача – это подвиг, она требует самоотвержения, чистоты души и чистоты помыслов». *(«Табиб һөнәре ул – батырлык, ул үз-үзең турында онытуны, күңел һәм фикер чисталыгын таләп итә».) (А.П. Чехов сүзләре.)*

– «Врачка карчыга күзләре, кызлар кулы, елан хикмәте (мудрость) һәм арыслан йөрәге кирәк». *(Әбүгалисина сүзләре.)*

– Табибларны фәрештәләр белән дә тиңлиләр. Фәрештә – ангел. Алар безнең тормышыбыз сагында торалар. Без өчебез, 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, медицина көллиятенә барабыз.

***8. Укучылар сөйли:***

– Ә минем фильм төшерәсем килә. «Ак чәчәкләр» фильмын гаиләбез белән карадык. Фильм ошады. Кино сәнгате белән кызыксынам. Укуымны шушы өлкә буенча дәвам итәсем килә.

– Яхшы, укучылар. Кино сәнгатенең тарихы турында ниләр беләбез?

– Кино – сәнгатьнең гадәттән тыш кызыклы һәм мавыктыргыч төре. Ул ике формага бүленә: документаль һәм нәфис. Документаль кинода реаль вакыйгалар һәм шәхесләр күрсәтелә. Нәфис кинода актёрлар уйный, барган вакыйгалар тулысынча уйлап чыгарылган булырга мөмкин. Киноның төрле жанрлары бар, мәсәлән, комедия, боевик, детектив, триллер, мелодрама һ.б. Актёрларсыз фильм төшереп булмый. Режиссёр фильмны төшерү процессын җитәкли һәм тулысынча аңа җаваплы.

– Кинематографның барлыкка килүенә – 131 ел. Бүгенге кинематографиягә нигез салган кино күрсәтү җайланмасын («синематограф») ике бертуган француз Луи белән Огюст Люмьерлар уйлап тапкан. Алар, беренче кыска метражлы фильмнар төшереп, 1895 елда Парижда күрсәтә. Бу көн кино туган ел булып тарихта кала. Димәк, кинога быел – 131 ел. Беренче сеанслар төссез һәм тавышсыз булса да, тамашачы арасында алар тиз популярлык казана.

Россиядә беренче кино Санкт-Петербургта 1896 елның маенда күрсәтелә. Бер елдан соң Казан халкы да кино күрү бәхетенә ирешә. Илдә Совет власте урнашкач, кино сәнгате тагын да популярлаша. Беренче мәртәбә татарча «Булат батыр» дигән фильм 1928 елның февралендә күрсәтелә. Ул ТАССРның Халык комиссариаты заказы белән төшерелә. Фильмдә кенәз Потёмкинга тәрбиягә эләккән Әсфән исемле татар малае язмышы сурәтләнә. Ул, егет булгач, әтисе Булат белән яу кырында очраша. Соңыннан икесе дә Пугачёв лагерена күчәләр. Дәүләт архивларында әлеге фильмның афишасы сакланган.

– Ә мин мультфильмнар карарга яратам. Безнең Татарстанда бу эш уңышлы башкарыла. «Аксу» продюсерлык үзәге тарафыннан Советлар заманында иҗат ителгән 38 мультфильм татарчага тәрҗемә ителде. Алар халык арасында популярлык казанды.

– Танылган режиссёр буласым килә. Бу сүзгә түбәндәге аңлатма бирелә: Режиссёр (фр. *Régisseur* – «заведующий», от лат. *Rego* – «управляю») – творческий работник зрелищных видов искусства: театра, кинематографа, телевидения, цирка, эстрады. Назначение режиссуры – создание на основе пьесы, музыкально-драматического произведения или сценария театрального спектакля, эстрадного или циркового представления, фильма.

– Нинди һөнәр бу?

– Режиссёр – иҗади һөнәр, кызыклы кешеләр әйләнәсендә эшли, уңыш һәм танылуга омтыла. Ләкин шуны да истән чыгармаска кирәк: күп вакытны ала, шәхси тормыш өчен вакыт калмый, иҗади кризислар да булырга мөмкин.

– Рәхмәт, укучылар. Димәк, безне алда олы юллар, зур сынаулар көтә. *(Җаваплар бәяләнә.)*

***9. Йомгаклау. Өй эше бирү.***

– Нинди дә булса һөнәр иясе булу өчен, имтиханнарны яхшы тапшырырга кирәк. Сезгә өй эше:

– Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз. Аның сорауларына җавап биреп, хат языгыз. Язма эшегез 80 сүздән торырга тиеш.

***1 нче вариант.*** Мин авырдым һәм хастаханәгә бардым. Анда мине бик яхшы табиб дәвалады. Шуннан соң мин табиб һөнәрен сайлау турында уйлый башладым.

Сиңа табиб һөнәре ошыймы? Табиб булу өчен нинди характер сыйфатлары кирәк? Безнең тормышта табиблар нинди роль уйный?

***2 нче вариант.*** Мин Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы буенча төшерелгән фильмны карадым. Фильм ошады.

Син кино сәнгате белән тормышыңны бәйләр идеңме? Режиссёр булу өчен нинди характер сыйфатлары кирәк? Кино сәнгатендә алар нинди роль уйный?

– Без бүген дәрестә нәрсә өйрәндек? *(Укучыларның җаваплары.)* Сөйләшүебезгә нәтиҗә ясыйк. Бүген бик күп кызыклы фикерләр әйтелде, һәрберегез бу темага үз мөнәсәбәтен белдерергә тырышты. Без куелган максатка ирештек дип саныйм. Чыннан да һөнәр сайлау – һәр кеше өчен бик әһәмиятле һәм бик җаваплы эш. Сез һөнәр сайлаганда, үз мөмкинлекләрегездән чыгып, әти-әниләрегезнең теләкләрен исәпкә алып, җәмгыятькә кирәкле һөнәрне дөрес сайларсыз дип ышанам.

Ә хәзергә дәрес тәмам. Дәрестә актив булганыгыз өчен рәхмәт сезгә. *(Билгеләр. Укучылар үзбәясе һәм укытучы бәясе.)* Сау булыгыз.

Музыка, салмак кына җыр яңгырый. «Ак чәчәкләр» җырын *(Айгөл Әхмәтгалиева сүзләре, Вил Усманов көе. )* «Казан егетләре» төркеме һәм Зәринә Хәсәншина башкара.



**Фирания ЕРЕМЕЕВА,**

Буа шәһәре Р.З. Сәгъдиев исемендәге мәктәпнең
I квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

15

# Зат алмашлыклары

(6 нчы сыйныфта татар теле дәресе)

ИСТӘЛЕК

*Мин КДПУда 1996–2001 елларда укыдым. Бик кадерле еллар! Муса Җәлил урамында урнашкан татар филологиясе факультеты гөрләп тора иде. Татфакта төрле чаралар үткәрелә, без барыбыз да әлеге чараларда бик актив катнаша идек. Олы хөрмәткә лаек укытучыларыбызның лекцияләрен тыңларга бүген дә кереп утырыр идем! Фоат Галимуллин, Рифат Сверигин, Рузәл Юсупов һәм башкаларның тавышлары әле дә колакта яңгырый… Роза Асылгәраева, Чулпан Харисова, Рәдиф Җамалетдинов, Рамил Мирзаһитовларның практик дәресләре аеруча җанлы үтте.*

*Ә тулай торак – үзе аерым бер дөнья! Без үзебезнең укытучылар белән янәшә яшәдек. Гел тәртип, чисталык, пөхтәлек иде бездә.*

*Укуны тәмамлаганга 25 ел үтсә дә, уку йортымда үткән һәр көнемне хәтерлим. Хәзерге вакытта үз эшчәнлеген дәвам итүче укытучыларыма нык сәламәтлек һәм зур уңышлар телим!*

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Предмет нәтиҗәләре:*** алмашлыклар турында мәгълүмат бирү. Зат алмашлыкларын җөмләләрдән табу һәм диалогик сөйләмдә дөрес куллана белү осталыгына ирешү.

***Метапредмет нәтиҗәләр:*** гомумиләштерү күнекмәсен камилләштерү, балаларның бәйләнешле сөйләм телен, грамоталы язу күнекмәсен, төркемнәрдә бер – берсе белән киңәшләшеп эшләү, нәтиҗә ясау, бәяли белү күнекмәләрен камилләштерү; фикерләү сәләтләрен үстерү юнәлешендәге эшне дәвам итү.

***Шәхси нәтиҗәләр:*** туган телгә мәхәббәт, үзара дустанә мөнәсәбәт, мөстәкыйльлек, дикъкатьлелек тәрбияләү.

**Төп төшенчәләр:** алмашлыклар, зат алмашлыклары, берлек һәм күплек сан.

**Предметара бәйләнеш:** әдәби уку, музыка, әйләнә-тирә дөнья.

**Эшне оештыру төрләре:** фронталь, индивидуаль, төркемнәрдә эшләү.

**Чыганаклар:** компьютер, презентация, экран, биремле карточкалар.

**Дәрес тибы:** яңа белем һәм күнекмәләр бирү.

**Дәрес этаплары**

**I. Ориентлашу, мотивлаштыру этабы**

*Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.*

– Исәнмесез!
Хәерле көн сиңа да!
Хәерле көн миңа да!
Хәерле көн безгә дә!
Хәерле көн сезгә дә!

**II. Уку мәсьәләсен кую**

***Укучылар өчен максат:*** *килеп туган уку мәсьәләсен анализлау; дәреснең темасын, максатын билгели белү. (Экранда слайдлар алмашып тора.)*

– Кеше үзен ничек атый? *(Мин.)*

– Иптәшегезгә кем дип эндәшерсез? *(Син.)*

– Сезнең янга килеп баскан кешене кем диярсез? *(Ул.)*

– Мин һәм син. Икесе бергә кем була? *(Без.)*

– Үзегездән олы кешеләргә ничек эндәшәсез? *(Сез.)*

– Калганнарга кем дип әйтәсез? *(Алар.)*

– Дөрес, укучылар.

– Укучылар, әлеге сүзләр нинди сүз төркеменә керә?

– Әйе, бу сүзләр – зат алмашлыклары. Димәк, безнең дәресебезнең темасы нинди була инде? *(Зат алмашлыклары.)*

– *Мин* алмашлыгы – сөйләүчене, *син* – тыңлаучыны, *ул* – сөйләмдә катнашмаган яки сөйләм ситуациясе вакытында булмаган затны, шулай ук аның турында сүз барган предметны белдерә. *Без* алмашлыгы сөйләүчене һәм аның тарафыннан бер төркемгә берләштерелгән затларны белдерә. *Сез* алмашлыгы сөйләүче мөрәҗәгать иткән затны, сөйләмдә катнашмаган

яки, гомумән, уртак билгеләре буенча сөйләүче тарафыннан бер төркемгә берләштерелгән затларны белдерә. *Алар* алмашлыгы сөйләмдә катнашмаган затларны һәм алар турында сүз барган предметларны белдерә.

Игътибар итегез: якын кешеләргә, туганнарга мөрәҗәгать иткәндә, һәрвакыт син дип әйтелә, билгеле бер затка карата ихтирам йөзеннән Сез алмашлыгы кулланыла.

**III. Танып белү эшчәнлеге. Уку мәсьәләсен чишү**

– Дәфтәрләрдә эш. Унберенче декабрь. Сыйныф эше. Зат алмашлыклары.

Берлек сан:
I зат *Мин*
II зат *Син*
III зат *Ул*
Күплек сан:
I зат *Без*
II зат *Сез*
III зат *Алар*

Ике төркемгә дә бирем бирелә. Конвертлардан текстны алырга, текстта нинди сүз кабатланып килә, аны нинди сүз белән алыштырып була, мөмкин булса алыштырырга.

***1 нче төркем.*** Кар бөртеге әкрен генә җиргә төшә. Кар бөртеге бөтен әйләнә-тирәне ап-ак итә. Кар бөртекләрен түбәләрдә дә, агач башларында да күрергә була. Кар күп булса, иген мул булыр.

***2 нче төркем.*** Бөек шагыйребез Г. Тукай бик аз гомер эчендә гаять бай иҗат мирасы калдырды. Г. Тукай, исән чакта ук, татар милләте тарафыннан милләтенең рухи юлбашчысы итеп танылды, иҗаты югары бәя алды. Г. Тукайның исеме күңелебезгә бик якын.

***1 нче төркем.*** Кар бөртеге әкрен генә җиргә төшә. Ул бөтен әйләнә-тирәне ап-ак итә. Аларны түбәләрдә дә, агач башларында да күрергә була. Кар күп булса, иген мул булыр.

***2 нче төркем.*** Бөек шагыйребез Г. Тукай бик аз гомер эчендә гаять бай иҗат мирасы калдырды. Ул, исән чакта ук, татар милләте тарафыннан милләтенең рухи юлбашчысы итеп танылды, иҗаты югары бәя алды. Аның исеме күңелебезгә бик якын.

– Укытучылар, нинди сүзләр кабатланып килгән?

– Аны нинди сүз төркеме белән алмаштырдыгыз?

– Алмашлыклар безнең сөйләмебезне нишләтә?

*Укучылар җавабы:*

– Сөйләмебезне матурлыйлар, кабатлаулардан коткара.

**IV. Ял итү минуты**

Мин, син, ул,
Без, сез, алар.
Бердәм, дус балалар!
Бергә укыйбыз,
Бергә язабыз,
Бергәләп ял итәбез.
*Музыка астында хәрәкәт итү.*

**V. Белемнәрне ныгыту**

***Укытучы өчен максат:*** белемнәрне күнегүләр ярдәмендә ныгыту мөмкинлеге булдыру.

***Укучылар өчен максат:*** белемнәрне дәреслек кулланып һәм төркемнәрдә камилләштерү.

– Төшеп калган алмашлыкларны куярга.

Хәтерлә әле.
1. Песи авызында күрдең син аны.
Хәтерлә әле, ул ни булыр?
Һәм эт авызында күрдең син аны.
Хәтерлә әле, ул ни булыр?
Син хәтерләсәң, хәтерләмәсәң дә, ул гел булыр.
Аның исеме, исеме аның тел булыр.
2. Иң гадел дус
Әйтә алмыйм, нindидер ул
Синең өчен?
Яхшы китап – иң гадел дус
Минем өчен:
Күзгә карап әйтә миңа
Иң дөресен,
Ачып сала серләренең
Бөтенесен.
Яратмасаң үпкәләми,
Алдашмый да...
Аның белән дус булганнар
Адашмыйлар.

– Дәреслектәге 273 нче күнегүне (119 нчы бит) телдән башкарабыз.

– Текстны укыйбыз, алмашлыкларны табабыз. Алмашлыкларның нинди җөмлә кисәге булып килгәнен әйтәбез.

**VI. Нәтиҗә ясау**

***Укытучы өчен максат:*** яңа белемнәрне мөстәкыйль куллану мөмкинлеге булдыру.

Зат алмашлыкларының моделе:

– сүзне алмаштырып килә;

– кабатлаудан коткара;

– җөмләдә ия, тәмамлык, аергыч була.

– Дәреслектәге 274 нче күнегүне (119 нчы бит) башкарабыз.

– Соңгы җөмләдә *Сез* алмашлыгы ни өчен баш хәрефтән язылган?

– Сез дип кемгә эндәшәләр?

– Сез дип өлкәннәргә һәм укытучыларга эндәшәләр.

**VII. Уку эшчәнлеген йомгаклау**

***Укытучы өчен максат:*** дәрестәге эшчәнлекне анализлау, белемнәрне бәяләү һәм киләчәккә алмашлыкларны дөрес куллану.

***Укучылар өчен максат:*** үз фикереңне дәлилләү, дәрестә алган белемнәрнең әһәмиятен аңлау, аларны киләчәктә куллана белү.

***Укытучы өчен максат:*** өй эшен хәбәр итү, аны башкару ысулын аңлату.

***Укучылар өчен максат:*** өй эшен дөрес башкару.

**Рефлексия.**

– Укучылар, сез бүген нинди яңалык белдегез?

– Теманы аңлаганда нинди кыенлыкларга очрадыгыз?

– Эшебезнең нәтиҗәсе булдымы?

*Балаларның җаваплары:*

– Без бүген дәрестә зат алмашлыкларын өйрәндек.

– Рәсемнәр карадык, *мин, син, ул, без, сез, алар* зат алмашлыклары икәнен белдек. Төркемнәрдә, парларда эшләдек.

– Җөмләләрдән алмашлыкларны табарга өйрәндек. Зат алмашлыклары исемне алмаштырып киләләр.

**Үзбәя.**

– Дәрес материалын бик әйбәт үзләштердем, хәтта иптәшләремә дә булыша алам: 5.

– Әйбәт эшлим, материалны аңладым, ләкин 1–2 хата ясадым – 4.

**Өй эше:**

1. Мәҗбүри: 184 нче күнегү.
2. Ирекле: әдәби уку китабыннан зат алмашлыклары кергән 6 җөмлә язарга.
3. Иҗади: зат алмашлыкларын кулланып, «Минем гаиләм» дигән темага инша язарга.

Дәрес тәмам!





**Эльмира ГЫЙБАСЕВА,**

Апас районы Биеш урта мәктәбенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

16

# Җөмләнең баш кисәкләре

(7 нче сыйныфта татар теле дәресе)

ИСТӘЛЕК

*Студент еллары – һәрбер кеше язмышында истә кала торган вакыт. Күңелле дә, кырыс та мәктәп. Сагынып сөйләр хатирәләре дә байтак. Инде күпме вакыт узса да, барлык укытучылар җылы хатирә белән истә саклана. Харисова Чулпан апаның 100 кешелек аудиториягә килеп керү белән морфологиядән: «Син, син, син» дип сораулар яудыруын ничек онытып була инде?! Үлеп терелә идек шул чакта. Бөтен курс алдында оятка каласы килмичә, әй, ятлый идек шул кагыйдәләрне. Чулпан апаның бу эш алымы бик үтемле булды, иярде бит миңа. Инде хәзер үз укучыларым шулай, дулкынлана-дулкынлана, кагыйдә сөйлиләр.*

**Максат:** җөмләнең баш кисәкләрен, хәбәр төрләрен һәм уен биремнәре аша сызык кую кагыйдәләрен өйрәнү; укучыларның анализ ясау, гомумиләштерү, мөстәкыйль фикерләүләренә ирешү; туган җиргә мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Дәреснең тибы:** яңа белемнәрне үзләштерү дәресе. Квест-дәрес.
**Төп төшенчәләр:** баш кисәк, ия, хәбәр.
**Предметара бәйләнеш:** әдәбият, рус теле, биология.
**Эшне оештыру төрләре:** фронталь, индивидуаль.

**Дәрес барышы**
**Дәресне оештыру моменты.**

– Исәнмесез, укучылар! Әйдәгез әле, бер-берегезгә карап, елмаешып, хәерле эш сәгатьләре теләп, дәресебезне күтәренке рухта башлап җибәрик.

– Укучылар, хәзер күзләрегезне йомыгыз да тыңлагыз әле. *(Чишмә чылтыравының аудиоязмасы.)*

– Сез нәрсә ишетәсез? *(Су шаулавы, үлән кыштырдаганы, кошлар сайравы.)*

– Нинди хисләр кичерәсез? *(Кәефем күтәрелә, яхшыра, миңа рәхәт, күңелем тынычлана, елмаясы, көләсе килә.)*

– Ә хәзер күзләрегезне ачыгыз һәм хыял дөньясыннан дәрескә әйләнеп кайтыгыз. Тактада 3 җөмлә бирелгән. Бергә матур итеп укыйк әле.

*Су ага.*
*Тау астында чишмә чылтырый.*
*Туган җирем – ялга туктамас саф чишмә, инеш, елга.*

– Укучылар, бу өч җөмлә чишмә суының өч тамчысы кебек. Ләкин аларда тел серләре яшерелгән. Ә хәзер шушы серләрне чишәргә тырышып карыйк әле.

– Ничек уйлыйсыз, бу җөмләләрнең нинди уртак яклары бар? *(Өчесе дә хикәя җөмлә, тәмамланган уйны белдергән, баш хәреф белән башланган, җөмлә ахырында нокта куелган.)*

– Алар бер-берсеннән нәрсә белән аерыла? *(Беренче җөмлә – җыйнак, ия белән хәбәрдән тора, икенче, өченче җөмләләр – җәенке, иярчен кисәк бар.)*

– Җөмләләрдә нинди баш кисәкләр бар? Алар кайсы сүз төркеме белән белдерелгән?

– Ни өчен бер җөмләдә сызык тора, ә икенчесендә юк?

– Димәк, укучылар, без бүгенге дәрестә шушы серләрне чишеп бетерергә тиешбез.

– Шушы сорау-җаваплардан чыгып, дәреснең темасын билгелик әле. *(Җөмләнен баш кисәкләре.)*

– Дәрестә без нишләячәкбез?

*– Ия белән хәбәрне дөрес итеп билгелибез.*

*– Бу баш кисәкләрнең нинди сүз төркемнәре белән белдерелүен ачыклыйбыз.*

*– Ия белән хәбәр арасына сызык куярга өйрәнәбез.*

– Шушы сорауларга җавап табу өчен, мин сезне «Җөмләләр сере» дип

аталган лингвистик сәяхәткә чакырам.

– Сезнең бурыч – 3 тукталышны узу, биремнәрне үтәү һәм дәрес ахырында нәтиҗә ясау. Безнең «сәяхәт картасы» бар – сезнең юл күрсәткечегез. Һәр этапны уңышлы узган өчен, сез белемнәрнең «тамчысы» наклейкасын алачаксыз.

– Укучылар, сезнең партада белемнәрегезне бәяләү картасы ята. Һәр биремнән соң сез критерийлар буенча үзегезне бәяләрсез. Дәрес ахырында балларны кушып, үзегезгә билге чыгарасыз. Хәзер үзегезнең исем, фамилияләрегезне язып куегыз.

– Дөрес итеп утырыгыз. Дәфтәрләрне авыш итеп куеп, числоны язып куегыз. *(Укытучы теманы язып куя.)*

– Юлга кузгалырга әзерме сез?

**1 нче тукталыш. «Кагыйдәне исеңә төшер!»**

– Сезнең бурыч – ия белән хәбәрләр турында 6 нчы сыйныфта алган белемнәрне искә төшерү. Дәреслектәге 98 нче күнегүне эшлисез.

– Күп нокталар урынына соралган сүзләрне генә дәфтәрегезгә языгыз. Сезгә 2 минут вакыт бирелә.

*1. Җөмләнең баш кисәкләре – ... белән хәбәр.*

*2. Ия һәрвакыт ... килештә килә: Мәктәп зур.*

*3. Иягә -ны/-не , -... /-... кушымчаларын куеп карап булмый. Мин күлмәк(не) юдым. Мин әти(нең ) күлмәген юдым.*

*4. Ия янында ... һәм бәйлек сүзләр килми. Мин театрга әни белән барам.*

*5. Ия һәм хәбәр булып килгән исемнәр берлек яисә ... санда, ... белән төрләнгән һәм иркәләү-кечерәйтү кушымчаларын алган булырга мөмкин.*

*6. Ияләр дә, ... дә тиңдәшләнеп килә алалар.*

– Бик яхшы, укучылар. Ә хәзер тикшереп алыйк. Чылбыр буенча укыйсыз. Башкалар эталонга карап, җавапларыгызның дөреслеген тикшереп барыгыз.

*(Укучылардан сорау, укыйлар, җавап чыгып бара.)*

*Белемнәрне бәяләү.*

1. Җөмләнең баш кисәкләре – ия белән хәбәр.

2. Ия һәрвакыт баш килештә килә: *Мәктәп зур.*

3. Иягә -ны/-не , -ның/-нең кушымчаларын куеп карап булмый. *Мин күлмәк(-не) юдым. Мин әти(-нең ) күлмәген юдым.*

4. Ия янында бәйлек һәм бәйлек сүзләр килми. *Мин театрга әни белән барам.*

5. Ия һәм хәбәр булып килгән исемнәр берлек яисә күплек санда, тартым белән төрләнгән һәм иркәләү-кечерәйтү кушымчаларын алган булырга мөмкин. *Абыем Казан шәһәрендә яши.*

– Беренче тамчыны ябыштырабыз, сезгә чишмә турында кызыклы мәгълүмат җиткерәсем килә.

Апас районы чишмәләргә бай. «Әнәле» чишмәсе – бик шифалы, саф сулы. Кешеләр монда авырулардан терелергә һәм көч алырга киләләр.

– Сәяхәтбезне дәвам итәбез, укучылар.

**2 нче тукталыш. «Ия белән хәбәрне тап!»**

– Зәңгәр карточкадагы биремне үтәргә кирәк була. Ләкин иң элек 68 нче биттәге кагыйдә белән танышып чыгарга кирәк. Парларда икәүләшеп эшлисез. Биремен укы әле. Сезгә 3 минут вакыт бирелә.

(***Бирем.*** *«Өзекне сәнгатьле итеп автор роленә кереп укыгыз. Ия белән хәбәрләрнең астына сызыгыз. Алар кайсы сүз төркеме белән белдерелгән? Өченче җөмләдә сызык куюның сәбәбен кагыйдә нигезендә аңлатыгыз.)*

1. Тау башына салынгандыр
безнең авыл.
Бер чишмә бар,
якын безнен авылга ул.
*Габдулла Тукай*

2. Тау астында җырлап чишмә ага,

Камышлыкка кереп югала.
Татлы суы, дәртле җыры белән
Гөлчәчәкле җирне сугара.

*Муса Җәлил*

3. Чишмә башы – изге урын, диеп,
Мосафирлар ялга туктаган.

*Гамил Афзал*

*Сугара – орошает.*
*Мосафир, юлчы – путник.*

– Укучылар, эшләрне тикшерер алдыннан өзекләрнең авторларына игътибар итегезче. Ни өчен шушы авторлар бирелгән икән? *(Чөнки быел аларның юбилейларын билгеләп үтәбез.)*

– Нинди юбилей даталар, әйтеп чыгыгызчы? *(Слайдта.)*

– Әйдәгез, биремнәрне тикшерәбез. Берегез, автор булып, өзекне укый, икенчегез бирем буенча җавап бирә. *(3 пардан сорау.)*

– Эшләрегезне бәяләгез, балалар.

– Нинди нәтиҗә ясыйбыз? Димәк, җөмләнең баш кисәкләре теләсә кайсы сүз төркеме белән белдерелә ала?

– Дәреслектәге кагыйдәне укыйк әле.

– Яхшы, без 2 нче тукталышны да үттек. Тамчыбызны ябыштырып куябыз. Чишмәләр турында тагын бер кызыклы мәгълүмат белән танышырга тәкъдим итәм.

Чишмә ни өчен шулай матур челтерәп ага? Бөтен хикмәт су хәрәкәт иткәндә барлыкка килә торган вак-вак һава куыкларында. Алар шартлаганда, нәкъ шул моңлы тавыш барлыкка килә. Агым никадәр куәтлерәк булса, челтер тавышы шулкадәр көчле яңгырый.

**3 нче тукталыш. «Уйла! Иҗат ит!»**

– 68 нче биттәге кагыйдә буенча, өченче тукталыш биремен үтәргә кирәк булачак.

– Хәзер 2 командага бүленеп эшлибез. 1 нче рәттә утыручылар – 1 нче команда, 2 нче рәттә утыручылар 2 нче команда була. *(Арткы яктагы парталарга утыралар.)*

– Командаларга шундый бирем:

**1 нче командага.** Күз алдыгызга китерегез, сез – экскурсовод. Картиналар күргәзмәсенә килүчеләргә бу рәсем турында нәрсә сөйләр идегез? Бер җөмләгездә ия белән хәбәр арасында сызык куелырга тиеш. (4–5 җөмлә.)

*(Рәсемгә күз салыгыз әле, нинди матур пейзаж! Үләннәр арасында матур чишмә ага. Чишмә – табигать бүләге. Ул саф су бирә. Яшел агачлар арасында ялгыз йорт тора. Еракта тау күренә. Монда шундый матур! Бөтен картинадан тынычлык бөркелә. Анда бер генә минутка булса да эләгәсе килә.)*

**2 нче командага.** Күз алдыңа китерегез, сезгә «Сабантуй» журналына урманда табылган «гаҗәеп чишмә» турында хәбәр язарга кирәк. *(4–5 җөмлә.)* Бер җөмләгездә ия белән хәбәр арасында сызык куелырга тиеш.

*(Гаҗәеп урын турында беләсегез киләме? Урманда, биек агачлар арасында, без чиста чишмә таптык. Чишмә – кечкенә могҗиза. Аның суы чиста  һәм салкын. Янәшәдә матур ялгыз йорт, ә урман артында тау күренә. Монда шундый тыныч, шундый тын, китәсе килми.)*

– Сезгә 3 минут вакыт бирелә. Башладык.

– Ә хәзер иҗади эшләрегезне тикшерәбез, укучылар. Ни өчен сызык куелган? Аңлатыгыз.

– Бик эчтәлекле, матур җөмләләр төзегәнсез. Афәрин. Урыннарыгызга утырыгыз, укучылар. Эшләрегезне бәяләгез.

– Яхшы, укучылар, без 3 нче тукталышны да уңышлы үттек. Укучылар, утырыгыз. Ә мин сезгә чишмә турында тагын бер кызыклы фактны сөйлим. *(Алдагы рәсемне карарга).*

**Рефлексия, бәяләү этабы.**

– Балалар, безнең картага карагыз. Барлык тамчылар да үз урыннарын алды. Бу –  «Җөмләләр сере» исемле сәяхәтнең барлык биремнәрен дә уңышлы үттегез һәм грамматик нигезнең төп серләрен ачтыгыз

**Чишмәнең суы гына түгел, аның челтерәп аккан тавышы да шифа бирә. Кеше көнгә 15–20 минут чишмә тавышын тыңласа, пульсы нормальләшә, сулышы тынычлана, киеренкелеге бетә.**



дигән сүз. Сез – яшь лингвистлар! Сез парларда, командада эшли һәм логик фикер йөртә белүегезне күрсәттегез. Мин сезнең бер-берегезгә ярдәм иткәнегезне күрдем,  бу – бик күркәм сыйфат.

– Ничек уйлыйсыз, дәрес башында куйган максатларга ирешә алдыкмы?

– Бүгенге сәяхәт барышында ия белән хәбәр турында нәрсәләр истә калдырдыгыз?

– Соңгы җөмләнең серен ача алабызмы?

– Бу белемнәр сезгә тормышта кирәк булырмы?

*– Ия белән хәбәрсез тулы җөмлә булмас. Аларны белсәм, мин дөрес сөйләшә һәм яза алам.*

*– Хаталар ясамыйча язу, текстларны тиз аңлау һәм үз уйларыңны ачык аңлату өчен кирәк бу белемнәр.*

**Үзбәя**.

Дәрес барышында билгеләп барган үзбәя карталарыгызга карап, үзегезгә билгеләр куегыз. Үзбәяләрегез минем билгеләр белән туры килсә, аларны журналга куям.

**Өй эше.**

Дәрестә сез бик актив булдыгыз, дөрес җаваплар бирдегез. Димәк, өй эшен башкару да сездә кыенлык тудырмас дип уйлыйм.

1. Мәҗбүри өй эше (репродуктив) – дәреслектәге 101 нче күнегү. Шигырьне күчереп языгыз. Ия белән хәбәрләрнең астына сызыгыз, кайсы сүз төркемнәре белән белдерелгәнне билгеләгез.

2. Ярым иҗади (конструктив) – әдәбият дәреслегеннән ия белән хәбәр арасында сызык куелган 5 җөмлә табып язарга.

3. Иҗади – бүген өйрәнгән кагыйдәләргә туры китереп чишмәләр, аларны саклау турында 5 җөмлә язып килергә.

– Рәхмәт сезгә, балалар. Чишмәдәй өлгер, җитез булыгыз. Телегез чишмә суыдай тәмле, чиста, саф булсын! Дәрес тәмам. Сау булыгыз.

17



**Диләрә ГАЛИМҖАНОВА,**

Саба районы Шәмәрдән «Үсеш» лицееның
I квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

# КӨЧЛЕ РУХЛЫ ШАГЫЙРЬ

(Фәнис Яруллин иҗатына багышланган сыйныфтан тыш чара)

ТӘРБИЯ СӘГАТЕ

ИСТӘЛЕК

*Университет елларымның бер истәлеге һәрвакыт күңел түремдә йөри. Әдәбият белеменнән дәүләт имтиханына әзерләнәбез. Барлык әсәрләрне ничек кирәк шулай укып чыктык. Ләкин Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәрен һич укып чыгып булмый. Бу әсәр минем өчен бик авыр иде. Менә имтихан җитәргә 1–2 көн калды. Ә бит әсәрне укып чыгарга кирәк. Ярый ничек тә төннәр йокламыйча, мин моның яртысын укыдым. Калганы башка керми генә бит. Әле ярый иптәш кызым Энже укыган иде. Имтихан бирәсе көннең төнендә ул эчтәлеген сөйләп чыкты. Күрәчәккә каршыдыр инде, имтиханда Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәре эләкмәсенме? Каушап, коелып төштем. Үзем эчтән генә имтиханны бирә алсам, ничек тә ахырына кадәр укып чыгам дип үземә сүз бирдем. Имтиханда әсәрнең башын төгәл итеп әйтеп биргәч, комиссия әгъзалары ахырын сорап тормадылар тагын. Сүземдә тордым, ахырына кадәр укып чыктым бит.*

**Максат:** Фәнис Яруллинның тормышы, иҗаты белән танышу; сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру өстендә эшләү; үз-үзеңне тәрбияләүгә омтылыш тудыру.

**Җиһазлау:** кабинет кафе кебек бизәлә. Өстәлләрдә шәмнәр, тәлинкәләр *(порцияләрне кую өчен).*

**Алып баручы.** Хәерле көн, хөрмәтле дусларыбыз. Бүгенге кичәбез гади генә булмас. Әдәби кафебызда үткәрербез. Рәхим итегез. *(Укучылар шахмат тәртибендә куелган өстәлләр артына утыралар, өстәлләргә ак эскәтерләр ябылган.)*

**Алып баручы.** Официантларга заказ биргәнче, әйдәгез, өстәлдәге язуларга игътибар итик әле.

**1 нче өстәлдәгеләр укый:** «Язмыш синең тез астыңа китереп сукса – егылмас өчен якасынаябыш. Утларга салса – үзең аннан да көчле ян, шулвакыт аның кызуын сизмәссең».

**2 нче өстәлдәгеләр укый:** «Суларга ташласа – күбек булып өскә күтәрелмә, асылташ булып төпкә бат, ялтыравыңны күреп чумып алырлар. Тузан итеп һавага күтәрсә – яңгыр тамчыларына кушылып, җиренә төш».

**3 нче өстәлдәгеләр укый:** «Җилкәнеңне җилләр екса – йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән».

**4 нче өстәлдәгеләр укый:** «Көчле рухлылар гына максатларына ирешә ала. Түземлеләр генә бәхеткә лаек».

**Алып баручы.** Я, әйтегез әле, бу көчле яңгырашлы сүзләрне кем язды икән? *(Фәнис Яруллин.)*

– Әйе, күренекле татар шагыйре, прозаик, драматург, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе һәм М. Җәлил исемендәге премия лауреаты, халык шагыйре көчле рухлы Фәнис Яруллин сүзләре бу. Әдәби кафедагы очрашуыбыз бүген нәкъ менә шушы язучыбызга багышлана.

– Ә хәзер официантларыбызны чакырабыз. Алар безгә ни тәкъдим итәр икән?

*Официантлар формасында киенгән, кулларында поднос, поднос өстендә өсте каплаулы тәлинкә, икенче кулларына сөлгеләр элгән укучылар керә. Алар, һәрбер өстәл янына килеп, подностагы әдәби порцияне тәкъдим итәләр. Өстәл артында утыручылар ачалар. Анда «Авылым – гомер бишегем» дип язылган сүзләр чыга.*

– Авыл – һәркем өчен кадерле, изге җир. Кая гына барсак та, без авылыбызны, туган җиребезне сагынып кайтабыз. Ф. Яруллин да, авылына багышлап, шигырь язмыйча булдыра алмагандыр.

Зур уңышлар яулап, заманалар
Матур бәя бирсә эшенә, –

Шатлыкларын ишеттерер өчен,
Туган ягы кирәк кешегә.

– Без хәзер Фәнис Яруллинның туган якка багышланган шигырьләренә күз салып китәрбез.

*«Баулы ягым» шигыре сөйләнелә.*

– Күренекле язучы Фәнис Яруллин 1938 елның 9 февралендә Баулы районы Кызылъяр авылында туган.

*«Якты тәрәзәм», «Өч нәрсә» шигырьләре сөйләнелә.*

*Официантлар икенче порцияне алып керәләр. Аннан «Балачак» дигән сүз чыга.*

**Алып баручы.** Ф. Яруллинның балачагы бик күңелле үтә. 8 класс белем алгач, Баулы конторасында монтёр булып эшли. Аннары армия сафларына алына.

*Балачакта булган кызыклы хәлләр турында «Илшат һәм Җил», «Бәп-бәләкәй булсам да», «Мультфильмнар карыйбыз», «Укыр идем бишкә генә» шигырьләре сөйләнелә.*

**Алып баручы.** Фәнис Яруллин өчен иң кадерле кеше – әнисе Гөлсәйдә ханым һәм тормыш иптәше Нурсөя ханымга багышланган порцияләрне дә татып карыйк әле. Бу ике затны оныту һич мөмкин түгел. Алар – язучының таянычы да, ышанычы да.

*Официантлар өченче порцияне алып керәләр. Ул «Якын кешем – әнием» дип атала. «Әни», «Молодец минем әби», «Ана турында баллада» шигырьләре сөйләнелә.*

*Официантлар дүртенче порцияне алып керәләр. Анда «Үлемсез җыр» дип язылган.*

**Алып баручы.** Безнең һәрберебезне балачактан яраткан шагыйрьләребезнең иҗаты озата бара.Фәнис Яруллинның яраткан шагыйрьләре турында әйтер сүзе бар икән.

*«Бәп-бәләкәй Апуштан», «Тукай аша», «Көч бирәсең миңа син, Муса», «Үлемсез җыр» шигырьләре сөйләнелә.*

*Официантлар бишенче порцияне алып керәләр. Анда «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» дигән сүзләр.*

**Алып баручы.** Гомер буе әти-әни белән янәшә безгә белем биргән укытучыларыбыз атлый. Бу Фәнис Яруллин белән дә шулай ук. Ни өчен дисезме? 1957 елда армиядә (авиация мәктәбендә) спорт белән шөгыльләнгәндә, арка сөяген җәрәхәтли, 1958 елдан гомерлеккә түшәккә кала. Түшәктә ятса да, читтән торып, Казан дәүләт университетын тәмамлый (1964–1970). Аның янына университет укытучылары килеп белем бирәләр, имтиханнар алалар. Язучы аларга бик зур рәхмәтле. 1960 еллардан башлап актив иҗат итә башлый.

– Әйдәгез, хәзер барлык укытучыларга гимн булган шул җырны бергәләп башкарыйк.

*«Сез иң гүзәл кеше икәнсез» җыры җырлана. «Сез кирәк» шигыре сөйләнелә. «Сөялдем сөяннәргә» җыры җырлана.*

– Әдәби кафебыз ябыла. Бу очрашу барыгызга да эчтәлекле һәм кызыклы булгандыр дип уйлыйм. Фәнис Яруллинның иҗаты – рухи ныклык, тормышны ярату һәм кешелеклелек үрнәге ул.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Ф. Яруллин. Әсәрләр. Өч томда: 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 495 б.
2. Ф. Яруллин. Йөрәкләрдә кабат терелә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 399 б.

18



**Райлә ЙОСЫПОВА,**

Саба районы Курсабаш мәктәп-интернаты
югары квалификация категорияле
укытучы-дефектологы

# БАЛАЧАК БӘЙРӘМНӘРЕ

(Роберт Миңнуллин иҗаты буенча сыйныфтан тыш чара – әдәби алан)

ТӘРБИЯ
СӘГАТЕ

**Мин 1990–1995 елларда КДПУның тарих-филология факультетында белем алдым. Уку йортына Тимершык урта мәктәбен уңышлы тәмамлап, дүрт кыз бергә укырга кердек. Группадашларыбызның кайберләре читтән торып укуларга күчтеләр, ә без дүрт сыйныфташ биш елны да көндезге уку бүлегендә тәмамладык. Хәзерге вакытта Татфак үсешенә зур өлеш керткән Рәдиф Рифкать улы, Рамил Хәмит улы безнең курсташларыбыз иде. Курсыбыз белән аралашып торабыз, биш ел саен очрашулар уза. Студент чакта Фоат абый Галимуллин дәресләрен бик ярата идем. Аның һәр сүзе, фикере күңелгә сеңеп калган. Сәнгатьле уку фәнен укытканда, Туфан ага Миңнуллинның «Бәхетле кияү» әсәрен сәхнәләштерде. Аның сәхнәдә бер әйбер дә артык булмый, стенада мылтык эленгән икән ул атарга тиеш дигән сүзләре гел хәтердә.**

**Максат:** балалар язучысы Роберт Миңнуллинның тормыш һәм иҗат юлы турында мәгълүматларны тирәнәйтү; язучы иҗаты белән тирәнрәк танышу теләге уяту.

**Җиһазлау:** Роберт Миңнуллинның портреты, фоторәсемнәре, китаплары, магнитофон, компьютер, презентация.

**Чара барышы**

**1 нче алып баручы.** Хәерле көн, хөрмәтле укучылар, мөхтәрәм кунаклар! Бүген без сезнең белән Татарстанның халык шагыйре, танылган дәүләт эшлеклесе, балалар язучысы Роберт Миңнуллин иҗаты турында сөйләшергә әдәби аланга җыелдык. Чарабызны әдипнең шигыре белән башлап җибәрик әле. Сүзне укучыларга бирик.

*Укучылар Роберт Миңнуллинның «Балачак бәйрәмнәре» шигырен укый.*

**1 нче алып баручы.** Роберт Миңнуллинның «Балачак бәйрәмнәре» китабы өчен сөенеп, 1985 елны Сибгат Хәким: «Балалык шушындый бәйрәмнәрдән башлана. Мин мондый бәйрәмнәрнең күбрәк булуын телим», – дип язган иде.

**2 нче алып баручы.** Балачак. Беркайчан да кабатланмас Балачак иле – кеше гомерендәге серле, мавыктыргыч алан. Шул аланда зур дулкынлану белән нәни кулларга алган беренче китап – балалар китабы.

**1 нче алып баручы.** «Балалар китабы ул – тормыш сабаклары да, гүзәллек, гаделлек, мәрхәмәтлелек дәресләре дә. Балалар китабы ул – якын дус, акыллы киңәшче дә, тугрылыклы иптәш, ышанычлы фикердәш тә. Балалар китабы ул вакытында чыккан якты кояш кебек, вакытында яуган шифалы яңгыр кебек, вакытында искән җылы җил кебек...» Танылган балалар язучысы, күренекле шагыйрь Роберт Миңнуллин кеше тормышында балалар китабының әһәмиятле, кыйммәтле ролен әнә ничек матур итеп тасвирлый!

**2 нче алып баручы.** Дөрестән дә, китап – кешене һәрчак яхшыга гына өндәүче, акыллы, тапкыр булырга киңәш бирүче, авыр вакытта югалып калмаска, нык ихтыярлы, батыр йөрәкле, әдәпле-әхлаклы булырга өйрәтүче тормыш дәреслеге бит ул.

*Укучы Роберт Миңнуллинның «Кайтыйк ла үзебезгә!» шигырен сөйли.*

**1 нче алып баручы.** Сөн елгасы аның иҗатында еш кабатлана. Ә хәзер Роберт Миңнуллинның тормыш юлын барлап китик. *(Мәгълүматлар слайдларда күрсәтелә бара.)*

Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин 1948 елның 1 августында Башкортстанның Илеш районындагы Нәҗәде авылында туа. Бер елдан соң аларның гаиләсе Кыпчак авылына күчеп килә. Әтисе Мөгаллим, анда берничә ел эшләгәннән соң, үзенең туган авылы Шәммәткә кайтып төпләнгән.

*Укучы Роберт Миңнуллинның «Шундый минем туган ягым» шигырен укый.*

**2 нче алып баручы.** Танылган әдип

башкорт язучысы Гыйлемдар Рамазанов 1986 елда Роберт Миңнуллин иҗаты турында түбәндәгечә язган: «Туган җир һәм газиз ана. Бу ике төшенчә – шигъриятнең терәк нокталары, төп темалары ул. Әнкәй белән туган җир, туган туфрак – бер-берсенә аерылгысыз булып бәйләнгән төшенчәләр. Туган төбәк һәм иң кадерле кеше – ана турында шигырь язмаган шагыйрьне табу мөмкин түгелдер. Шулай да Роберт – бу темаларга иң күп һәм иң җимешле язучы шагыйрьләребезнең берсе. Авторның йөрәгеннән чыккан ихлас сүзе, әлбәттә, укучы йөрәгенә дә барып җитә, җылы тойгылар уята».

**1 нче алып баручы.** «Әнкәйләр турында сүз чыкканда, мин элек үземнең Әнкәмне – гади бер татар хатынын искә алам. Ул үзе Гөлҗәүһәр исемле. Ә авылдашлар исә аңа Гөлҗәүһәр дип тә, ни өчендер, Җәүһәрия, Гәүһәрия дип тә, Җәүһәр, Гәүһәр, хәтта Миңнуллина дип тә дәшәләр. Безнең өчен аның иң матур исеме – ӘНКӘЙ! Ул бер ялгызы биш бала тәрбияләп үстерде». Менә ничек матур итеп Р. Миңнуллин әнисе турында искә төшерә. Әнисе хакындагы шигъри юлларга тукталыйк:

Күзләре – гел җәүһәр,
Һәр сүзе – мең гәүһәр!
Йөзләре – гөл, җәүһәр,
Ә үзе – Гөлҗәүһәр!

Әниләргә карата бик күп җырлап тора торган әсәрләр иҗат иткән шагыйребез. Кызлар башкаруында **«Әни кирәк»** җырын тыңларбыз.

**2 нче алып баручы.** Әдибебезнең әниләр турындагы шигырьләре хисапсыз. Шуларның берсен тыңлап китик.

*Укучы Роберт Миңнуллинның «Әнкәйне сайлап алмыйлар» шигырен укый.*

**1 нче алып баручы.** Әдибебезнең тормыш юлы белән танышуны дәвам итик. 1966–1968 елларда Илеш районы «Маяк» газетасында әдәби хезмәткәр. 1973 елда Казан университетын тәмамлагач, «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. Кайда гына яшәсә дә, туган җирен онытмый. Кеше күңелендә тирән эз калдыра торган шигъри тәлгәшләр яза. Әдипнең «Авылыма» шигыренә язылган җырын тыңлап китик. Наил Шәймарданов көе. *(Җыр башкарыла.)*

**2 нче алып баручы.** Роберт Миңнуллинның балалар өчен язган җырларын санап чыксак, аны җырчы шагыйрь дияр идек. Мәсәлән, «Күңелле тәнәфес» (Р. Яхин көе), «Әйлән-бәйлән», «Яңгыр җыры» (Ф. Әбүбәкиров көе), «Әни кирәк», «Кызыл тавык» (М. Шәмсетдинова көе), «Әйдәгез, дуслашабыз» (Р. Абдуллин көе),«Сандугач» (И. Якупов көе), «Зоопаркта» (Л. Хәйретдинова көе), «Светофор» (Т. Вәлиев көе) , «Әйдәгез, биибез! » (Т. Ильясов көе). Юкка гына Ләбиб Лерон шагыйрьне «Моңнуллин» димәгән шул.

**1 нче алып баручы.** «Миңа Робертның җырлары, бигрәк тә балалар өчен язганнары ошый, – дип яза Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиев. – Балачак образының гәүдәләнеше итеп күз алдына китерәм мин аны. Менә нинди кеше язарга тиеш балалар өчен! Ул – нечкә күңелле, хисле, ихлас кеше. Аның кебек шагыйрьләрнең кадерен белергә кирәк!»

**2 нче алып баручы.** Үзенең бер мәкаләсендә Роберт Миңнуллин шундый фикер әйтә: «Җыр – шигъриятнең канатлы жанры. Аның шундый бер үзенчәлеге бар: җыр сандугачы читлегеннән бер очып чыгып киткән икән, аны яңадан ул читлеккә кертермен димә...» Әйе, җыр сандугачын читлектә утыртып булмый. Бигрәк тә безнең героебыз сүзләренә язылган җырларны!

Җырларым, сез – татлы елларым,
Җырларым, сез – якты юлларым.
Җырларым, сезне шул юллардан
Гомерем буена юлладым.

«Җырларым-моңнарым»

**1 нче алып баручы.** Хәзер **«Әйдәгез, биибез!»** җырын җырлап биеп алыйк. *(Гали Ильясов көе, Роберт Миңнуллин сүзләре. Укучылар ярымтүгәрәк ясап басалар, җырлый-җырлый бииләр.)*

**2 нче алып баручы.** 1977–1983 елларда «Казан утлары» журналында өлкән мөхәррир, соңрак җаваплы сәркатип. 1983–1986 елларда ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт комитетында әдәби-нәфис тапшырулар редакциясенең баш мөхәррире.1986–1995 елларда «Яшь ленинчы» газетасының баш мөхәррире. «Татарстан» телеканалында 1976–1983 елларда «Шигъри тәлгәшләр», 1993–1995 елларда «Ихлас», 2008 елдан «Китап» тапшыруларын алып бара.

*Укучы «Әни, мин көчек күрдем!» шигырен сөйли.*

**1 нче алып баручы.** «Роберт Миңнуллин беренче китабын «Бәхетле булыгыз» дип атаган иде. Теләге нәшрият капусы ачылган чакка туры килгәндер: бик күп укучыларын бәхетле итте ул. Телдән төшмичә җырланган җырлары белән барлык өйләргә, күңелләргә килеп керде, үзен дә яраттырды... Ә сабыйлар аны тәмам үз итте: шигырьләрен отып алып сәхнәләрдән сөйлиләр, җырларын җырлыйлар. Аны белмәгән татар баласы юктыр», – дип яза аның остазы Шәүкәт Галиев.

*Укучы «Бәхетле булыгыз» җырын башкара.*

*Икенче укучы «Энекәш кирәк миңа» шигырен яттан сөйли.*

**2 нче алып баручы.** «...шагыйрь нәниләр дөньясында үзен судагы балык кебек иркен һәм табигый, иркә һәм бәхетле итеп хис итә», – дип яза Равил Рахмани «Нәниләр шагыйре» мәкаләсендә.

*Укучы «Өлкәннәр» шигырен сөйли.*

Бу өлкәннәр ни өчендер
Гел киресен эшлиләр.
Мин үзем чәй эчмим, алар
Кыстый-кыстый: «Эч!» – диләр.

**1 нче алып баручы.** Автор аналарның да, балаларның да колагына көлеп кенә, мыек астыннан елмаеп кына: «Үзегезгә читтән карагыз әле. Менә нәрсә килеп чыга гел акыл өйрәтүчеләргә», – ди сыман. Шигырьнең теле дә бик гади. Нәкъ балаларча киреләнә автор. Р. Миңнуллин олыларның приказ бирү, боеру рәвешеннән көлә. Автор «акыл өйрәтмичә» генә балаларны да өлкәннәрне дә тәрбияли.

**2 нче алып баручы.** Роберт Миңнуллин – җәмәгать эшлеклесе. 1995–2014 елларда Татарстан Республикасы Дәүләт Советында: Мәдәни һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе, 2000–2004 елларда ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, 2004 елдан ТР законнары текстларын тәңгәлләштерү комиссиясе рәисе.

*Укучы «Мактанырга яратмыйм» шигырен сөйли.*

**1 нче алып баручы.** Роберт Миңнуллинның күпкырлы хезмәтләре дәүләт тарафыннан бәяләнә. Авторның бүләкләренә тукталыйк. «Акбай цирк карый» (1978), «Җиде абый тай җигә» (1980), «Айга очтык (1982) исемле балалар китаплары һәм телевидениедән әдәбиятны актив пропагандалаганы өчен 1982 елда М.Җәлил исемендәге республика премиясенә лаек була. 2011 елда мәгариф өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре өчен, «Белем һәм тәрбия бирүдә балалар әдәбияты» фәнни-методик лабораториясе әгъзалары белән берлектә, Татарстан Республикасының Каюм Насыйри исемендәге премиясенә лаек була.

*«Без айга оча яздык» шигырен 5 укучы, күңелле музыка уйнаганда, рольләргә бүлеп сөйлиләр.*

**2 нче алып баручы.** «Дөньяда иң зур алма» исемле китабы өчен 1992 елда шагыйрь халыкара әдәби бүләккә – Андерсен исемендәге Почётлы дипломга лаек була. Исеме атаклы әкиятчеләрнең Почётлы исемлегенә кертелә.

*Укучы «Дөньяда иң зур алма» шигырен яттан сөйли.*

**1 нче алып баручы.** 1997 елда Р. Миңнуллинга балалар әдәбияты өлкәсендә ирешкән казанышлары өчен Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясе бирелә.

*Укучы «Малайлар сөйләшә» шигырен сөйли.*

**2 нче алып баручы.** 1998 елда исә шагыйрь «Мәгариф» нәшрияты чыгарган «Күчтәнәч» (1995) китабы өчен Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе белән бүләкләнә.

*«Исәнмесез, җилләр!» (Р. Миңнуллин сүз., О. Усманов көе) җыры башкарыла.*

**1 нче алып баручы.** Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәрне дә йөртә Р. Миңнуллин. 2000 елда Башкортстанның Фатих Кәрим исемендәге премиясе бирелә. 2005 елда татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән өчен Миңнуллин Роберт Мөгаллим улына «Татарстан Республикасы халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелә.

*Укучы «Остазларым» шигырен сөйли. Слайдлардан аның турындагы фикерләр укыла.*

**2 нче алып баручы.** Роберт Миңнуллин шигырьләрен укыганда, безне һәрчак ихлас күңелле, шаян, кызыксынучан, уйнарга бик яратучы, үзенең әти-әнисен, туганнарын, туган ягын өзелеп сөюче кечкенә татар малае озатып бара. Бу малай – табигать баласы. Роберт аганың шигырьләрен балачак китабының битләре дип әйтергә мөмкин. Чөнки биредә төп геройлар – балалар, аларның әйләнә-тирәлеге: табигать яшәеше, кош-корт, җәнлекләр тормышы, балалар уенындагы «мөһим» детальләр – яраткан уенчыклар,



китаплар, кием, ташлар, вак-төяк әйбер кисәкләре һ.б. Иң кызыгы: болар өлкәннәр өчен бер дә кызыксыну уятырлык әйберләр түгел, әмма бала өчен ул бик кыйммәтле.

**1 нче алып баручы.** Балалар әдәбиятына килгәндә исә, Р. Миңнуллин – һичшиксез, «балаларның куанычы» булган чын талант. Популярлык сере – балалар белән уртак сыйфатларында – ихласлылык, тапкырлык, шаянлыкта. Моңа ул тел-сурәтләү чараларын дөрес һәм урынлы куллану нәтиҗәсендә ирешә.

*Укучы «Батырлык эшләр идем» шигырен сөйли.*

**2 нче алып баручы.** Бер-беребез белән очрашыр булсак, йөгерә-ашыга күчтәнәчләр эзләргә тотынабыз. Кадерле дустыңа әллә ниләр табасы, тапшырасы килә. Ләкин безнең өчен иң кадерле күчтәнәч бүләк ул – китап! Без, кулдан Р. Миңнуллин шигырьләрен кертеп, рәсемнәр ясап, китапчыклар ясаган идек. Хәзер шуларны бер-беребезгә бүләк итик. Әдәби алан очрашуы истәлеге булсын.


**«Яратыгыз»** җыры бергәләп башкарыла.

# ПЕДАГОГЛАР ӨЧЕН ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШУ МӘЙДАНЫ




***Заман, укытучыдан бүгенге алгарышлар белән танышып, алар нигезендә эшли белүне таләп итә. Без сезгә файдалы чыганак булырга әзер!***


**«Мәгариф» һәм «Гаилә һәм мәктәп» журналлары**
Кәгазь басмаларда мәгариф дөньясындагы соңгы яңалыклар, проблемалар һәм аларны чишү юллары, белгечләр фикере, галимнәребез хезмәтләре, гаилә һәм мәктәп өчен файдалы язмалар белән таныша аласыз.



**«Магариф. РФ» электрон журналы (www.магариф.рф)**
Балалар бакчалары тәрбиячеләре, урта мәктәп укытучылары, урта һөнәри уку йортлары һәм югары уку йортлары педагоглары методик эшкәртмәләрен, дәрес планнарын, мастер-класслар, шөгыльләр һәм башка төрле эшкәртмәләрне бастыру порталы. Биредә мөгаллимнәребезгә аттестация узу өчен сертификат алу мөмкинлеге дә каралган.




**«МӘГАРИФ. ТАТАР ТЕЛЕ»**
**электрон журналы**
3 айга бер чыга. Биредә татар теле укытучылары үзләренең эш тәҗрибәләре белән уртаклаша ала.



**magarif-uku.ru сайты**
Мәгариф дөньясындагы яңалыклар, кызыклы язмалар, үзегезнең хәбәрләр белән дә уртаклашу мөмкинлеге.

**БӘЙГЕЛӘР**
Укытучылар һәм тәрбиячеләр, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә үткәрелә торган «Авыл укытучысы», «Иң яхшы тарих укытучысы», «Моңлы саз чыңнары», «Мәктәп бәйрәмнәре» h.б. бәйгеләрдә катнашып, үз көчләрен сыный ала.

**ЯЗЫЛУ**
Журналларга почтада гына түгел, редакция аша альтернатив рәвештә очсыз бәягә язылу мөмкинлеге бар. **Бәясе – 600 сум.**

**ЖУРНАЛНЫ САТЫП АЛУ:**
SHOP.TATMEDIA
Яндекс Маркет

**БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:**
«Мәгариф» ВКда
«Мәгариф» МАХта

РЕКЛАМА 16+